К. Ф. ӘМИРОВ Р. Г. ӘМИРОВА

ХОКУК БЕЛЕМЕ НИГЕЗЛӘРЕ

«МӘГАРИФ» НӘШРИЯТЫ

К.Ф. ӘМИРОВ Р.Г. ӘМИРОВА ХОКУК БЕЛЕМЕ НИГЕЗЛӘРЕ

К. Ф. ӘМИРОВ Р. Г. ӘМИРОВА

ХОКУК БЕЛЕМЕ НИГЕЗЛӘРЕ

ТАТАР УРТА ГОМУМИ БЕЛЕМ МӘКТӘПЛӘРЕ ӨЧЕН УКУ ЯРДӘМЛЕГЕ

Татарстан Республикасы Мәгариф министрлыгы тарафыннан тәкъдим ителгән

КАЗАН
«МӘГАРИФ» НӘШРИЯТЫ
1998

УДК 373.167.1
ББК 67.99(2) я 72
Ә54

Амиров К. Ф., Амирова Р. Г. Основы правоведения: Учебное пособие для сред. общеобразоват. шк. — Казань: Магариф, 1998.

Рецензентлары:

Рябов А. А. — Казан дәүләт университеты профессоры.
Татарстан Республикасы Мәгариф хезмәткәрләре квалификациясен күтәрү һәм белемнәрен арттыру институтының тарих һәм икътисад фәннәре лабораториясе.

Шушы китап материалларын нәшрият рөхсәтеннән башка яңадан бастырып чыгару «Автор хокукы һәм эргәдәш хокуклар турында» Россия Федерациясе Законын бозу була. Моның өчен закон нигезендә җавапка тарту каралган.

Әмиров К. Ф., Әмирова Р. Г.

Ә54 Хокук белеме нигезләре: Татар урта гомуми белем мәктәпләре өчен уку ярдәмлеге/Русчадан Л. Н. Гыймадиева тәрҗ. — Казан: Мәгариф, 1998. — 215 б.
ISBN 5-7761-0505-6

Уку ярдәмлегендә СССР таркалганнан соң бәйсез дәүләтләр формалашуның үзенчәлекләрен чагылдыручы хокук фәннәре нигезләре бәян ителгән. Материал Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарын исәпкә алып төзелгән. Китапта методик рекомендацияләр, белемнәрне ныгыту өчен контроль сораулар тәкъдим ителә, хокук фәннәренә караган документаль материал бирелә.

Китап укучыларга, укытучыларга адресланган, аны урта мәктәпләр өчен дәреслек итеп файдаланырга мөмкин.

БЗ — 5(64) — 43 — 98/99

© Издательство «Магариф» 1998
© Татарчага тәрҗемә,
«Мәгариф» нәшрияты, 1998

ISBN 5-7761-0505-6

Эчтәлек

Кереш. Хокук белемнәре ни өчен кирәк? 5

I бүлек. Дәүләт. Хокук. Әхлак

1. Дәүләт һәм хокук. Җәмгыятьтә тәртипне көйләүче буларак хокук һәм әхлак 8
2. Хаклы тәртип. Хокук бозу. Юридик җаваплылык 18
3. Законлылыкны саклау — җәмгыять тормышының нигезе. Хокукый дәүләткә бару юлында 25
4. Шәхеснең әхлакый-хокукый үсеше. Хокук культурасы (дәрес-бәхәс) 31

II бүлек. Конституция — дәүләтнең Төп Законы

5. Россия Федерациясендә конституцион законнар чыгару тарихыннан 35
6. Россия Федерациясендә дәүләт хакимияте органнары системасы 40
7. Татарстан Республикасы Конституциясе 45
8. Татарстан Республикасында дәүләт хакимияте органнары системасы 49
9. Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының хокук саклау органнары системасы 56
10. Җәмгыятьнең сәяси системасы 63

III бүлек. Кешенең юридик хокуклары һәм бурычлары

11. Гражданның хокуклары һәм бурычлары нәрсә ул? 68
12. Кеше хокуклары турында халыкара документлар. Кеше хокукларының гомуми декларациясе 74
13. Гражданлык хокуклары һәм ирекләре 78
14. Сәяси хокуклар һәм ирекләр 83
15. Икътисади хокуклар 85
16. Социаль хокуклар. Мәдәни хокуклар 87
17. Бала хокуклары турында халыкара документлар 90
18. Кеше хокукларын бозулар һәм аларны яклау 94

IV бүлек. Гамәлдәге законнар

19. Ватанны саклау — һәр гражданның изге бурычы 98
20. Административ хокук 102

21. Гражданлык хокукы. Салымнар 109
22. Торак хокукы 117
23. Җир хокукы 122
24. Табигатьне саклау 124
25. Никах, гаилә һәм закон 130
26. Җинаять — иң куркынычлы хокук бозу 137
27. Җинаять җаваплылыгына юл калдырмый торган шартлар 146
28. Җинаять җәзасы төшенчәсе һәм аның максатлары 149
29. Җинаятьнең кайбер төрләре өчен җинаять җаваплылыгы 154
30. Җинаятьләр ни өчен кылына? (Дәрес-бәхәс) 156
31. Хезмәт һәм закон 163
32. Үз хокукларыңны ничек якларга? (Практик дәрес) 165

Йомгак 167

Документаль материал 169

Хокукый төшенчәләр һәм атамаларның кыскача сүзлеге 196

Укырга тәкъдим ителә торган китаплар исемлеге 214

Кереш

Хокук белемнәре ни өчен кирәк?

> **Без һәр кеше белергә тиешле бер нәрсәне — законны бик начар беләбез.**
>
> *Оноре де Бальзак,*
> француз язучысы

Бу китап нәрсә турында? Гомумиләштереп әйтсәк, ул — хокук турында, кеше тормышының барлык якларын эченә алган һәм тууыннан алып вафатына кадәр аны озатып барган тулы бер нормалар җыелмасы турында.

Билгеле, сезнең һәммәгез дә прокурор, судья яисә адвокат булмас. Ләкин алган белемнәрегез тормыш турында күзаллавыгызны киңәйтер, үз тәртибегезне, башкаларның кылган гамәлләрен төгәлрәк һәм тирәнрәк, ә иң мөһиме, дөресрәк бәяләргә ярдәм итәр. Юридик белемнәр фикерләү дәрәҗәсен киңәйтеп кенә калмый, мөстәкыйль тормышка ышанычлырак адымнар белән керергә дә ярдәм итә. Законнарны яхшы белгән кеше җәмгыять өчен файдалырак. Ул кирәк чакта хокукларны һәм ирекләрне кысуга каршы тора, үз хокукларын гына түгел, җәмгыять, дәүләт мәнфәгатьләрен дә яклый ала. Юридик мәгълүматлы кеше үзе дә закон бозмый, башкаларны да моннан тыеп кала.

Сез законнарның ничек, кайчан һәм ни өчен килеп чыгуы, аларның ничек төзелүе һәм гамәлгә ашуы турында белерсез.

Сезнең күбегез инде җинаять хокукы белән кызыксына. Сез яратып карый һәм укый торган детектив фильмнар һәм әдәби әсәрләр шул турыда сөйли. Ләкин алар сез үзләштерергә тиешле белемнәргә иллюстрацияләр генә. Максат, беренчедән, җинаятькә каршы көрәш хокукының зарури нормаларын үзләштерү булса, икенчедән, кайбер яшүсмерләр тарафыннан эшләнә торган гамәлләр өчен җавапсызлык хисен җиңү. Һәр җинаять җинаять законын бозып кына калмый, әдәпсезлек, әхлаксызлык булып та исәпләнә.

Җинаятькә каршы көрәш хокукы — хокукның бик күп тармакларыннан берсе. Шуңа күрә аны өйрәнү белән генә чикләнеп калу дөрес булмас иде. Сез хокукның ул кадәр үк кы-

зыклы булып тоелмаган, әмма тормышта шулай ук кирәкле булган башка тармаклары — хезмәт, гаилә, гражданлык хокуклары һ. б. белән дә танышырсыз. Иң әүвәл балигъ булмаганнарга, ягъни сезгә турыдан-туры кагылышы булган положениеләр турында белерсез.

Дәреслектә үтемле формада Россия Федерациясе территориясендәге бәйсез республикалар формалашуның үзенчәлекләрен чагылдыручы хокук белемнәренең нигезләре бәян ителгән. Әлеге дәреслекнең үзенчәлеге шунда, ул республикабыз мәктәпләре өчен махсус әзерләнгән. Материал Россия Федерациясенең генә түгел, Татарстан Республикасы законнарын да исәпкә алып бирелгән. Республикабызның бәйсезлеге игълан ителү, ә аннары Россия Федерациясе белән Татарстан Республикасы арасындагы килешүгә кул кую белән бәйле рәвештә, законнарның үсеше оригиналь юл белән бара, һәм кайбер мәсьәләләрне хәл итүнең Татарстанда үз үзенчәлекләре бар.

Дәреслектә дәүләт һәм хокук нигезләре буенча кирәкле белемнәр системага салынган, гамәлдәге дәүләт һәм хокук күренешләрен чагылдыручы төп тасвирламалар схемалар рәвешендә күрсәтелгән. Схемалар хокук нормаларын һәм алар арасындагы бәйләнешләрне гадиләштерелгән формада үзләштерергә мөмкинлек бирер. Истә калырга тиешле төп төшенчәләр һәм билгеләмәләр калын хәрефләр белән бирелгән. Үтелгән материалны кабатларга теләсәгез, шул урыннарны гына укып чыгу да җитә. Китапны укыганда һәр бүлек ахырындагы сорауларга җавап бирергә онытмагыз. Беренчедән, сез теманы ничек үзләштерүегезне тикшерә аласыз, икенчедән, бу аны хәтергә яхшырак сеңдерергә ярдәм итәр.

Материал күләмнәре якынча тигез булган параграфларга, бер дәрес темасы бер параграфка сыеп бетәрлек итеп бүленгән.

Законнар, аларны үтәү кирәклеге турындагы белемнәр, билгеле, бер бу дәреслектә генә бәян ителмәгән. Әдәбият, тарих һәм башка фәннәрдә дә сез моңа кагылышлы шактый мисаллар күрә аласыз. Шымчылар турында фильмнар караганда, детектив әдәбият укыганда сез хокук законнары белән очрашасыз. Бу — информация алуның иң үтемле ысулы. «Бары тик бик компетентсыз кеше генә әдәбиятның әлеге төрен бәяләп бетермәскә мөмкин. Ул тирән әхлакый-психологик этәргеч бирә һәм үз-үзеңне тотуның гади һәм аңлаешлы мисалларында тәрбияли», — дип яза атаклы шымчы комиссар Мэгре турындагы китаплар авторы Жорж Сименон.

Дәүләт һәм хокук проблемаларының иң әһәмиятлеләре дә шактый катлаулы һәм киң уку материалы булып тора. Һәр фәндәге кебек үк, хокук белеменең үз төшенчәләре, кагыйдәләре бар. Китапта сезнең өчен яңа сүзләр, юридик атамалар һәм төшенчәләр шактый — аларны үзләштерми торып, хокук нормаларын аңлау мөмкин түгел. Китап ахырында махсус

хокук төшенчәләре һәм атамалары сүзлеге бирелгән, документаль материаллар — Россия Федерациясе Конституциясеннән, Татарстан Республикасы Конституциясеннән, башка законнардан өземтәләр өстәлгән. Материал белән танышканда аларга ешрак игътибар итегез, дикъкать белән укыгыз, сүзлек һәм закон текстлары сезнең өчен әйбәт ярдәмче материал булачак, һәм сез укылганнарның эчтәлеген яхшырак аңларсыз. Законнар даими яңартылып тора. Яңа законнар чыгуын күзәтегез, аларның иң әһәмиятлеләренең текстларын тормышта файдалану өчен сакларга тырышыгыз. Рәсми төстә алар «Российская газета» һәм «Республика Татарстан», «Ватаным Татарстан» газеталарында басылалар.

Дәреслекнең кайбер бүлекләре дәрес-бәхәс һәм практик дәрес формасында төзелгән. Класста шундый ук бәхәсләр оештырырга һәм практик биремнәрне үтәргә тырышыгыз.

Китапны тулысынча укып чыкканнан соң, үзләштерүнең нәтиҗәсе турында уйлау да файдалы булыр. Хокук нигезләрен без ни өчен өйрәнәбез? Ул хокук мөнәсәбәтләре өлкәсендә хәбәрдар булу, тормышның бу катлаулы өлкәсендә «сай йөзмәү» өчен кирәк. Хәзер белемле булу гына җитми. Катлаулы заманыбызга туры килә торган югарырак дәрәҗәгә ирешергә кирәк. Бу — хокук культурасы. Ул хокук белеменең һәм безнең курсның төп нәтиҗәсе булып тора. Законнар турындагы белемнәрне үзләштерү генә түгел, үзеңдә законга карата ихтирам тәрбияләү дә әһәмиятле. Курку түгел, ә нәкъ менә ихтирам. Күп кенә яшүсмерләрдә бу фәнне өйрәнгәннән соң җаваплылыктан курку хисе барлыкка килүе мөмкин. Ләкин бит ярамаган эш кылуның һәрвакытта да җәмгыятькә каршы юнәлтелгәнлеген, кемнеңдер хокукларын бозуын аңларга кирәк. Әгәр менә шуны аңласагыз, без үзебезнең максатыбызга ирешкән булырбыз.

Дәреслек Татарстан мәгариф хезмәткәрләренең квалификациясен күтәрү институты тарафыннан мәктәпләргә тәкъдим ителгән якынча план нигезендә язылган. Ул укытучыларга һәм укучыларга адресланган, аны урта мәктәп өчен тотрыклы дәреслек итеп файдаланырга мөмкин.

Китапның кульязмасы турында Татарстан мәгариф хезмәткәрләренең квалификациясен күтәрү институтында фикер алышынды. Авторлар, әйтелгән теләкләр һәм тәкъдимнәр өчен, Татарстан Республикасы мәктәпләренең атказанган укытучысы Ф. Г. Борһановага (Актаныш, 2 нче мәктәп-гимназия), укытучы-методистлар В. И. Гыйниятуллина, Н. А. Зачетова (Казан, 96 нчы мәктәп-гимназия), Ә. Ә. Әхмәтова (Зеленодол районы), Г. В. Цымбал, И. А. Исмәгыйлеваларга, укытучылар Н. П. Медушкина, Н. Б. Әхмәтшина, В. В. Гордеев, Ю. Д. Шурхаев, В. З. Бәһаветдиноваларга һ. б. ихлас рәхмәтле.

Авторлар әлеге дәреслекне куллану процессында үз фикерләрен белдергән иптәшләргә дә рәхмәтле булырлар.

I бүлек

Дәүләт. Хокук. Әхлак

1. Дәүләт һәм хокук. Җәмгыятьтә тәртипне көйләүче буларак хокук һәм әхлак

Нәрсә ул дәүләт? «Әхлак», «дәүләт», «хокук» сүзләрен сезнең инде күп тапкырлар ишеткәнегез бар. Без дәүләттә яшибез, безнең үз-үзебезне тотуыбызны әхлак, хокук көйләп тора. Ә менә аларның мәгънәсе нәрсәдә, төп билгеләре нинди? Мөгаен, моны әлегә һәммәгез дә белеп бетерми торгандыр.

Дәүләт кайчан һәм ничек барлыкка килгән соң? Бу өлкәдә фикерләр шактый күп. Шуларның берсен, дөресрәк булып тоелганын, карап үтик.

Гомуми территориядә уртак тормыш алып барган кешеләр акрынлап бердәм культурага ия булалар, аларның яшәү рәвешләре охшаш була бара, бердәм традицияләргә, гореф-гадәтләргә, күнекмәләргә буйсына башлыйлар. Кешеләрнең мондый берләшмәләре җәмгыять барлыкка китерә. Ләкин җәмгыять — кешеләр төркеме генә түгел, анда яшәүчеләрнең тарихлары уртак. Җәмгыять барлыкка килсен өчен, гасырларга сузылган вакыт, ничәмә-ничә буынның алмашынуы кирәк. Кыскача әйткәндә, җәмгыять — бергәләп эш итүнең зарурлыгын аңлаган, гомуми тырышлык кую юлы белән генә канәгатьләндерелә торган даими уртак ихтыяҗлары һәм мәнфәгатьләре булган кешеләр берлеге ул.

Җәмгыятьтәге мөнәсәбәтләрне көйләүче көч булып хакимият исәпләнә. Хакимият ул — үз ихтыярын үткәрергә, кешеләрнең яисә тулы бер төркемнәрнең эшчәнлек характерына һәм юнәлешенә, аларның тәртипләренә йогынты ясарга сәләтле көч. Борынгы община строенда хакимият гореф-гадәтләргә һәм абруйга таянган. Җәмгыять үсә барган, һәм тормышның барлык өлкәсендә дә тәртип урнаштыру өчен бу гына җитми башлаган. Җәмгыять үсеше, тарих курсыннан белүегезчә, сыйныфлар барлыкка килүгә китергән. Бай сыйныфларның мәнфәгатьләрен яклау һәм бер үк вакытта капма-каршы сый-

ныфның ризасызлыгын тыеп тору өчен куәтлерәк көч, хакимият коралы кирәк булган. Җәмгыятьтән аерылып чыккан һәм аның башында торган дәүләт нәкъ менә шундый көчне тәшкил иткән дә инде. Дәүләт һәм хокук кинәт кенә тумаган, гасырлар дәвамында акрынлап барлыкка килгән.

Шулай итеп, дәүләт кешелек үсеше процессында идарә итү коралы, җәмгыятьне оештыру формасы буларак барлыкка килгән. Сүз уңаеннан, дәүләт белән идарә итү сәнгате элек-электән сәясәт дип атала. Ә аның ярдәмендә ил белән идарә итә торган хакимият сәяси хакимият дип атала.

Дәүләт белән борынгы община строе арасындагы төп аермалар түбәндәге схемадан күренә.

1 нче схема

Борынгы заман җәмгыятендә хакимият	Дәүләт
Махсус идарә аппараты юк	Махсус идарә аппараты бар
Аерым мәҗбүр итү аппараты юк	Аерым мәҗбүр итү аппараты бар
Салымнар юк, чөнки ыру башлыклары үзләре дә җитештерүдә катнашканнар һәм үз өлешләрен дәгъвалый алганнар	Идарә һәм мәҗбүр итү аппаратларын тоту өчен салымнар алына
Хакимият җәмәгатьчелекнеке: һәркем бер үк вакытта хакимлек тә итә, буйсына да	Ачыктан-ачык хакимият: халык буйсындырылган
Халык кардәшлек билгеләре буенча тупланган	Халыкның территориаль бүленеше

Борынгы община строенда кешеләрнең башкалар белән даими идарә итүче махсус төркемнәре булмаган, тормышның барлык әһәмиятле мәсьәләләре ыруның өлкән әгъзаларының гомуми җыелышында хәл ителгән, ә җыелышлар арасында общинадагы эшләр белән халык тарафыннан билгеле бер срокка сайланып куелган юлбашчылар идарә иткән. Дәүләт хакимиятен тормышка ашыру өчен инде кешеләрнең аерым бер катлавы бүленеп чыккан. Алар хакимият һәм идарә, шулай ук мәҗбүр итү аппаратлары төзегәннәр. Беренчесенә закон чыгаручы һәм башкаручы хакимиятнең үзәк һәм җирле органнары, ә икенчесенә армия, полиция (милиция) һ. б. карый. Бу кешеләргә дәүләт-хакимият вәкаләтләре бирелә. Демократик булмаган илләрдә армия, полиция, судлар идарә итүче өстен катлауга хакимлекләрен сакларга ярдәм итәләр. Демократик илләрдә исә бу көчләр халык тарафыннан сайланып куелган вәкилләргә буйсыналар һәм үзләренең эшләрендә конституциягә һәм башка законнарга таяналар. Идарә аппа-

раты, кораллы кешеләрнең махсус отрядлары белән бергә, халык хакимияте дип атала.

Дәүләт тагын берничә билгегә ия — алары 2 нче схемада күрсәтелгән.

2 нче схема



Борынгы заман җәмгыятендә ыру яки кабиләнең билгеле бер территориясе булмаган, алар буш урыннарга күчеп йөргәннәр. Кешеләрнең хакимияткә буйсынуы аларның билгеле бер нәселгә, кабиләгә, гаиләгә каравына нигезләнгән була. Дәүләтнең исә төгәл билгеле территориясе барлыкка килә. Дәүләт хакимиятен һәм идарәсен әйбәтрәк итеп оештыру өчен, дәүләт территориясендә яшәүче халык административ-территориаль берәмлекләргә — провинция, край, өлкә, округ, районнарга берләштерелә.

Дәүләт суверенитеты дәүләт куәтенең нигезе булып тора. Дәүләт суверенитеты — дәүләт хакимиятенең ил эчендәге һәм тышындагы һәртөрле башка хакимияттән (сәяси яки идеологик) бәйсезлеге ул. Бәйсезлек хакимиятнең эчке тормыштагы барлык мәсьәләләрне мөстәкыйль һәм ирекле хәл итүдәге һәм башка дәүләтләр белән мөнәсәбәтләрдәге өстенлекле хокукында чагыла.

Халыктан салым җыю — дәүләтнең тагын бер билгесе. Салым җыю белән махсус дәүләт органнары шөгыльләнә. Салым һәм башка төр җыемнардан алынган керемнәр армия, полиция, дәүләтнең идарә аппаратын тотуга, шулай ук мәгарифкә, медицинага, халыкның фәкыйрь катлауларына ярдәм итүгә китә.

Дәүләтнең эчке һәм тышкы эшчәнлегенең төп юнәлешләре дәүләт функцияләре дип атала. Дәүләт функцияләрендә дәүләтнең җәмгыять үсешенең иң мөһим мәсьәләләрен хәл итүдәге төп максаты чагыла. Эчке функцияләр эчке сәясәтне чагылдыра һәм *саклаучы* (хокук тарафыннан билгеләнә һәм көйләнә торган барлык иҗтимагый мөнәсәбәтләрне саклауны тәэмин итү, ягъни гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен яклау, законлылык һәм хокук тәртибен, әйләнә-тирә мохитне һ. б. саклау) һәм *көйләүче* (иҗтимагый җитештерүне, ил икътисадын оештыру, шәхесне һәм җәмгыятьне формалаш-

тыру өчен лаеклы шартлар тудыру) функцияләр дип атала. Дәүләтнең тышкы функцияләре аның халыкара эшчәнлегеннән тора. Башка дәүләтләр белән үзара мөнәсәбәтләр тышкы сәясн һәм тышкы икътисади эшчәнлек юнәлешендә тормышка ашырыла. Илне тышкы һөҗүмнән саклау икътисади, дипломатик һәм хәрби чаралар белән тормышка ашырыла.

3 нче схема

Әгәр сез барлык өч схеманы да игътибар белән өйрәнсәгез, дәүләт төшенчәсен җиңелрәк аңлата алырсыз.

Дәүләт ул — буйсындыру һәм идарә итү аппаратына ия булган, үз боерыкларына илнең бөтен халкы өчен мәҗбүрилек көче бирә торган һәм суверенитетка ия булган үзенә бер төрле сәяси оешма.

Төрле сәяси агым вәкилләренең дәүләткә мөнәсәбәте төрлечә: аны тулысынча кире кагудан алып (анархизм) абсолютлаштыруга, җәмгыять тормышында дәүләтнең ролен арттырып күрсәтүгә кадәр (этатизм).

Анархистлар гына түгел, күп кенә либерал-демократлар да дәүләт идарәсенең әһәмиятен төрлечә кечерәйтеп күрсәтергә, дәүләт һәм шәхес мәнфәгатьләренең капма-каршы булуын расларга омтылалар. Бу позицияне дөрес дип санап булмый. Уйлап чыгарылмаган реаль тормышта дәүләтнең роле, аеруча авыр кризислар, реформалар чорында, гаять зур. 1994 ел башында «Россия дәүләтен ныгыту турында»гы документ шул сәбәптән барлыкка килде дә. Анда ничек итеп дәүләтне кеше хокукларын уңышлы яклый алырлык, икътисад белән идарә итә (турыдантуры түгел, мөмкин булганча читләтеп, салымнар аша), җинаять белән көрәшә, фәнгә, культурага, мәгарифкә ярдәм итә алырлык көчле дәүләткә әверелдерергә икәнлеге турында әйтелә.

Тәртипне норматив көйләү. Нормаль үсү өчен җәмгыять оешкан булырга тиеш. Аерым кешеләрнең, төркемнәр һәм коллективларның үз-үзләрен тотуларына ничек тә булса юнәлеш бирергә, аларны мәгълүм кысаларга кертергә, төрле юллар белән дәртләндереп яки, киресенчә, чикләп торырга кирәк.

Тәртипне шул рәвешле көйләү гомуми кагыйдәләр — нормалар ярдәмендә тормышка ашырыла. Норма (латинча *norma*-дан) — үрнәк, тәртип кагыйдәсе дигән сүз. Ул кешеләр тарафыннан кертелгән һәм кешеләргә юнәлдерелгән. Бу үз-үзеңне тоту үрнәген файдалануның билгеләнгән бер чиге юк, һәм тормышта ул һәммә кеше өчен дә уртак тәртип урнаштырырга ярдәм итә. Хокукый, әхлакый, сәяси, икътисади, корпоратив (җәмәгать оешмалары өчен) нормалар, шулай ук гореф-гадәтләр, традицияләр нормалары була. Шулар арасында хокук һәм әхлак нормалары төп урынны алып тора. Алар белән якыннанрак танышыйк.

Тарихи яктан алганда **әхлак** дәүләт һәм хокуктан шактый элек барлыкка килгән. Әхлак — җәмгыятьтә формалашкан рухи башлангычлар ул. Алар мәгълүм гомуми кагыйдәләрдә — гаделлек, изгелек, яхшылык, намуслылыкта чагыла. Кешеләрнең күпчелеге, үзенең һәм башкаларның кылган гамәлләрен бәяләгәндә, әхлакый нормаларга таяна, чөнки аларда тормыштагы иң әһәмиятле нәрсәләр турында күзаллаулар, идеаллар чагыла. Кешелек үсеше барышында иҗтимагый мөнәсәбәтләрне махсус көйләү ихтыяҗы туа, чөнки гореф-гадәтләрнең, традицияләрнең гамәлдәге нормалары социаль көйләү бурычын үти алмый башлый. Алардан көчлерәк көйләүче кирәк була. Хокук шундый норматив көйләүче урынын ала. Акрынлап барлыкка килгән тотрыклы гадәтләр **законга** әвереләләр.

Дәүләт һәм хокук бер үк вакытта барлыкка килә, чөнки алар — үзара бәйләнгән ике социаль күренеш. Хокуксыз дәүләт һәркем ни теләсә шуны эшли торган корабны хәтерләтер иде: берәү штурвал әйләндерә, икенчесе җилкән күтәрә, өченчесе якорь төшерә. Өстәвенә, берәү дә карта һәм компаска күз салмый. Мондый кораб белән ни булачагын сез күз алдына бик яхшы китерә торгансыздыр. Хокукның төп максаты — җәмгыятькә йогынты ясау, аны камилләштерү һәм үстерү. Нәкъ менә шуңа күрә дә хокук иҗтимагый алгарыш факторы булып тора.

Тарихчылар фикеренчә, беренче хокукый актлар безнең эрага кадәр IV—III йөзләрдә барлыкка килгән. Озак вакыт яшәү дәверендә хокук үзенең тышкы чагылышын, формасын үзгәрткән. Борынгы Греция һәм бигрәк тә Борынгы Рим хокукы классик дип, ягъни үрнәк алырлык дип исәпләнә. Законнар иҗтимагый тәртип нормаларын, билгеле бер чаманы саклау зарурлыгы турындагы күзаллаулардан чыгып билгеләнгән. Аннан соңгы бөтендөнья юридик фикеренең үсешенә Рим хокукы зур йогынты ясый. Буржуазия чорында тормышка юридик аксиомалар үтеп керә: законда каралмаган җәзалар кулланырга, бер үк җинаять өчен ике тапкыр гаепләү карары чыгарырга, җинаять законы тарафыннан каралмаган гамәлләр өчен хөкемгә тартырга, кешене хокук яклавыннан мәхрүм итәргә ярамый һ. б.

Хокук барлыкка килү белән, борынгы заманнан алып бүгенге көнгә кадәр, юристлар, философлар һәм башка галимнәр: «Хокук нәрсә ул? Ул нинди сыйфатларга ия?» — дип бәхәс-

ләшәләр. Бердәм фикер юк. Шулай да хокукның төп билгеләрен күрсәтергә, хокук башлангычы чагылу формаларын сурәтләргә, аның функцияләрен һәм ролен тикшерергә мөмкин.

Иң әүвәл хокукның ничек формалашуын карап үтик. Аның ике юлы барлыгы билгеле. Беренчесе буенча борынгы заман гадәтләре хокук нормаларына әверелгән, дәүләт аларны үтәүне барлык кеше өчен дә мәҗбүри итеп куйган. Француз язучысы Жозеф Жубер (1754—1824) бу хакта болай дигән: «Иң яхшы законнар гореф-гадәтләрдән барлыкка килә». Гореф-гадәтләрне эченә алган тәртип кагыйдәләре вакыт сынавын үткән кебек булганнар, тормыш ихтыяҗларына тәңгәл рәвештә үзгәреп торганнар һәм әзер хокук нормасы булып киткәннәр. Икенче юл буенча хокук дәүләт тарафыннан урнаштырылган. Ул норматив хокук актларын кабул итү, моңа кадәр җәмгыятьтә булмаган нормалар, тәртип кагыйдәләре билгеләү рәвешендә барган. Петр I нең барлык законнары да диярлек шундый.

Хокук ни өчен «хокук» дип атала соң? Барыннан да бигрәк, иң мөһим әхлакый принцип — хаклыктан, гаделлектән аерылгысыз булганлыгы өчен. Әмма аның өчен генә түгел. Иң әһәмиятлесе шунда: хокук һәрвакыт хокуклар аша, ягъни аерым кешеләр һәм тоташ коллективлар, оешмалар ия булган юридик мөмкинлекләр аша хәрәкәт итә. Хокук аларның үз-үзләрен тотулары законлымы яисә түгелме, димәк, җәзаланырга тиешлеме, юкмы икәнлеген билгели.

Еш кына «хокук» һәм «закон» сүзләре бер төрле мәгънәдә кулланыла. Хокук дәүләт тарафыннан закон формасында тәкъдим ителә. Нормалар — тәртип кагыйдәләре — нәкъ менә законда урын алган. Законнар дип дәүләт хакимиятенең югары органнары тарафыннан кабул ителгән һәм төп, әйдәүче дип исәпләнгән хокук актлары атала. Ә алар арасында Конституция (Төп Закон) иң югары юридик көчкә ия. Аның нигезендә һәм аңа туры китереп, барлык башка законнар чыгарыла. Законнар белән беррәттән, аларга буйсындырылган булса да, билгеле бер тәртип кагыйдәләрен — карарлар, инструкцияләр, кагыйдәләр, боерыклар һ. б. ларны үз эченә алган башка хокук актлары да яшәп килә. Бу нормалар мәгънәви бәйләнеш белән тоташканнар, законнар җыелмасы чылбырының буыннарын тәшкил итәләр. Законнар белән бергә алар хокук чыганакларын — хокук нормаларын — эченә алган документларны төзиләр.

Хокук өч төрле мәгънәдә кулланыла. Беренчесе — җәмгыятьтәге иң әһәмиятле мөнәсәбәтләрне җайга салучы нормалар җыелмасы, аларны бозган өчен дәүләт тарафыннан җәза бирелә. Икенче мәгънәсе — шәхси мөмкинлек. Бу мөмкинлек закон тарафыннан гарантияләнә. Сүз кешенең вөҗдан ирегенә, дин ирегенә, хезмәткә, укуга, социаль тәэминатка һ. б. хокуклары турында бара. Һәм, ниһаять, без еш кына «хокук» сүзен юридик булмаган мәгънәдә кулланабыз. Бу да шулай ук шәхси мөмкинлек, ләкин законда теркәлмәгән. Без, мәсәлән: «Ми-

нем үз фикеремне әйтергә хакым бар», — дибез. Һәм бу хокуклар да закон тарафыннан яклана торганнары кебек үк хөрмәткә лаек. Безнең өчен хокукның беренче мәгънәсендәгесе әһәмиятле, нәкъ менә шунысы безгә хокук төшенчәсен формалаштырырга ярдәм итәр.

Хокук ул — дәүләт тарафыннан урнаштырылган һәм үтәлүе дәүләт көче белән тәэмин ителә торган, һәркем өчен мәҗбүри тәртип нормалары системасы.

Хокукның асылы аның иҗтимагый мөнәсәбәтләрне көйләүче булуында чагыла. Мөнәсәбәтләрне көйләү, — димәк, кешенең үз-үзен тотышына юнәлеш бирү, аны билгеле бер кыса эченә кертү, җәмгыять өчен куркыныч булган гамәлләрдән кисәтү. Җәмгыять өчен хокукның кыйммәте шунда. Хокукый йогынтының ике төп юнәлешен аерып карарга була. Беренчедән, бу — көйләү, ягъни кеше, җәмгыять һәм дәүләт мәнфәгатьләренә туры килүче мөнәсәбәтләрне тотрыклыландыру һәм үстерү максатларында тәртип кагыйдәләрен урнаштыру функциясе. Икенчедән, саклау, ягъни иҗтимагый файдалы мөнәсәбәтләрне саклау һәм кеше, җәмгыять һәм дәүләт өчен куркыныч, зарарлы булган мөнәсәбәтләрне бетерү функциясе.

4 нче схема



5 нче схемада «хокук» төшенчәсен нинди сыйфатлар билгеләгәнлеге сурәтләнгән. Шуларны карап үтик.

5 нче схема



Әхлактан һәм башка хокукый булмаган социаль нормалардан аермалы буларак, хокук нормалары билгеле бер дәүләт тер-

риториясендә яшәүче барлык халык өчен дә мәҗбүри. Мәсәлән, Россия Федерациясенең яңа Җинаять кодексы Дәүләт Думасы тарафыннан 1996 елның 24 маенда кабул ителде һәм Федерация Советы тарафыннан 1996 елның 5 июнендә, ә Россия Федерациясе Президенты тарафыннан 1996 елның 13 июнендә яраклы дип табылды, 1997 елның 1 гыйнварыннан гамәлгә кертелде. Шул вакыттан алып ул закон көченә керде, ягъни үзенең көчен Россия Федерациясенең барлык территориясенә җәелдерде, һәммә кеше өчен гомуммәҗбүригә әверелде.

Хокук нормаларын барлык кеше дә үтәргә тиеш. Бу өлкәдә берәүгә дә өстенлек бирелми. Эш урыны, милләте, белеме һ. б. лар белән бәйле искәрмәләр гамәлдә юк. Әлеге юл белән җәмгыять тормышында бердәм, тотрыклы әйдәүче башлангычка ирешелә.

Җәмгыять катлауларга бүленгән очракта да хокук нормалары «өстәгеләрнең» дә, «түбәндәгеләрнең» дә мәнфәгатьләрен бердәй саклый. Атаклы нәселдән булган дворян А. В. Сухово-Кобылин (1817—1903), мәсәлән, кеше үтерүдә гаепләнә, гаебе исбат ителмәсә дә, озак еллар буе суд хакимияте тарафыннан хаксызга эзәрлекләнә, һәм бу хәл аңа «Кречинский туе», «Хөкем эше», «Тарелкинның әҗәле» дигән сатирик пьесалар язу өчен материал бирә.

Тоталитар дәүләтләрдә дә хокук кайвакыт хакыйкать сагында була. Бу аның асыл кыйммәте турында сөйли. Петербург шәһәре башлыгы Треповка аткан Вера Засулич эшенең нәтиҗәсе һәркемгә мәгълүм. Антлы утырышчылар суды аны аклый.

Хокук нормаларында кешеләрнең үз-үзләрен тотышларына булган таләпләр төгәл һәм җентекле күрсәтелә. Хокук нормалары рөхсәт ителгән яисә тыелган тәртип кагыйдәләренең чиге булып исәпләнә. Кыскача әйткәндә, хокук нормалары — идеяләр, фикерләр генә түгел, хокук актларында рәсми рәвештә бәян ителгән боерыклар да ул. Мондый рәсми билгеләмә тәртип кагыйдәләрен бер мәгънәдә аңларга һәм барлык җирдә дә бер төрле кулланырга мөмкинлек бирә, ул көчләү һәм башбаштаклыкның җәелүенә киртә булып тора.

Хокук нормалары һәрвакытта да ихтыяри рәвештә үтәлми, ул очракта аларны куллану дәүләтнең мәҗбүр итү көче ярдәмендә тәэмин ителә — гаепле кешеләр юридик җаваплылыкка тартыла. Юридик җаваплылык билгеле бер хәлләргә бәйле рәвештә вәкаләтле дәүләт органнары (суд, прокуратура, тикшерү һәм башлангыч сорау алу органнары) тарафыннан тормышка ашырыла. Хокук нормаларының яшәве һәм тормышка ашырылуы дәүләт органнары эшчәнлеге белән бәйле. Мәҗбүр итү көче булмаса, хокук беркемгә кирәксез кагыйдәләр җыелмасына әйләнер иде.

Хокук нормаларын куллану чикләнмәгән сандагы очракларга исәпләнгән. Тәртип кагыйдәләре алар юкка чыгарылганчыга кадәр гамәлдә була.

Хокук нормалары — мәңгелеккә катып калган догмалар түгел, алар чор үзенчәлекләренә яраштырылып даими камил-

ләштереләләр, кешелеклерәк була баралар. Гражданнарның гомуми һәм шәхси таләпләрен чагылдырып, хокук җәмгыятьтә гаделлек принцибын урнаштыра. Борынгы Рим ораторы Цицерон болай дигән: «Законнар «җитешсезлекләрнең тамырын корытырга һәм гаделлек урнаштырырга ярдәм итәргә тиеш».

Хокук һәм әхлак. Кеше кылган гамәлләрнең кайберләре әхлак нормалары белән генә, кайберләре закон белән генә көйләнә. Әлбәттә, беренчеләре икенчеләренә караганда күбрәк очрый. Борынгы Рим философы Сенека бу хакта болай дип яза: «Оят кайчакта закон тыймаган нәрсәләрне дә тыя». Әмма тормышта хокук һәм әхлак тарафыннан бер төрле карала торган хәлләр дә бар.

Марат дусты Николайны алдады, шуның белән әхлак нормасын бозды, ди. Бу очракта ул җәмәгатьчелек тарафыннан гына шелтәләнергә, кисәтелергә тиеш, дәүләт бу процесска тыкшынмый. Ләкин әгәр Марат аудиокассета сату-алу килешүенең шартларын үтәмәсә (акчаны алган, кассетаны бирмәгән булса), ул очракта инде гражданнарның һәммәсе өчен дә мәҗбүри булган Гражданлык кодексы таләпләрен бозган була һәм гражданлык-хокукый җаваплылыкка тартыла. Дөрес, законга каршы эшләре өчен Марат бу очракта да әхлакый яктан шелтәләнергә тиеш.

Хокук нормалары нигездә әхлаклылыкка корыла һәм халык акылын, хезмәттәге һәм көнкүрештәге максатка ярашлы таләпләрне чагылдыра, явызлык, гаделсезлек, җинаять һ. б. белән көрәш ысулларын билгели. Демократик дәүләттә барлык хокукый тәртип кагыйдәләре әхлакый нигезгә корыла. Закон тарафыннан тыелган һәммә нәрсә әхлак тарафыннан да тыела. Әйтик, хулиганлык, караклык, наркоманлык закон тарафыннан тыелган. Безнең әхлак та мондый гамәлләр белән каршылыкта тора.

Хокук әхлак нормалары эчендә хәрәкәтсез ятмый, үзе дә тәрбияли, гаделлеккә, чит кеше хокукын һәм иреген сакларга кирәклегенә өйрәтә. Бу күзлектән чыгып караганда, «Закон булган җирдә рәнҗү бар» дигән рус мәкале бик үк хаклы түгел. Закон бозган кеше өчен тискәре нәтиҗә — «рәнҗү» була, билгеле. Ләкин ул рәнҗү башка гражданнарның, җәмгыятьнең, дәүләтнең мәнфәгатьләрен тупас бозу аркасында барлыкка килә. Законны бозмасаң, синең үзеңне дә рәнҗетмәсләр. Югары әхлак сыйфатларына ия булган кеше беркайчан да законсыз гамәлләр кылмас.

Җәмгыятебездәге хокук һәм әхлак турында сөйләгәндә, хәзергә аларның норматив көйләүче икәнлекләренә генә басым ясадык, алар арасындагы аермаларны күрсәтмәдек. Әйе, безнең җәмгыятьтә хокук һәм әхлак бердәм нигезгә корылган, алар гомумкешелек кыйммәтләрен һәм идеалларын чагылдыралар. Ләкин хокук һәм әхлакның ике төрле норматив көйләүче икәнлеген онытырга ярамый. Аларның аерым үзенчәлекләре, тәэ-

сир итү өлкәләре бар. Бу үзенчәлекләр үзара тәңгәл килергә дә, килмәскә дә мөмкин.

6 нчы схема

Моннан тыш, әхлак нормалары үзләренең табигатьләре буенча да төгәл түгел. Хәтта бер гаилә әгъзалары да бер үк эшне төрлечә бәяләргә мөмкин. Хокук исә төгәллеге, билгелелеге белән аерылып тора. Хокук нормасы кешеләрнең хисләрен һәм кәефләрен түгел, ә аларның тәртибен, эшен җайга сала. Хокук нормалары белән әхлак нормалары арасындагы аерманы билгеләү өчен, 6 нчы схемага игътибар итегез.

6-а схема

Хокук нормалары һәм әхлак нормалары арасындагы аермалар		
Чагыштыру критерийлары	Хокук нормалары	Әхлак нормалары
Көйләү өлкәсе	Кешеләрнең һәм җәмгыятьнең мөһим мәнфәгатьләренә кагылучы иң әһәмиятле иҗтимагый мөнәсәбәтләр	*Кеше — кеше, кеше — коллектив, кеше — җәмгыять, кеше — дәүләт* тибындагы барлык иҗтимагый һәм шәхси мөнәсәбәтләр
Яшәү формасы	Законда беркетелгән	Акрынлап иҗтимагый аңда барлыкка килеп яшиләр
Тәртип бозу очрагында җаваплылык	Дәүләт тарафыннан мәҗбүр итү мөмкинлеге	Җәмгыять, коллектив яки аерым кешеләрнең әхлакый гаепләве
Кеше тәртибенең мәҗбүри көйләүчесе булып китүе	Алар дәүләт тарафыннан урнаштырылганнан яки расланганнан соң	Алар шәхеснең индивидуаль аңына кергәннән соң
Үсеш перспективалары	Киләчәк җәмгыятьтә хокук нормалары, әхлак нормалары белән кушылып, кеше тәртибенең бердәм нормасына әвереләчәк.	

Кыскача йомгак ясыйк. Дәүләт һәм хокук кешелек җәмгыяте үсеше нәтиҗәсендә барлыкка килгән, һәм алар кешелек

мәнфәгатьләренә хезмәт итәргә тиеш. Дәүләт җәмгыять белән идарә итүне, аны саклауны һәм аның икътисади һәм социаль үсешен тәэмин итүне тормышка ашыручы махсус сәяси оешма булып җитешә. Моның өчен дәүләтнең идарә итү һәм мәҗбүр итү аппараты бар. Аның боерыкларын үтәү бөтен ил халкы өчен мәҗбүри. Кеше хокукларын яклауда, икътисадны идарә итүдә, җинаятьчелек белән көрәшүдә, фәнне, культураны, мәгарифне үстерүдә дәүләтнең роле гаять зур.

Хокук — иҗтимагый мөнәсәбәтләрне җайга салучы күпкырлы күренеш. Хокук — җәмгыятьнең мөһим мәсьәләләрен хәл итү, кеше мәнфәгатьләрен канәгатьләндерү чарасы. Шул ук вакытта хокук гаделлек һәм кешелеклелек идеясен алга сөрә.

Дәүләт һәм хокук шәхес хокукларын хөрмәт итәргә һәм сакларга тиеш.

Сораулар һәм биремнәр: 1. Дәүләт нәрсә ул? Ул ничек һәм кайчан барлыкка килгән? Аның билгеләре һәм функцияләре нинди? **2.** Җәмгыятьтә ни өчен норматив көйләү кирәк? Юридик нормаларны ни өчен «гомуми кагыйдәләр» дип атыйлар? Биредә «гомуми» сүзе нәрсәне аңлата? **3.** Гореф-гадәт әхлактан һәм әхлак хокуктан ничек аерыла? Татарстан Республикасында яшәүче төп милләтләр өчен нинди гореф-гадәтләр хас? Алар нинди нормалар ярдәмендә җайга салына? Гаиләгезнең өлкән әгъзаларыннан гаиләгездә нинди традицияләр барлыгы турында сорашыгыз. Алар ничек барлыкка килгән һәм буыннан-буынга ничек күчә? **4.** Ике җөмләне чагыштырыгыз: «Хокук ул — тәртип кагыйдәләре һәм нормалар системасы», «Кешенең шәхси кагылгысызлыкка хокукы бар». «Хокук» сүзенең бу җөмләләрдә аермасы бармы? Түбәндәге сүзтезмәләрнең кайсысында «хокук» сүзе норматив мәгънәдә кулланылган: *аңлауга хокук; ата-ананың балага исем кушарга хокукы; җинаятькә каршы көрәш хокукы; үз илеңне идарә итүдә катнашу хокукы; милкәткә ия булу хокукы; тәләктәшлеккә хокук; тыныч җыелышлар ирегенә хокук; дуслык һәм мәхәббәткә хокук?*

2. Хаклы тәртип. Хокук бозу. Юридик җаваплылык

Хаклы тәртип. Һәр кешенең үз-үзен тотышы аның кылган гамәлләрендә, эшләрендә чагыла. Характерлары һәм аларның нәтиҗәләре буенча гамәлләр бер-берсеннән кискен аерыла. Иҗтимагый файдалы гамәлләрне хаклы тәртип дип билгеләргә мөмкин. Ул хокук нормалары күрсәтмәләренә туры килә, аларны бозмый. Иҗтимагый зарарлы гамәлләр икенче төркемне — хаксыз, хокукка каршы гамәлләр төркемен тәшкил итә. Алар хокук нормалары күрсәтмәләрен бозалар һәм шуңа күрә хокук бозу дип аталалар.

Җәмгыять өчен, билгеле, кешеләрнең хаклы тәртипләре файдалы. Хаклы тәртип социаль мөнәсәбәтләрнең оешканлыгын, аларның хокук тәртибенә буйсынганлыгын тәэмин итә, бөтен җәмгыятьнең нормаль тормыш эшчәнлегенең әһәмиятле шарты булып тора.

7 нче схема



Хокук бозу нәрсә ул? Гомумән алганда, хокук бозу хокук нормалары күрсәтмәләрен үтәмәүче, әйләнә-тирәдәгеләргә зыян салучы һәм юридик җаваплылыкка тартылучы, яки хокук урнаштырган тыюларны бозучы кешенең гаепле хәрәкәте (яисә хәрәкәтсезлеге) буларак характерлана ала. Тиешсез урыннан урам аркылы чыктың, гражданлык килешүе шартларын боздың, салым түләмәдең, кеше милкен урладың ди, — хокук бозуга мисаллар шундый.

Хокук бозуның аны әхлак нормаларын, гореф-гадәт һәм традицияләрне бозудан аера торган махсус билгеләре бар. Хокук бозуның аны кешеләрнең җәмгыятькә каршы башка гамәлләреннән, мәсәлән, закон тарафыннан җәзаланмый, ләкин тирә-юньдәгеләр тарафыннан гаепләнә торган әхлак нормала-

рыннан аера торган сыйфатларын закон билгели. Без тарих буенча әхлакның, гореф-гадәтләрнең, традицияләрнең законнан өстен куелуын күрсәтә торган вөҗданлылык, намуслылык мисалларын беләбез.

8 нче схема



Кешенең кылган гамәле хәрәкәттә яки хәрәкәтсезлектә чагыла. Хокукка каршы хәрәкәтне хокук тарафыннан саклана торган иҗтимагый мөнәсәбәтләргә зыян салучы кешенең үзүзен актив тотуы итеп күз алдына китерергә мөмкин. (Мәсәлән, автомобильне урлап алып китү.) Хәрәкәтсезлек, киресенчә, билгеле бер нигезе булып та аерым шартларда эшләнергә тиешле эшнең эшләнмәвендә чагыла. (Мәсәлән, бәлагә юлыкканнарга ярдәм күрсәтмәү.)

Хокук бозу хокукка каршы бару сыйфатына ия. Гражданнарга, дәүләткә, җәмгыятькә зыян салучы гамәл хокукка каршы бару була. Әлеге гамәл хокук нормасы куйган тәртип кагыйдәсенә каршы килә дигән сүз. Әмма кылган гамәлне хокук бозу итеп билгеләү өчен хокукка каршы бару сыйфаты гына җитми. Формаль яктан хокукка каршы башкарылган эш хәтта аны хокук бозу дип танымаслык дәрәҗәдә кечкенә булырга мөмкин. Әйтик, сез партадашыгыздан сорамыйча бер генә минутка аның карандашын алып тордыгыз, ди. Формаль яктан моны чит кеше милкен башбаштакланып тартып алу, хәтта талау дип тә әйтергә була. Ә дөреслектә?

Шуңа күрә хокук бозу төшенчәсенә тагын бер билгене — аның җәмгыятькә каршы юнәлтелгәнлеген кертергә кирәк. Бу инде формаль түгел, ә әһәмиятле сыйфат: бу гамәл җәмгыятькә һәм ул урнаштырган тәртипләргә зыян сала. Бу ике сыйфат объектив рәвештә хәрәкәттә (гамәлдә) яки хәрәкәтсезлектә чагыла. Хокук бозулар җәмгыять өчен зыянлы булганга, хокук күрсәтмәләре ярдәмендә дәүләт аларны кылудан тыя.

Хокук бозу һичшиксез гаеп эш булып саналырга тиеш. Гаеп — хокук бозучының үзенең хокукка каршы юнәлтелгән эшенә һәм аның нәтиҗәсенә психик мөнәсәбәте ул. Әлеге психик мөнәсәбәттә хокук бозуның мотивлары һәм максатлары чагыла.

Хокукка каршы эшнең җәзаланучанлыгы хокук бозучыга карата дәүләт йогынтысы чаралары куллану белән характерлана. Хокукка каршы эшнең җәзалануучанлыгы, Дамокл кылычы кебек, хокук бозучы өстендә хәтта реаль җәза булмаган очракта да эленеп торачак.

Юридик фән хокук бозу төшенчәсендә аның объектив һәм субъектив билгеләрен аерып күрсәтә, алар барысы бергә хокук бозуның составын тәшкил итәләр.

9 нчы схема



Хокук бозу составына түбәндәгеләр керә:

1. *Хокук бозу субъекты.* Ул кылган гамәлләре өчен закон буенча җавап бирергә сәләтле физик зат, шулай ук оешма (юридик зат) булырга мөмкин. Бу очракта җинаятькә каршы көрәш хокукында хокук бозу субъекты булып бары тик физик зат кына тора ала.

2. *Хокук бозу объекты.* Ул хокук тарафыннан көйләнә һәм саклана торган иҗтимагый мөнәсәбәтләрдән (мәсәлән, милек мөнәсәбәтләре) тора.

3. *Хокук бозуның объектив ягы.* Хокук бозуны объектив яктан караганда, аны билгеле бер объектка — хокук тарафыннан саклана торган иҗтимагый мөнәсәбәтләргә юнәлтелгән хокукка каршы гамәл (хәрәкәт яки хәрәкәтсезлек) буларак характерлыйлар һәм хокукка каршы гамәл белән аның иҗтимагый зарарлы нәтиҗәләре арасындагы сәбәп бәйләнешен билгелиләр.

4. *Хокук бозуның субъектив ягы* җинаять кылган кешенең гаебен күрсәтә, кылган эшенә аның психик мөнәсәбәтен чагылдыра.

Шушы билгеләрнең кайсысы да булса юк икән, димәк, хокук бозу да юк, закон тарафыннан билгеләнгән җаваплылык та юк дигән сүз.

Хокук бозуларның төп төрләре. Барлык хокук бозулар үзләренең иҗтимагый куркынычлылык дәрәҗәсе (зарарлы булулары) ягыннан җинаять эше һәм гаеп эшкә бүленәләр.

10 нчы схема



Гаеп эш хокук бозуның бер төре булып тора, җинаять белән чагыштырганда иҗтимагый зыян дәрәҗәсенең кечкенәлеге белән аерыла. Ул җәмгыять тормышының төрле өлкәләрендә кылына, җәмгыятьтә яшәп килүче хокук тәртибенең аерым якларына зыян китерә. Иҗтимагый мөнәсәбәтләр өлкәсенә бәйле рәвештә, гаеп эшләр берничә төргә бүленә:

— *гражданлык-хокукый гаепләр*: мөлкәткә бәйле мөнәсәбәтләр һәм кайбер очракларда мөлкәткә бәйләнмәгән мөнәсәбәтләр өлкәсендә кылына торган хокук бозулар. Оешмаларга һәм аерым гражданнарга гражданлык хокукын бозу аркасында салынган зыян, мәсәлән, килешү буенча алынган йөкләмәләрне үтәмәү аркасында мөлкәткә зыян китерә; мөлкәткә бәйләнмәгән очракларда, мәсәлән, кешенең намусына тап төшерә торган мәгълүматлар таратудан торган зыян салуда чагыла;

— *административ гаеп эшләр*: дәүләт идарәсе белән бәйле иҗтимагый мөнәсәбәтләргә (мәсәлән, вак хулиганлык, төрле кагыйдәләрне — юл йөрү, төзелеш, янгын куркынычсызлыгы, йорт хайваннарын тоту һ. б. бозу) зыян салучы хокук бозулар;

— *дисциплинар гаеп эшләр*: хезмәт мөнәсәбәтләре өлкәсендә була торган хокук бозулар. Алар эшчеләр, хезмәткәрләр, укучылар коллективы эшчәнлегенең эчке тәртибенә зыян салалар һәм аларның дисциплинасын йомшарталар (мәсәлән, эшкә чыкмау, җитәкченең боерыгын үтәмәү һ. б.).

Административ, гражданлык-хокукый һәм дисциплинар гаеп эшләр 19—25 нче параграфларда җентекләбрәк өйрәнеләр.

Җинаять (җинаятьчел хокук бозу) гаеп эштән иҗтимагый куркынычлылыкның иң югары дәрәҗәдә булуы белән аерыла һәм җинаятьләр турындагы законнар тарафыннан төрлечә кул сузулардан саклана торган иң әһәмиятле социаль мәнфәгатьләргә зыян сала. Җинаять шәхескә, җәмгыятькә, дәүләткә гаять зур зарар китерә. Бу — хокук бозуларның иң куркыныч төре. Болар турында без 26—30 нчы параграфларда җентекләбрәк сөйләшербез.

Юридик җаваплылык. «Җаваплылык» атамасы төрле мәгънәдә кулланыла. Күпчелек очракта ул «бурыч», «вазифа», яисә «җәза», «шелтә» төшенчәләрен аңлата. Юридик җаваплылык исә җәза яки шелтәне белдерә.

Юридик җаваплылыкка хокук бозу составының барлык элементлары да раслангач кына тартылалар. Гаепләнүчене җинаять һәм административ җаваплылыкка тарткан очракта, бу таләп мәҗбүри булып исәпләнә. Әмма закон бу кагыйдәдән кайбер искәрмәләр дә чыгара — субъект билгеле бер шартларда гаебе булмаса да җавапка тартылырга мөмкин (әйтик, эшмәкәр, әгәр закон яки килешү тарафыннан башка нәрсә каралмаган булса, гаебе булмаса да җаваплылыкка тартылырга һәм бурычын түләргә мөмкин).

11 нче схема

Юридик җаваплылык —
хокук бозучыга карата закон тарафыннан төгәл билгеләнгән процессуаль тәртип кысаларында вәкаләтле дәүләт органнары тарафыннан дәүләтнең мәҗбүр итү чаралары күрсәтелгән хокукый нормалар санкцияләрен куллану

Билгеләре

- дәүләт тарафыннан мәҗбүр ителү төрләренең берсе
- хокук тарафыннан билгеләнгән җәза
- хокук бозучының авырлыклар кичерү мәҗбүрияте
- хокук нормалары белән үзара тыгыз бәйләнеше
- хокук бозу гамәле эшләнсә генә кулланыла

Юридик җаваплылыкны күбесенчә хокук тармаклары буенча классификациялиләр.

Гражданлык-хокукый җаваплылык һәрвакыт мөлкәти характерда була һәм, зыян күргән кеше мәнфәгатьләрен яклап (кредиторны), җинаятьчегә (бурычлыга) карата уңайсыз нәтиҗәләргә китерә торган (зыянны каплату, неустойка түләтү һ. б.) мөлкәти характердагы йогынты ясау чаралары куллануда чагыла. Гражданлык-хокукый җаваплылык кредиторның бозылган мөлкәт хокукларын һәм мәнфәгатьләрен торгызуга юнәлтелгән була. Бурычлы-хокук бозучы үз мөлкәте белән түли.

Дисциплинар җаваплылык предприятие, учреждение яки оешма администрациясенең хезмәткәргә дисциплинар җәза бирүеннән гыйбарәт. Мәсәлән, Россия Федерациясенең Хезмәт турындагы законнар кодексында (135 нче статья) дисциплинар җәзаның түбәндәге төрләре каралган: кисәтү, шелтә, каты шелтә, эштән азат итү. Моннан тыш, эшче һәм хезмәткәрнең хезмәт вазифаларын башкарганда предприятиегә китергән зыяннары өчен (мәсәлән, эшче эш вакытында станокны ватты яисә җиһазны эштән чыгарды, ди) матди җаваплылык билгеләнгән.

Административ җаваплылык нигездә штраф, махсус хокуктан мәхрүм итү кебек чараларда чагыла. Административ җәза суд, урындагы кешеләр һәм органнар тарафыннан бирелергә мөмкин, аларга бу хокук закон буенча каралган (мәсәлән, ГАИ хезмәткәрләре, янгын сүндерүчеләр һ. б.).

Җинаять җаваплылыгы дәүләт йогынтысының катырак чаралары белән характерлана. Алар беренче чиратта гаепле кеше шәхесенә юнәлтелгән була. Берәү дә законга туры килә торган суд карарыннан башка җинаять эшләүдә гаепләнергә, шулай ук җинаять җаваплылыгына тартылырга тиеш түгел. Иректән мәхрүм итү, штраф салу, төзәтү эшләре кебек җинаять җәзалары җинаять җаваплылыгын тормышка ашыруның төп формасы булып исәпләнә.

Юридик җаваплылыкка кешеләр билгеле бер яшьтән генә тартылырга тиеш:

— *гражданлык-хокукый җаваплылыкка* — өлешчә 14, тулысынча 18 яшьтән;

— *дисциплинар җаваплылыкка* — 16 яшьтән;

— *административ җаваплылыкка* — 16 яшьтән;

— *җинаять җаваплылыгына* — 16 яшьтән, ә кайбер җинаятьләр, мәсәлән, үтергән, сәламәтлеккә зыян китерә торган тән яралары ясаган, көчләгән, талаган, урлаган, явыз хулиганлык кылган өчен — 14 яшьтән.

Юридик җаваплылыкка акылга сау, ягъни үз эшләре өчен хисап бирергә һәм алар белән җитәкчелек итәргә сәләтле кешеләр тартылырга мөмкин. Акылга сау булмаган кешеләр юридик җаваплылыкка тартыла алмый. Мондыйларга хроник

төстәге психик авырудан, вакытлыча психик эшчәнлеге бозылудан, акылга зәгыйфьлектән һәм башка төрле авыру халәтеннән интегүчеләр керә, андый вакытта кеше үз эшләренә хисап бирә һәм алар белән җитәкчелек итә алмый.

Гражданнардан тыш, оешмалар да хокук бозган өчен юридик җаваплылыкка тартылырга мөмкин. Алар гадәттә юридик зат дип аталалар, һәм бердәм таләп буенча бер тере организм, бер кеше кебек эш итәләр. Бу оешманың аерым хезмәткәре бердәм план буенча эш итә, аның хезмәт тәртибе оешманың үз тәртибе булып санала. Табигый ки, оешмалар законнарга һәм аларның эшчәнлегенә кагыла торган башка норматив актларга буйсынырга тиеш. Хокук бозган өчен алар юридик җаваплылыкка тартылалар. Оешмалар үзләренең йөкләмәләрен бозган яки зыян салган өчен — гражданлык-хокукый җаваплылыкка; идарә органнары күрсәтмәләрен бозган, мәсәлән, налоглар түләмәгән, төзелеш, табигатьне саклау кагыйдәләрен бозган өчен административ-хокукый җаваплылыкка тартылалар.

Юридик җаваплылык — җәмгыятьтә хокук бозучылар белән көрәштә, гражданнарны законнарны һәм хокук тәртибен хөрмәт итү рухында тәрбияләүдә, хокук бозучыларны тәртипкә өйрәтүдә үтемле чара ул.

Сораулар һәм биремнәр: 1. Хаклы тәртипне сез ничек аңлыйсыз? Хаклы тәртипкә мисаллар китерегез. Җәмгыять өчен хаклы гамәлләр нилектән аеруча кыйммәт? 2. Хокук бозу нәрсә ул? Әхлаксызлык хокук бозудан ничек аерыла? Барлык хокук бозулар да әхлаксызлыкмы? Законны бозуларның барысы да хокук бозу булып исәпләнәме, әллә хокук бозу составының барлык элементларын да эченә алган гамәлләр генә хокук бозуга керәме? Сез хокук бозуның нинди төрләрен беләсез? 3. Юридик җаваплылыкның сыйфатлары нинди? Ул нәрсәдә чагыла? 4. Юридик җаваплылыкның төп төрләрен атагыз. Аларга кыскача тасвирлама бирегез.

3. Законлылыкны саклау — җәмгыять тормышының нигезе. Хокукый дәүләткә бару юлында

Законлык һәм хокук тәртибе. Бер генә нык үскән җәмгыять тә законнарны катгый үтәүдән башка яши алмый. Әгәр законнар үтәлми икән, моның җәмгыять өчен ни файдасы бар? Инглиз философы Джон Локк (1632—1704) бу уңайдан болай дип әйткән: «Законнарны азрак чыгарыгыз, әмма аларның үтәлүен тикшерегез». Юридик нормаларны барлык кешенең дә төгәл һәм тайпылышсыз үтәве законлылык дип атала.

Законлылык башбаштаклык һәм законсызлыктан тыеп тора торган плотинага охшаган. Борынгы грек философы Ге-

раклит (б. э. га кадәр VI гасыр ахыры — V гасыр башы): «Халык законны үзенең терәге, үзен саклый торган стена шикелле сакларга тиеш», — дигән. Кечкенә генә ярык барлыкка килсә дә, законсызлык шуннан үзенә юл ярачак, һәм плотина һәлак булачак, анда яңа ярыклар пәйда булачак та, үзен куәтле агым алып китәчәк. Ярыклар һәм тишек-тошыклар булмаганда гына законлылык нык булачак. Моннан күп гасырлар элек француз короле Франциск I әйткән сүзләр бүген бөтен дөньяга таныды: «Fiat justitia, pereat mundus!» Аның тәрҗемәсе беренче карашка гаҗәбрәк яңгырый: «Дөнья җимерелсә дә, гадел хөкем тантана итсен!» Дөнья җимерелгәч, гадел хөкем ни өчен тантана итәргә тиеш соң? Кем өчен тантана итәргә? Безнеңчә, бу сүзләрне болай аңларга кирәк: әгәр гадел хөкем һәм закон тантана итә икән, дөнья да җимерелмәячәк.

Иң югары изге максатка да законсыз чаралар ярдәмендә ирешергә ярамый.

Борынгы грек философы Сократ (б. э. га кадәр 470—399 еллар тирәсе) игълан ителгән принциплар белән аларның практик яктан гәүдәләнешенең абсолют туры килергә тиешлеген раслаган сабак биргән. Аның тормышы да, үлеме дә бер-берсенә тәңгәл.

Картлык көнендә Сократ алласызлыкта (Олимп аллаларын, Зевсның үзен кире кагуда) һәм яшьләрне бозуда гаепләнә. Судта ул үзен бәйсез һәм горур тота. Афина суды философны үлем җәзасына хөкем итә. Аның дусты Критон җәза алдыннан Сократ янына төрмәгә килә һәм аңа качарга тәкъдим итә, чөнки хөкем карары гадел булмый бит. Әмма Сократ, акыллы һәм туры сүзле кеше буларак, моны намуссызлык дип исәпли, чит кеше гаделсезлегенә буйсыну аны үзең кылуга караганда яхшырак, ди. — «Әгәр дә без моннан табан ялтыратырга уйласак, Законнар һәм Дәүләт каршыбызга килеп чыгып юлыбызны бүләрләр иде дә сорарлар иде: «Әйт әле, Сократ, ни эшләргә уйладың син? Әлеге гамәлең белән Законнарны һәм бөтен Дәүләтне юкка чыгарырга ниятлисең түгелме? Әллә, синеңчә, хөкем карарларының бернинди көче булмаган, аерым кешеләр ихтыяры белән яраксызга әйләнә, юкка чыгарыла торган дәүләт бөтен һәм имин килеш яши аламы?» Сократ качудан баш тарта.

Соңрак Сократка карата чыгарылган хөкем карары дөрес булмаган дип табыла. Ләкин соң була инде.

Әллә Сократның яшисе килмәгәнме? Ничек кенә әле! Җәзаланыр алдыннан, шунда утыручы музыканттан ул үзен сазда бер җырны уйнарга өйрәтүен үтенгән. Теге, аптырап: «Нигә кирәк ул, син бит барыбер үләчәксең! — дигән. Сократ: «Үлем алдыннан уйнап карыйсым килә», — дип җавап биргән.

Сократның үлеме ахмакларча законга буйсыну түгел, гаделлек өчен көрәшнең бер формасы була. Качып китсә, хөкем карарын яраксызга чыгарган булыр иде. Ә бу түбән, кешегә лаек булмаган чара, димәк, аннан файдаланырга ярамый. Югары максатларга бары тик хаклы чаралар белән генә ирешергә кирәк.

Яшәп килүче хокук тәртибе законлылыкка таяна. Хокук тәртибе — җәмгыятьтәге хокук тарафыннан җайга салына торган мөнәсәбәтләрнең тәртипкә салыну халәте, законнарның гамәлдә булуы, хокукый көйләү механизмының тоткарлык-

сыз эшләве. Хокук тәртибе — законлылык тормышка ашуның, хокук субъектлары тарафыннан юридик нормаларның үтәлүе нәтиҗәсе (Россия Федерациясе Конституциясе, 2 бүлек, 15 статья). Хокук тәртибе законлылык режимы практик төстә реаль тормышка ашырыла торган урында яши. Хокук тәртибе — законлылык хәрәкәт итү нәтиҗәсе, ул аның таләпләрен тормышка ашыру дәрәҗәсен чагылдыра.

Законлылык, хокукый тормышның бер күренеше буларак, аерым принципларга нигезләнә.

12 нче схема

Законлылык —

хокук мөнәсәбәтләре субъектларының юридик нормаларны төгәл һәм тайпылышсыз үтәве

төп принциплар

законның өстенлек итүе, ягъни барлык норматив актларның Конституциягә һәм законнарга туры килүе (Россия Федерациясе Конституциясе, 1 бүлек, 15 статья)	дәүләт территориясендә законлылыкның бердәмлеге, дәүләтнең бөтен территориясендә законнарны бертөрле аңлау һәм куллану	закон каршында гражданнарның гомуми конституцион статуста, конституцион хокукларның, ирекләрнең һәм бурычларның тигезлегендә чагыла торган тигез хокуклылыгы

Законлылык таләпләрен тулысынча һәм эзлекле рәвештә тормышка ашыруны тәэмин итәргә булыша торган чаралар законлылык, ягъни хокук тәртибе гарантияләре дип атала. Гарантияләрне икътисади, сәяси, рухи һәм махсус-юридик төрләргә бүләргә мөмкин. Күп кенә гарантияләр Россия Федерациясе Конституциясендә, Татарстан Республикасы Конституциясендә күрсәтелгән.

Хокукый дәүләт төшенчәсе һәм аның билгеләре. Хокукый дәүләт идеясе — кешелек акылының иң кыйммәтле казанышларыннан берсе. Бу идея чыганаклары үзенең тамырлары белән Борынгы Грециянең антик җәмгыятенә барып тоташа. Борынгы заман һәм урта гасырның күп кенә сәяси һәм хокукый тәгълиматлары аша гадел дәүләт хакимияте, көч һәм хокукны берләштерү буларак законның хакимлек итүе, кешеләрнең табигый хокуклары ягыннан тигезлеге, хокукның

гаделлек үлчәме булуы турындагы фикер уза. Ул хокук ярдәмендә тәэмин ителә алырлык барлык яхшы нәрсәне үзендә туплый барып, дистәләрчә гасыр дәвамында акрынлап җитлегә, ныгый, камилләшә. Җәмгыять тормышы шартлары үзгәрүгә бәйле рәвештә хокукый дәүләт идеясе үзе дә үзгәрә.

Хәзерге заман хокукый дәүләт концепцияләренең нигезендә немец философы Кант (1724—1804), француз мәгърифәтчесе һәм хокук белгече Шарль Луи Монтескье (1689—1755) һәм XVIII гасырның башка галимнәре идеяләре ята. Бу галимнәр абсолютизм чоры дәүләтенә (аны Кант башбаштаклык дәүләте дип атаган) алмашка кешеләрнең табигый хокукларын танучы закон өстенлек иткән дәүләт килергә тиеш дип исәпләгәннәр.

Ә бу идея Россиядә үзенә ничек юл салган?

Крепостной хокук бетерелү, патша Александр II нең суд реформасы хокукый дәүләткә бару юлында беренче адымнар була. 1864 елгы суд уставлары судның администрациядән бәйсезлегенә, судьяларның алмаштырылмавына, җинаять эшен караганда округ судында антлы утырышчыларның катнашуына, суд эшенең ярыш характерында булуына нигезләнгән яңа суд оештыруны игълан итәләр. Адвокатура оештырыла. Николай II дә реформалар үткәрергә омтылыш ясый. Бу конституцион стройга күчү процессының башлануы белән бәйле була. 1905 елның 17 октябрь манифесты белән сүз, матбугат, митинглар һәм демонстрацияләр иреге, вөҗдан иреге, шәхси кагылгысызлык һ. б. ирекләр игълан ителә. Әмма бу чаралар эзлекле рәвештә тормышка ашырылмый. Хокукый дәүләт башлангычларына нигез бары тик 1917 елгы февраль революциясеннән соң гына салына. Ләкин бу демократик режим яшәүгә сәләтсез булып чыга һәм Октябрь революциясе тарафыннан бетерелә.

Большевикларның парламентар республикага караганда демократиграк һәм халыкчанрак булырга тиешле Совет дәүләте төзү планнары, тормыш күрсәткәнчә, җимерелә. 1918 елгы беренче конституция үк инде пролетариат һәм иң ярлы крестьяннар диктатурасын ныгыта. Билгеле булганча, диктатура ул — бернинди законнар белән дә бәйләнмәгән хакимият. Атаклы рус философы Н. Бердяев 1917 елгы Октябрь вакыйгаларыннан соң болай ди: «Россиядә сыйныф идеясе кеше идеясен үтерде». Бу шартларда, әлбәттә, хокукый дәүләт, хокукның өстенлеге, законның идарә итүе турында сөйләшергә туры килми. Совет власте хокук һәм хокукый дәүләт идеясенә тупас каршы килә торган бик күп мисаллар бирә. Хокукый нигилизм (кире кагу) урнаша. Кеше гаять зур административ-идарә машинасының кечкенә бер шөребе итеп кенә карала. Шәхеснең хокукларын һәм ирекләрен тәэмин итү икенче планга күчә. Совет дәүләте төзелешенең теориясе һәм практикасында хакимиятләрнең бүленеше принцибы кире кагыла. Ул принцип буржуаз дип һәм Совет дәүләтен идарә итүдә яраксыз дип аңлатыла. 80 нче еллар азагында гына хокукый дәүләт төзү кирәклеге турында сүз алып барырга мөмкинлек туды.

Хокукый дәүләт турындагы тәгълиматның төп положениеләре арасында түбәндәгеләрне билгеләргә мөмкин:

1. Законның өстенлеге. Хокукый дәүләттә хокук хакимлеге, законның өстенлеге урнаштырыла.

Закон кем һәм нәрсә өстеннән хакимлек итәргә тиеш? Бер үк дәрәҗәдә дәүләт өстеннән дә, кеше өстеннән дә. Закон каршында барысы да: гражданнар да, урындагы кешеләр дә, дәүләт тә бертигез. Хокук нормалары урнаштыргач, дәүләт үзе дә шуларга бәйләнгән булырга тиеш. Хокук нормалары барлык дәүләт органнары өчен дә, гражданнар өчен дә бертигез дәрәҗәдә мәҗбүри. Алар закон кушканны гына үтәргә тиеш. Закон өчен кешеләр арасында аерма юк. Нәкъ менә шул дәүләтне сәламәт, көчле итә, рәхимсезлектән һәм гаделсезлектән саклый.

Законның өстенлеге аның иң югары юридик көчкә ия булуын да белдерә. Хокукый дәүләттә закон күпчелек халык ихтыярын чагылдырырга, кеше һәм гражданның хокукларын һәм ирекләрен сакларга мөмкинлек бирә торган юл белән кабул ителә. Хокукый дәүләт формалашу законнарның үсүен һәм камилләшүен белдерә. Соңгы вакытта дәүләтебезнең хокукый дәүләт буларак үсүенә нигез сала торган күп кенә закон актлары кабул ителде. Бу — Россия Федерациясенең дәүләт суверенитеты турындагы декларация, Кеше һәм гражданның хокуклары һәм ирекләре декларациясе, Гражданлык турындагы закон һ. б. Бөтен халык тавыш бирүе юлы белән Россия Федерациясенең яңа Конституциясе кабул ителде.

Хокукый нигилизмнан — гомуми кабул ителгән кыйммәтләрне, хокукларны кире кагудан котылырга кирәк. Җәмгыятьнең барлык әгъзаларының, барлык урындагы кешеләренең законнарны хөрмәт итүе һәм саклавы демократик хокукый дәүләтнең аерылгысыз сыйфаты булып исәпләнә.

2. Дәүләтнең һәм шәхеснең үзара җаваплылыгы җәмгыятебезнең дәүләти һәм сәяси тормышындагы күп кенә үзгәртеп коруларның уңышын билгеләүче әһәмиятле фактор булып тора. Хокукый дәүләт кешелек дәрәҗәсен хөрмәт итә, аның өчен ул иң югары кыйммәт булып исәпләнә. Административ башбаштаклыкка, тупас көчләү һәм ялганга юл куймый. Моннан тыш, хокукый дәүләт гражданнарның хокуклары һәм ирекләренең аларның конституцион бурычлары белән иң уңай ярашуын тормышка ашыра.

3. Шәхес хокуклары һәм ирекләренең реаль гарантияләнүе суд эшчәнлеге һәм башка хокук саклау органнары ярдәмендә аларны тулысынча яклауның эшкәртелгән механизмы барлыгын белдерә, кешенең хокуклары һәм ирекләре суд яклавы белән гарантияләнә. Хокукый дәүләттә кеше, аның хокуклары һәм ирекләре — иң югары кыйммәт. Кеше һәм гражданның хокуклары һәм ирекләре декларациясе, Россия Федерациясе Конституциясе дәүләт хакимиятенең төп бурычы сыйфатында кеше хокукларын һәм ирекләрен, намусын һәм дәрәҗәсен саклауны һәм яклауны игълан итә. Бу конституцион положениеләрнең тормышчанлыгын тәэмин итә торган гарантияләр системасын төзү күздә тотыла.

4. **Хакимиятләрнең бүленүе** дәүләт хакимиятенең мөстәкыйль һәм тигез хокуклы өч тармактан — *закон чыгаручы, башкаручы* һәм *суд* органнарыннан торуын аңлата. Хакимиятләрнең бүленүе теориясенә беренче тапкыр инглиз Джон Локк (1632—1704) һәм француз Шарль Луи Монтескье (1689—1755) нигез салалар, һәм ул хакимият бер кеше һәм кешеләрнең тар бер даирәсе кулында булган абсолютизмга каршы идея көрәшендә кулланыла. Абсолютизм вакытында хакимиятнең бер органда, бер кулда тупланнуы законсызлык, хокукны санга сукмаучы режим урнашу куркынычы тудыра. Деспотик режим барлыкка килүгә юл куелмасын өчен, хакимиятнең барлык тармаклары чикләнгән, бүленгән, аерымланган булырга тиеш. Алар үз вәкаләтләре кысаларында, бер-берсен алыштырмыйча эш итәләр. Гүя бер хакимият икенчесенә күзәтчелек итә, тиешледән читкә чыгарга юл куймый. Үзара мөнәсәбәтләрдә контроль һәм тигез хокуклылык урнаша.

Хакимиятләрнең бүленү принцибы бездә беренче мәртәбә Россия Федерациясенең 1990 елның 12 июнендә игълан ителгән Дәүләт бәйсезлеге турындагы декларациясенең 13 статьясында, ә аннары Россия Федерациясе Конституциясенең 10 статьясында беркетелде. Конституциянең 11 статьясы буенча, дәүләт хакимиятен Россия Федерациясе Президенты; Федераль Җыелыш; Россия Федерациясе Хөкүмәте һәм Россия Федерациясе судлары тормышка ашыра. Әлеге структураларның үзара йогынтысының билгеле бер традицияләрен һәм кагыйдәләрен формалаштыру өчен күп тырышырга кирәк әле. Хакимиятнең бу тармакларының ничек эшләве турында без җентекләбрәк алтынчы параграфта танышырбыз.

Әйтелгәннәрне исәпкә алып, хокукый дәүләткә түбәндәге билгеләмәне бирергә мөмкин:

Хокукый дәүләт — иҗтимагый мөнәсәбәтләрне көйләүче төп принцип буларак хокук өстенлеге, законның идарә итүе, закон һәм бәйсез суд каршында һәммәсенең дә (хакимиятнең, гражданның, җәмгыятьнең) тигез хокуклылыгы тәэмин ителгән, кешенең хокуклары һәм ирекләре танылa һәм гарантияләнә торган, ә хакимиятне оештыру нигезенә хакимиятләрне бүлү принцибы салынган демократик дәүләт ул.

Хокукый дәүләт төшенчәсе безгә демократия шартларында дәүләт хакимияте эшчәнлегенең идеаль үрнәген бирә. Иҗтимагый үсеш ихтыяҗларыннан барлыкка килеп, бу идея акрынлап тормышка аша. Хокукый дәүләт формалашу — гаделлеккә, гомумкешелек кыйммәтләренә, социаль алгарышка бару юлында озакка сузыла торган процесс. Россия Федерациясе Конституциясенең аны хокукый дәүләт буларак билгеләүче 1 статьясын нәкъ менә шулай кабул итәргә кирәк тә. Бу статьяда Россия Федерациясе хокукый дәүләт дип игълан ителгән. Әлегә бу положение киләчәккә теләк булып кына кала, чөнки Россиядә хокукый дәүләт төзелеп кенә килә әле.

Сораулар һәм биремнәр: 1. Кабул ителә торган законнарның тормышка ашуына ничек ирешергә? Түбәндәге мәкальләрнең мәгънәсен ничек аңлыйсыз: «Көчле белән көрәшмә, бай белән судлашма», «Хаклык өчен судлашма, бүрегеңне сал да башың и», «Закон — пәрәвез: шөпшә очып үтә, чебен эләгеп кала», «Җүләргә закон юк», «Мохтаҗлык закон белми». Искермәгәнме алар? Закон белән бәйле тагын нинди мәкальләр беләсез? Аларның мәгънәләрен аңлатыгыз. 2. Хокукый дәүләт идеясе үзенә ни белән җәлеп итә? 3. Түбәндә китерелгән фикерләрнең кайсысы хокукый дәүләт «рухына» каршы килә: *суд закон чыгару һәм башкару хакимиятенә бәйсез булырга тиеш; дәүләт мәнфәгатьләре шәхес мәнфәгатьләреннән өстен; шәхес хокукларының һәм ирекләренең реаль гарантияләнүе; кеше хокукларын тормышка ашыру билгеле бер сәяси ситуациядән тора.* 4. Хокукый дәүләтнең төп билгеләрен санагыз. Аларның кайсылары бездә әле тиешле үсеш алмаган? Мисаллар китерегез. Хокукый дәүләтнең төп билгеләренең схемасын сызыгыз. Хакимиятләрнең бүленеше ни өчен кирәк? Безнең илдә аңа ничек ирешелә? 5. Россиядә хокукый нигилизмның чыганаклары нинди? Хокукый дәүләттә хокукның өстенлек итүе, законның идарә итүе нәрсәдә чагыла? 6. «Европа тарихында шәхесне азат итүдәге һәр адым хокукый дәүләт үсеше һәм... үсеше белән бәйләнгән». Күп нокталар урынына түбәндәге сүзләрнең кайсысын куярга була: *киеренкелек; культура; законлылык; сәясәтләшү.*

4. Шәхеснең әхлакый-хокукый үсеше. Хокук культурасы

(дәрес-бәхәс)

Сез радио, телевидение, газеталар аша безнең илдә теге яки бу үзгәртеп коруларның катлаулы, акрын баруы турында белеп торасыз. Кайбер реформаларның кирәклеге күренеп торса да, аларны тормышка ашыруга төрле кеше төрлечә карый. Бу нәрсә белән бәйләнгән соң? Әлеге сорауга хокук культурасы төшенчәсе — чын гражданның төп сыйфатларының берсе аша җавап бирергә тырышыйк.

Бу төшенчә хокук һәм культура сүзләреннән тора. «Хокук» төшенчәсен без инде карап үттек. Гомуми планда «культура» атамасы астында кешелек җәмгыяте барлыкка китергән, аның билгеле бер үсеш дәрәҗәсен чагылдыра торган матди һәм рухи кыйммәтләр җыелмасын күз алдына китерәләр. Хокук культурасы, бер яктан, гомуми культураның бер өлеше булып тора, икенче яктан, ул һәрвакыт җәмгыятьтә яшәп килә торган билгеле бер хокук системасы белән бәйләнгән була.

Хокук күп яктан тулаем җәмгыятьнең билгеле бер тарихи үсеш дәрәҗәсе белән (культура үсеше дәрәҗәсен дә кертеп) бәйле. «Хокук культурасы» төшенчәсе хокук һәм законнарның үсеш дәрәҗәсен, җәмгыятьтә аның турындагы хәбәрдар-

лыкны, законлылык һәм хокук тәртибенең торышын чагылдыра. Хокук культурасы тормышыбызның аерым якларына гына — хокук белән көйләнә торган иҗтимагый мөнәсәбәтләргә генә кагыла.

Шәхеснең хокукый культурасы — хокукны тирәнтен белү һәм аңлау, аңа хөрмәт белән карау, хокуктан файдалана белү күнекмәләре, шулай ук юридик әһәмияткә ия булган тәртип, ягъни үзеңнең тәртибеңне юридик нормалар таләбенә буйсындыра белү, законлылык һәм хокук тәртибен ныгытуга ярдәм итәргә әзер булу ул.

13 нче схема



Шулай итеп, шәхеснең хокукый культурасы төзелеше түбәндәгеләрдән тора:

Беренчедән, гамәлдәге законнарны белү. Билгеле, гражданнан барлык законнарны да белүен таләп итеп булмый. Сүз иң әүвәл аның Конституцияне, төп хокукларны, ирекләр һәм бурычларны белүе турында бара. Хокукны белү, ягъни халыкның югары хәбәрдарлыгы хокук мәгълүматларын аңлаешлы итә торган чараларның күплегеннән тора. Хокукый дәүләт төзү бу положениене үтәүне дә күздә тота.

Икенчедән, хокук культурасының әһәмиятле күрсәткече — хокукый аң дәрәҗәсе. Гражданның хокукый культурасы хокукка хөрмәт белән каравында чагыла, башкаларның хокукын хөрмәт итүне, үз бурычларын намус белән үтәүне күздә тота.

Законнар тәртипнең техник кагыйдәләре буларак кына түгел, ә гомумкультура, әхлакый кыйммәт буларак кабул ителергә тиеш. Әхлаклылык, кирәге беткән әйбер кебек, тарих чүплегенә ташланырга тиеш түгел. Әгәр әхлаклылык һәм хокук культурасы читкә тибәрелә икән, бу, илебездә 30 нчы еллар азагында булган кебек, миллионнарча кешене коточкыч язмышка дучар итәргә мөмкин.

Әхлаклылыкның һәлакәте проблемасы турында, намус, кызгану, кеше хәленә керә белү, шәфкатьлелек, гакыл, кешелеклелекнең юк ителергә һәм онытылырга тиеш түгеллеге турында Ю. Домбровскийның «Кирәксез әйберләр факультеты» дигән романы сөйли. Романдагы вакыйга 1937 елда бара.

...Сорау алу күренеше. Ул бәхәскә әйләнгән диярлек. Шиккә алынган Зыбин археолог булып эшли. Үз вакытында ул университетның юридик факультетын тәмамлаган булган. Тикшерүче — яшь кенә хатын — белеме буенча шулай ук юрист. Әмма аларга бер-берсен аңлау кыен, аларның әхлак һәм хокук турындагы күзаллаулары төрлечә. Зыбин өчен алар икесе бер бөтен, рухи һәм әхлакый кыйммәтләрнең бердәм дөньясы. Тикшерүчегә аның хокук нормаларын бозуы турында искә төшергәч, тегесе ансат кына болай дип җавап кайтара: «Сезнең әхлак һәм хокук турындагы күзаллауларыгыз искергән, болар һәммәсе дә — кирәксез әйберләр факультеты».

Вөҗданлылык һәм кеше хәленә керә белү тынычлыкны ала торган мәшәкать итеп каралырга тиеш түгел. Әсәр безне күпне күргән илебез тарихыннан сабак алырга өнди. Кешелеклелек кыйммәтләре бүген үзләренең гаять әһәмиятле икәнлеген раслады. Хокукый дәүләт төзелә башлагач, «кирәксез әйберләр»дән башка демократия, законлылык, гадел хөкем, шәхес хокуклары проблемалары буенча яңа фикерләр формалаштырып булмый.

Өченчедән, хокук культурасы гражданның үз тәртибен юридик нормалар күрсәтмәләренә туры килерлек итеп корырга омтылуында күренә. Бу тәртип законга буйсынып яшәүдә генә түгел, кешенең законнарны үзе дә бозмавында, башкаларга да аларны бозарга ирек бирмәвендә чагыла.

Хокук культурасы — тарихи тәҗрибә, социаль берлекләрнең һәм аерым кешеләрнең хокук өлкәсендәге хәтере, аларның хокук тәртибенә йогынты ясый торган кыйбласы. Илебезнең тарихи культурасын, традицияләрен өйрәнү Россиядә хокукый аң һәм тәртип үзенчәлекләренең сәбәпләрен ачыкларга ярдәм итә. Бу яктан караганда россиялеләрнең диктат, абсолют монархия, тоталитаризм шартларында барлыкка килгән хокук культурасына демократик традицияләре булган халыкларның хокук культурасында өстенлек итүче сыйфатлар хас түгеллеге күренеп тора. Л. Н. Толстой болай дип яза: «Рус халкы, Европа халыклары белән чагыштырганда, хакимияткә һәрвакыт башкача караган. Хакимият белән ул беркайчан да көрәшмәгән һәм, иң әһәмиятлесе, беркайчан да хакимияттә катнашмаган. Рус кешесе һәрвакытта да хакимияткә кеше читләтеп үтәргә тиешле явызлык дип караган». Югары хокук культурасы формалашу процессы, бер яктан, мәдәни традицияләрнең «җитенкерәмәве» аркасында кыенлашса, икенче яктан, демократияләшү процессы хокукый дәүләтнең бер кисәге булган кешегә кирәкле культура сыйфатларын тудыруга һәм таратуга ярдәм итәргә тиеш. Демократик җәмгыять төзү югары хокук культурасы формалашуга да ярдәм итәчәк.

Хезмәт вазифалары буенча хокук куллану, хокук саклау эшчәнлеге белән шөгыльләнә торган урындагы кешеләрнең, дәүләт аппараты хезмәткәрләренең, хокук культурасы дәрәҗәсе аерым әһәмияткә ия. Иң беренче чиратта алар законга, гражданнарның хокукларына һәм ирекләренә хөрмәт белән карарга, үз эшчәнлекләре өлкәсендә юридик хәбәрдар булырга ти-

ешләр. Дәүләт хокук культурасының югары дәрәҗәдә булуын таләп итә, чөнки бу җәмгыятьтә хокук тәртибенең ныгуына, шәхси тормыштагы һәм җәмгыять тормышындагы төрле каршылыкларның мәдәни юл белән хәл ителүенә китерә.

Хокук культурасы төрле дәрәҗәдә була. Җәмгыять әгъзаларының хокук культурасы түбән булу законнарның үтәлүенә кире йогынты ясый һәм хокук нормаларының бозылуы, ягъни хокукый нигилизмның үсүе өчен уңдырышлы җирлеккә әверелә. Борынгы римлылар ук инде законга хөрмәт белән карауны тиз һәм ансат кына какшатып була, ә аның абруен торгызу кыен һәм газаплы икәнлеген яхшы аңлаганнар.

Табигый ки, хокукый культураның билгеле бер дәрәҗәсе кешегә тумыштан ук бирелми. Ул аңа хокук тәрбиясе барышында ирешә. Хокук культурасы — хокукый тормышның яңа факторларын һәм күренешләрен даими аңлау процессы ул. Хокукый культура дәрәҗәсе никадәр югары булса, җинаятьчел мохит йогынтысына эләгү яки җинаять кылу куркынычы шулкадәр азрак була. Россиядә гражданнарның хокук культурасын күтәрү проблемасы никадәр тизрәк хәл ителсә, хокукый дәүләт төзү шулкадәр уңышлырак булачак.

Сораулар һәм биремнәр: 1. Хокук культурасы нәрсә ул? **2.** Законнарны белми торып, гаделсезлек белән уңышлы көрәшеп буламы? **3.** Хокукый кыйммәтләр кешедән кешегә ни рәвешле тапшырыла? Гаилә, мәктәп, дин, массакүләм мәгълүмат чаралары, яшьләр оешмалары хокук идеяләрен һәм кыйммәтләрен тапшыруда нинди йогынты ясыйлар? Җинаятьчел яшүсмерләр төркемнәре хокук кыйммәтләрен тапшыра аламы? **4.** 5—6, 10—15, 16—17 яшьтәге балалар хокук турындагы мәгълүматларны ничек һәм ни дәрәҗәдә үзләштерә? Сезнеңчә, хокукка мөнәсәбәт ничә яшьләрдә формалаша? Баланы «бишектә чакта» тәрбияли башларга кирәк, юкса соң була, дигән сүзләрне сез ничек аңлыйсыз? **5.** Нинди вакытлы матбугатны карап барасыз (көн саен, даими, айга бер, атнага бер)? Нинди хокукый мәгълүматлар аласыз? Барлык бу басмаларда бер үк хокук актлары, аларның йогынтысы бер үк төрле бәяләнәме? Юк икән, ни өчен? **6.** 5—6 кешелек төркемнәргә бүленеп, 15 минут эчендә түбәндәге мәкальләрдә белдерелгән проблемаларның берәрсе буенча фикерләр әзерләгез: «Иелгән башны кылыч кисми», «Каракның бүреге яна», «Ике кулың ни эшләсә, ике иңең шуны күтәрер», «Кул кулны юар».

II бүлек

Конституция — Дәүләтнең Төп Законы

5. Россия Федерациясендә конституцион законнар чыгару тарихыннан

Конституция төшенчәсе һәм аның асылы. Бүгенге көндә Конституция дип без җәмгыятьнең һәм дәүләтнең иң югары юридик көчкә ия булган, иҗтимагый стройның нигезләрен билгеләүче, кеше һәм гражданның хокукларын һәм ирекләрен гарантияләүче, дәүләт идарәсе һәм территориаль төзелеше формасын, дәүләт хакимияте органнарының оештырылу һәм вәкаләт нигезләрен урнаштыручы Төп Законын аңлыйбыз.

«Конституция» сүзе латинча «constitutio»дан алынган, «төзү», «урнаштыру» дигәнне аңлата. Рим императорларының хокукый актлары шулай аталган. Конституциянең бүгенге төшенчәсе XVIII гасыр азагы — XIX гасыр башында буржуаз революцияләр барышында барлыкка килгән һәм формалашкан. Конституция дәүләтнең Төп Законы булып тора, ул җәмгыятьнең сәяси яшәү формасын, дәүләт хакимияте органнары системасын юридик яктан рәсмиләштерә, аларның формалашу тәртибен һәм эшчәнлек ысулларын билгели, кеше һәм гражданның хокукларын һәм ирекләрен беркетә. Конституция — хокук акты гына түгел. Ул бөтен җәмгыять өчен гаделлекнең әхлакый ориентирларын эченә ала.

Төп Закон буларак, конституция — дәүләтнең барлык башка институтларын бердәм структурага, бер бөтен системага берләштерә торган үзәк институты да ул. Менә ни өчен конституцияне илнең барлык сәяси-дәүләти тормышын көйләүче камертон дип атарга мөмкин.

Конституциядә җәмгыятьнең һәм дәүләтнең барлык тормыш рәвешен беренчел хокукый көйләү тәртибе бирелә. Шуңа күрә конституцион нормалар үзләренең эчтәлекләре буенча гомумиләштерелгән күрсәтмәләрдән торалар, ә практик тормышка ашырганда алар иҗтимагый мөнәсәбәтләргә, хокуклы һәм бурычлы субъектларның эшчәнлегенә киң планда йогынты ясыйлар. Конституцион көйләү предметы булып җәмгыять тормышының сәяси, икътисади, социаль һәм рухи өлкәләренең төп үзенчәлекләре исәпләнә.

Конституциянең асылы, аның кеше һәм җәмгыять өчен иң югары кыйммәте дәүләт хакимиятен хокукый чикләүдән,

аны билгеле бер хокукый кысалар эчендә тотудан гыйбарәт. Хакимият гамәлдәге Конституция кысалары белән чикләнгән дәүләтне конституцион яисә хокукый дәүләт дип атарга мөмкин.

Конституциянең, илнең Төп Законы буларак, аны башка норматив-хокукый актлардан аера торган берничә махсус юридик үзенчәлеге бар. Конституция югары юридик көчкә ия, ягъни ул илдәге норматив-хокукый актлар пирамидасын җитәкли, дәүләтнең Төп Законы буларак өстенлеккә ия. Аңа дәүләт органнары тарафыннан кабул ителә торган бер генә федераль закон да яки теләсә нинди башка норматив-хокукый акт та каршы килә алмый. Башка законнар конституцион положениеләрне үстерәләр генә, аларга каршы килергә тиеш түгелләр. Шуның белән законнарның бөтен системасы эчтәлек бердәмлегенә ирешә.

Федератив дәүләтләрдә, федераль Конституция белән беррәттән, Федерация субъектлары конституцияләре дә бар. Россия Федерациясендә конституцияләр РФ составындагы республикаларда бар, барлык башка субъектларның РФ Конституциясенең 5 статьясы буенча конституция дәрәҗәсендәге үз уставларын кабул итәргә хокуклары бар.

1993 елгы РФ Конституциясенә гомуми тасвирлама. Совет дәүләтендә конституцияләр 1918, 1924, 1936, 1977 елларда кабул ителде. Алар декларация төсендә булулары, «социализмның иҗтимагый строен» ныгытуга юнәлгәнлекләре белән аерылып тора, шуның белән бергә Советларның «тулы хакимиятен» игълан итә, дәүләтнең демократик төзелешен кире кага, партия һәм дәүләт хакимлегенең контрольсез диктатурасын тәэмин итә иде.

Россия Федерациясенең гамәлдәге Конституциясе 1993 елның 12 декабрендә бөтен халыкның тавыш бирүе (референдум) юлы белән кабул ителде. Теләсә кайсы илдә яңа конституция игълан ителү бу ил тарихында әһәмиятле яңа этап башлануын күрсәтә. Конституция яңа дәүләт төземе. Яңа конституция — дәүләт тормышы нигезләрендәге тирән үзгәрешләрнең көзгесе. Россия Конституциясе дә инде булып узган үзгәрешләрне ныгыту һәм яңаларына юл ачу өчен кабул ителде. Анда Россия дәүләтчелегенең бөтен тарихы барышында дәвамчанлык һәм Россия дәүләтенең бердәмлеге идеясе чагыла. Россия Федерациясе СССРның хокукый варисы булып тора, СССРда төзелгән күпсанлы халыкара килешүләр нәтиҗәсендә туган хокуклар һәм вазифалар аңа күчте.

Россия Конституциясе кереш өлештән (преамбула) һәм ике бүлектән тора.

Преамбулада Конституцияне кабул итү максатлары, шартлары, сәбәпләренең кыскача тасвирламасы бирелгән. Преамбула шактый дәрәҗәдә аның эчтәлеген дә билгели. Преамбуладагы положениеләрнең юридик нормалары юк. Әмма сәяси,

идеологик һәм хокукый яктан алганда алар зур әһәмияткә ия. Алар Конституциянең эчтәлеген һәм аның статьяларын дөрес аңларга һәм кулланырга ярдәм итәләр.

Преамбулада Конституция кабул итүгә сәбәп булган нигезләр һәм шартлар күрсәтелгән. РФ Конституциясе күпмилләтле халык тарафыннан кабул ителә, анда дәүләтнең төп бурычы булган максатлар атала: кеше хокукларын һәм ирекләрен раслау, гражданнарның иминлеген һәм үзара татулыгын урнаштыру, тарих барышында урнашкан дәүләт бердәмлеген саклау, Россиянең суверен дәүләтчелеген торгызу, Россия дәүләтенең демократик нигезләрен ныгытуны, Россиянең иминлеген һәм чәчәк атуын тәэмин итү.

Төп өлеш асылда Конституциянең текстын тәшкил итә. РФ Конституциясендә дәүләт хакимиятен оештыру нигезенә хакимиятләрнең бүленеше идеясе салынган яңа концепция беркетелә, анда дәүләтне оештыру һәм аның эшчәнлегенең төп принциплары раслана.

1 статьяда Россия Федерациясе идарә итү формасы республика булган демократик федератив хокукый дәүләт дип күрсәтелә. Моны ничек аңларга?

«Хокукый дәүләт» төшенчәсе дәүләт төзелешендә һәм эшчәнлегендә хакимият башындагы кешеләрнең бернигә дә нигезләнмәгән теләкләре түгел, ә Конституция тарафыннан беркетелгән хокукый принциплар һәм закон нормалары өстенлек итүен белдерә. Дәүләт үз хокукларына «бәйле» хәлгә куела, шуларга туры китереп эшләү бурычы ала. Әмма Россия дәүләтен хокукый дип тануны әле тормышка ашкан факт итеп түгел, беренчел дәрәҗәдәге хәл ителәсе мәсьәлә дип карарга кирәк.

«Республикачыл идарә итү формасы», «республика» төшенчәләре барлык югары дәүләт органнары халык тарафыннан сайлана яисә халык сайлап куйган органнар тарафыннан оештырыла, өстәвенә, сайлау һәм оештыру билгеле бер срокка гына була, дигәнне аңлата. Республика монархиядән шуның белән аерыла. Республикачыл идарә итү формасы Россиянең башында сайлап куелган Президент торган республика булуын күздә тота.

Демократия — халык хакимияте ул. Илдә хакимиятнең бердәнбер чыганагы — халык, аның ихтыяры һәм мәнфәгатьләре. Россия Федерациясе гражданнары дәүләт һәм җәмгыять эшләре белән идарә итүдә шәхсән үзләре дә, сайлап куелган законлы вәкилләр эшчәнлеге аша да катнаша алалар.

Россия Федерациясе 89 субъект җыелмасын тәшкил итә: 21 республика, 6 край, 49 өлкә, федераль әһәмияткә ия булган 2 шәһәр (Мәскәү һәм Санкт-Петербург), Еврей автономияле өлкәсе, 10 автономияле округ. Конституция федератив дәүләт буларак Россиянең территориясен һәм составын, Россия Федерациясе һәм аның субъектлары идарә итәргә тиешле

предметларны билгели, гомуми планда федерация субъектларының хокукый статусын беркетә, федераль хакимият белән федерация субъектларының хакимият органнары арасындагы үзара мөнәсәбәтләрне җайга сала. Бүгенге көндә РФ территориясе аның субъектлары территорияләреннән тора, болар: РФ составындагы республикалар, крайлар, өлкәләр, Мәскәү һәм Санкт-Петербург шәһәрләре, автономияле округлар, автономияле өлкә.

Конституция ил эчендә дә, халыкара мәйданда да дәүләт суверенитеты принцибын беркетә. «Суверенитет» сүзе «югары хакимият» дигәнне аңлата. Суверенитетның хокукый (юридик) чагылышы Конституциянең һәм законнарның илнең барлык территориясендә өстенлек итүендә, аларның барлык органнар, урындагы кешеләр һәм гражданнар өчен мәҗбүрилегендә күренә. Федераль хакимият Россия халкы исеменнән эш итәргә вәкаләтләре булган, дәүләтнең бөтенлеген, Россиянең сәяси һәм икътисади бәйсезлеген һәм аның чикләренең кагылгысызлыгын тәэмин итәргә сәләтле бердәм һәм бердәнбер югары хакимият булып исәпләнә.

Конституция Россия Федерациясен кешенең имин яшәешен һәм ирекле үсешен тәэмин итәрлек шартлар тудырырга тиешле социаль дәүләт дип таный; әгәр кеше үзенә бәйсез сәбәпләр аркасында үзен матди яктан тәэмин итә алмый һәм социаль яклаучысыз кала икән, ул очракта дәүләт аңа бушлай ярдәм күрсәтә. Дөрес, икътисадның тулысынча савыгуы шартларында гына дәүләттән мәдәниятле дәүләтләрдә эшләп чыгарылган стандартлар дәрәҗәсендәге социаль ярдәмгә исәп тотып була икәнлеген танырга кирәк.

Россия Федерациясендә икътисади эшчәнлекнең күп төрле формалары, милек формаларының төрлелеге һәм тигез хокуклылыгы, икътисади эшмәкәрлек һәм хезмәт иреге, аларны хокукый яклау, шулай ук гадел конкуренция һәм иҗтимагый файда тәэмин ителә, шул ук вакытта дәүләт хуҗалык тормышын кеше һәм җәмгыять мәнфәгатьләренә җайлаштырып көйли. Хосусый милек, дәүләт милке һәм муниципаль милек белән беррәттән, дәүләт тарафыннан таныла һәм яклана. Икътисади мөнәсәбәтләр кеше һәм дәүләт, хезмәткәр һәм эш бирүче, җитештерүче һәм кулланучының социаль партнерлыгы нигезендә төзелә. Күп партиялелек, идеологик күптөрлелек таныла.

Россия Федерациясендә кеше, аның гомере һәм сәламәтлеге, намусы һәм горурлыгы, шәхси кагылгысызлыгы һәм куркынычсызлыгы, хокуклары һәм ирекләре иң югары кыйммәт булып исәпләнә. Конституциядә, халыкара хокукның гомумтанылган нормаларына һәм принципларына төгәл туры китереп, шәхеснең хокукый хәле нигезләре, аның төп хокуклары, ирекләре һәм бурычлары, һәм шулай ук бу хокукларның һәм ирекләрнең гомуми юридик гарантияләре беркетелгән. Граж-

даннарның хокуклары һәм ирекләренең дәүләт мәнфәгатьләреннән өстенлеге раслана. Хокукларны һәм бурычларны җәмгыятькә каршы максатларда файдалану тыела. Дәүләт шәхес хокукларын һәм ирекләрен тайпылышсыз якларга һәм сакларга тиеш. Ул җәмгыятьнең аерым бер өлешенә түгел, бөтен җәмгыятькә хезмәт итә, кеше һәм граждан алдында җаваплы булып исәпләнә.

Алга таба Конституциядә дәүләт хакимияте федераль органнарының төзелү тәртибе һәм хокукый статусы билгеләнә: Россия дәүләте башлыгы буларак Президент статусы, илнең иң югары вәкиллекле һәм закон чыгаручы органы буларак Федераль Җыелыш (парламент) статусы, башкаручы хакимиятнең иң югары органы буларак Хөкүмәт статусы, суд эшчәнлеген гамәлгә ашыруның төп принциплары, суд системасын һәм прокуратура органнарын оештыру нигезләре. Конституция җирле үзидарәне оештыруның төп принципларын урнаштыра.

Конституцияләр озак срокка исәпләнгән шактый тотрыклы хокукый акт булып исәпләнсәләр дә, тормыш еш кына үзгәрешләр, яңадан караулар, хәтта юкка чыгарулар да таләп итә. Мондый гамәлләрнең тәртибе яхшы уйланылган булырга тиеш. Махсус бүлек конституциягә үзгәрешләр һәм төзәтмәләр кертү яисә, аны тамырдан үзгәртеп, яңа Төп Закон кабул итү тәртибен билгели. Бу конституциягә юридик тотрыклылык һәм ныклык бирә, аңа парламент аша сәясәтчеләрнең зур булмаган төркеме тарафыннан нинди дә булса тамырдан үзгәрешләр кертү мөмкинлеген юкка чыгара.

Йомгаклау һәм күчеш положениеләре Конституциянең закон көченә керү тәртибен билгели, анда Конституцияне кабул иткәнчегә кадәр гамәлдә булган законнарны һәм башка норматив актларны куллану тәртибе күрсәтелә.

Россия Федерациясе конституцион төзелешенең нигезләре шундый. Конституция үтәләчәкме, аңа салынган демократик механизм эшләп китәчәкме икәнлеге бүген безнең һәрберебездән тора, икенче төрле әйткәндә, иртәгә безнең нинди илдә яшәячәгебез безнең үзебезгә бәйле. Россия Федерациясе куәтле хокукый дәүләт булырга тиеш.

Сораулар һәм биремнәр: 1. Конституцион-хокукый нормалар ярдәмендә нинди иҗтимагый мөнәсәбәтләр җайга салына? Конституция нәрсә ул? Конституциянең асылы нидән гыйбарәт? Конституциянең юридик үзенчәлекләре турында сөйләгез. 2. Россия Федерациясе Конституциясенең төзелеше нинди? Конституциянең преамбуласы нәрсә ул, һәм ул ни өчен кирәк? 3. Дәүләт һәм җәмгыятьнең Төп Законы буларак Россия Федерациясе Конституциясенең нинди төп үзенчәлекләре бар? 4. Нинди дәүләт конституцион дип атала? Конституцион төзелеш нәрсә ул? Россия Федерациясе конституцион төзелешенең нигезләрен нинди принциплар тәшкил итә? Аларның эчтәлеге нинди? РФ конституцион төзелеше ничек яклана?

6. Россия Федерациясендә дәүләт хакимияте органнары системасы

Дәүләт үзенең күпкырлы эшчәнлеген дәүләт органнары аша тормышка ашыра. Дәүләт хакимияте органы дигәндә без дәүләт аппаратының дәүләт-хакимият вәкаләтләре булган, үзенең вазифаларын билгеле бер тәртиптә тормышка ашыра торган аерымланган бер өлешен аңлыйбыз. Бу — кешеләр коллективы; кайчакта бер кеше — президент, губернатор булырга мөмкин.

РФ Конституциясенең 11 статьясы буенча Россиянең дәүләт хакимияте дәүләт башлыгы буларак Президент; закон чыгаручы хакимият буларак Федераль Җыелыш — парламент; башкаручы хакимият буларак Хөкүмәт тарафыннан; федераль судлар тарафыннан тормышка ашырыла.

Хакимиятләрнең бүленеше дәүләт органнарының берсе дә тулысынча дәүләт хакимиятенә ия түгел икәнлеген аңлата. Хакимиятләрнең бүленеше принцибын тормышка ашырып, хакимиятнең төрле тармагына караган дәүләт органнары үзләренең вәкаләтләрен мөстәкыйль рәвештә, үзара тәэсир итешеп һәм бер-берсен тигезләп тормышка ашыралар. Россия Федерациясенең дәүләт органнары системасы түбәндәгечә:

14 нче схема



Россия Федерациясе субъектларында дәүләт хакимиятен алар үзләре оештырган дәүләт хакимияте органнары тормышка ашыра. Аларда органнарның төрле рәвешле системалары барлыкка килгән: кайбер республикаларда президент вазифасы (мәсәлән, Татарстан) бар, башкаларында юк; кайбер крайларда һәм өлкәләрдә башкаручы хакимият башында губернатор тора. Мәскәү һәм Санкт-Петербург шәһәрләрендә башкаручы хакимиятне мэрлар җитәкли; закон чыгаручы һәм башкаручы органнарның вәкаләтләре, аларның урнашу тәртибе, эшчәнлекләрен оештыру һ. б. төрлечә. Россия Федерациясе Конституциясе мондый күп төрлелекне рөхсәт итә.

Президент. Илнең дәүләт хакимияте органнары системасында төп фигура булып Президент исәпләнә.

Россиядә Президент посты кертү турындагы карар 1991 елның 17 мартында референдумда бөтен халыкның тавыш бирүе нәтиҗәсендә кабул ителде. Беренче Президент сайлаулары шул ук елның 12 июнендә үткәрелде.

Президент илнең сәяси лидеры, парламентка, хөкүмәткә һәм хакимиятнең барлык башка органнарына карата үзенчәлекле югары координатор булып тора. Хөкүмәт башлыгы буларак, Президент Россия Федерациясе Конституциясенең, кеше һәм гражданның хокуклары һәм ирекләренең, Россия суверенитетының, аның бәйсезлеге һәм дәүләт буларак бөтенлегенең гаранты санала. Ул шулай ук дәүләт хакимияте органнарының килешеп һәм үзара ярдәм итешеп эшләвен тәэмин итә. Президент дәүләтнең тышкы һәм эчке сәясәтенең төп юнәлешләрен билгели, ил эчендә һәм халыкара мөнәсәбәтләрдә Россия Федерациясе исеменнән эш итә.

Президентның вәкаләтләрен түбәндәге төп төркемнәргә бүләргә мөмкин: закон чыгару инициативасына хокук; федераль законнарга кул кую һәм халыкка җиткерү; федераль законнарга кичектереп тору өчен вето салу хокукы; парламентка эчке һәм тышкы сәясәтнең төп юнәлешләре турында ел саен хат белән мөрәҗәгать итеп тору.

Президентның үзе кирәк тапкан мәсьәләләрне референдумга чыгарырга хокукы бар.

Президент дәүләт аппаратындагы барлык мөһим урыннарга кешеләр билгеләгәндә катнаша.

Президент Дәүләт Думасы ризалыгы белән Хөкүмәтнең рәисен билгели; аның тәкъдиме буенча Хөкүмәтнең барлык башка әгъзаларын билгели һәм эшләреннән азат итә; Хөкүмәт утырышларында рәислек итәргә һәм аның отставкасы турында карар кабул итәргә, Хөкүмәт кабул иткән актларны юкка чыгарырга хокукы бар. Президентның шулай ук федерация субъектларының башкарма хакимияте органнары актларын, аларның законлылыклары турындагы мәсьәлә тиешле суд тарафыннан хәл ителгәнчегә кадәр, гамәлгә кертмичә торырга хакы бар. Президент илнең Кораллы Көчләренең Югары Башкомандующие булып тора, Куркынычсызлык Советын төзи һәм

аңа җитәкчелек итә, хәрби һәм гадәттән тыш хәл игълан итә ала. Үз вәкаләтләренә кергән мәсьәләләр буенча Президент указлар һәм боерыклар чыгара.

Россия Федерациясе Президенты гомуми, тигез һәм турыдан-туры сайлау хокукы нигезендә яшерен тавыш бирү юлы белән 4 елга сайлана. Бер үк кеше дәүләт башлыгы урынына ике сроктан да артыкка сайлана алмый.

Россия Федерациясе Президенты кагылгысызлыкка ия. Аны бары тик дәүләткә хыянәт итсә яисә башка авыр җинаять эшләсә генә җавапка тартырга мөмкин.

Федераль Җыелыш. Россиядә хакимиятләрнең бүленеше принцибы нигезендә вәкиллекле һәм закон чыгаручы орган сыйфатында парламент — Федераль Җыелыш эшли. Федераль Җыелышның статусы Конституциянең 5 статьясында беркетелгән. Законнар чыгару хакимияте тулысы белән аның кулында. Президентның указлары һәм боерыклары, Хөкүмәт карарлары һәм башка норматив актлар Федераль Җыелыш кабул иткән федераль законнарга туры килергә, алар белән каршылыкка кермәскә тиеш.

Федераль Җыелыш ике палатадан тора. Түбән палата — Дәүләт Думасы — барлык Россия халкы мәнфәгатьләрен чагылдырырга тиеш. Ул профессиональ нигездә эшли торган 450 депутаттан тора, алар гомуми, тигез һәм турыдан-туры сайлау хокукы нигезендә яшерен тавыш бирү юлы белән 4 елга бер тапкыр сайлана. Югары палата — Федерация Советы — беренче чиратта, Россия Федерациясе субъектлары мәнфәгатьләрен чагылдыра. Аңа Россия Федерациясенең һәр субъектыннан икешәр вәкил керә: дәүләт хакимиятенең вәкиллекле һәм башкарма органнарыннан берәр вәкил.

Һәр палатаның үз вәкаләтләре бар. Палата утырышлары аерым үткәрелә. Уртак утырышлар РФ Президенты юлламасын, РФ Конституцион Суды юлламасын, чит дәүләт җитәкчеләренең чыгышларын тыңлау өчен уздырыла.

Дәүләт Думасы вәкаләтенә закон проектларын карау һәм кабул итү; Президентка РФ Хөкүмәте Рәисен билгеләргә ризалык бирү; Хөкүмәткә ышаныч мәсьәләсен хәл итү; РФ Үзәк банкы Рәисен билгеләү һәм эшеннән азат итү; амнистия игълан итү; эшеннән баш тарттыру максатында Президентка гаеп ташлау керә.

Федерация Советы Дәүләт Думасы кабул иткән закон проектларын хуплый яисә кире кага; субъектлар арасындагы чикләр үзгәрүен раслый; Президентның гадәттән тыш яки хәрби хәл кертү турындагы Указын раслый; РФ Кораллы Көчләрен аның территориясеннән читтә файдалану мөмкинлеге мәсьәләсен хәл итә; Президентны эшеннән читләштерә (азат итә); Конституцион суд, Югары суд, Югары Арбитраж суды судьяларын билгели.

Дәүләт Думасы һәм Федерация Советының уртак вәкаләтләренә дәүләт бюджетын кабул итү, халыкара килешүләрне

раслау һәм өзү, РФ Президентын срогыннан алда эшеннән азат итү керә.

Россия Федерациясе Хөкүмәте. Россия Федерациясендә башкарма хакимият Хөкүмәт тарафыннан тормышка ашырыла. Ул башкарма хакимиятнең федераль органнарының барлык системасын җитәкли. Аңа федераль министрлыклар, Россия Федерациясе комитетлары һәм дәүләт комитетлары керә. Моннан тыш, Россия Федерациясе вәкаләтендәге мәсьәләләр буенча һәм Россия һәм аның субъектларының бергәләп хәл итә торган мәсьәләләре буенча федераль башкарма органнар һәм федерация субъектларының башкарма органнары илнең башкарма хакимиятенең бердәм системасын барлыкка китерәләр, ягъни үзләренең эшчәнлекләрендә Хөкүмәткә буйсыналар.

Россия Федерациясе Конституциясенең алтынчы бүлегендә беркетелгән төп хөкүмәт вазифаларына һәм вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

илнең бюджетын эшләү һәм аның үтәлүен тәэмин итү;

бердәм икътисади һәм финанс сәясәте үткәрү;

федераль милек белән идарә итү;

илнең оборонасын, дәүләт куркынычсызлыгын һәм тышкы сәясәтне тормышка ашыруны тәэмин итү буенча чараларны үтәү;

культура, фән, мәгариф, сәламәтлек саклау, экология, социаль тәэминат өлкәсендә дәүләт сәясәтен үткәрү;

илдә җәмәгать тәртибен һәм законлылыкны тәэмин итә торган чаралар күрү;

Федераль Җыелыш законнарын, Президент указларын һәм боерыкларын тормышка ашыру.

Хөкүмәт үз вәкаләтләрен карарлар һәм боерыклар аша, шулай ук, үзенең закон чыгару инициативасына булган хокукын файдаланып, закон проектлары эшләү һәм аларны Дәүләт Думасына кертү юлы белән тормышка ашыра.

Россия Федерациясе Хөкүмәте Хөкүмәт Рәисеннән, аның урынбасарларыннан һәм федераль министрлардан тора. Хөкүмәт Рәисе Дәүләт Думасының ризалыгы белән Президент тарафыннан билгеләнә. Хөкүмәт Рәисе урынбасарларын һәм федераль министрларны Рәис тәкъдим итүе буенча Президент билгели. Мөстәкыйль рәвештә Рәис Россия Федерациясе хезмәтләре, агентлыклары һәм комитетлары җитәкчеләрен билгели.

Рәис Хөкүмәт эшчәнлегенең төп юнәлешләрен билгели һәм аның эшен оештыра.

Хөкүмәтнең вәкаләтләр срогы аны яңа сайланган Президент оештырганнан соң башлана һәм Россия Федерациясенең яңа сайлауларда сайланган Президенты тарафыннан яңа Хөкүмәт оештырылгач тәгәлләнә. Хөкүмәт вәкаләтләренең срогыннан алда туктатылуы Хөкүмәт отставкага киткән яки аңа Дәүләт Думасы тарафыннан ышанычсызлык белдерелгән очракта булырга мөмкин.

Суд хакимияте. Суд хакимиятенең төп вазифалары булып гадел хөкемне тормышка ашыру һәм дәүләтнең барлык башка органнары эшчәнлегендә законлылыкны контрольдә тоту санала. Гадел хөкем — конституцион, гражданлык, арбитраж, административ һәм җинаять судларында эшләрне карау һәм хәл итү буенча суд эшчәнлеге ул.

Барлык судларда да тикшерү эшләре ачык була, якларның ярышуы һәм тигезлеге нигезендә тормышка ашырыла. Судьялар бәйсез, алыштырылмыйлар һәм бары тик законга гына буйсыналар. Алар кагылгысыз һәм бары тик суд хөкеменең гаепләү карары закон көченә кергәч кенә, судьяның намусына һәм абруена тап төшерә торган гамәл кылынган очракта, шулай ук судьяның үлеме яки аның Россия гражданлыгын югалтуы нигезендә генә вазифаларыннан читләштерелә алалар.

Россиядә суд хакимияте оештыру ягыннан мөстәкыйль һәм дәүләт хакимиятенең башка органнарыннан бәйсез булган суд органнарының өч тармагы буларак эш итә. Россия Федерациясе суд хакимиятенең югары органнарына Конституцион суд, Югары суд һәм Югары Арбитраж суды керә.

Җирле үзидарә. Демократик хокукый дәүләт төзүне җирле үзидарә оештыру исәбенә дәүләт хакимиятен үзәкләштерүне бетерүдән башка күз алдына китереп булмый. Чыннан да, әле күптән түгел генә, юк кына сәбәп белән дә, рөхсәт алу өчен үзәккә мөрәҗәгать итәргә кирәк иде. Хәлбуки, җирле тормышның күп кенә мәсьәләләре урында, җирле үзидарә тарафыннан хәл ителергә тиеш.

Җирле үзидарә Россия Федерациясе тарафыннан таныла һәм гарантияләнә. Җирле үзидарә дигәннән без гражданнарның эшчәнлеген җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне мөстәкыйль хәл итү, муниципаль милеккә ия булу һәм аннан файдалану мөмкинлеге бирә торган итеп оештыруны аңлыйбыз.

Россиядә җирле үзидарә земстволар рәвешендә беренче тапкыр 1864 елда оештырыла. Россиянең гамәлдәге Конституциясен кабул иткәнчегә кадәр җирле тормышның барлык мәсьәләләре дәүләт хакимияте органнарының бердәм системасына кергән җирле Советлар тарафыннан каралды. 1990 елдан башлап кына җирле Советларны аерып чыгарырга һәм аларны җирле үзидарә органнары итәргә омтылышлар булды.

Әлеге халык хакимияте формасының әһәмияте шунда ки, граждан теге яки бу территориядә көн саен килеп чыга һәм аңа кагыла торган проблемаларны хәл итүдә турыдан-туры катнашу хокукына һәм мөмкинлегенә ия була.

Россия Федерациясе Конституциясе буенча, җирле үзидарә органнары структурасы халык тарафыннан мөстәкыйль рәвештә билгеләнә.

Җирле берләшмәләргә икътисади һәм финанс байлыгы бүлеп бирү мәсьәләсе дә әһәмиятле. Конституция «муниципаль милек», ягъни җирле үзидарә милке дигән махсус яңа төшенчә кертә. Муниципаль милек составына җирле берләшмә территориясендәге табигый байлыклар (җир, җир асты байлыклары, су, урман, хайваннар һәм үсемлекләр дөньясы), күчә һәм күчми торган милек, җирле бюджет акчалары керә. Җирле үзидарә органнары муниципаль милек белән мөстәкыйль рәвештә идарә итәләр, җирле бюджетны төзиләр, раслыйлар һәм тормышка ашыралар, җирле салымнар һәм җыемнар билгелиләр, җәмәгать тәртибен саклауны оештыралар, шулай ук җирле әһәмияткә ия булган башка мәсьәләләрне хәл итәләр.

Сораулар һәм биремнәр: 1. Нәрсә ул дәүләт хакимияте органы? Закон чыгаручы хакимият башкаручы хакимияттән ни белән аерыла? 2. Россия Федерациясендә дәүләт хакимиятен нинди органнар тормышка ашыра? Сезнең фикерегезчә, хакимиятләрнең бүленешенә ихтыяҗ бармы? 3. Россия Президенты посты кайчан кертелде? Дәүләт органнары системасында Президент нинди урын били? Аның конституцион статусы нинди? Россия дәүләте башлыгы буларак Россия Федерациясе Президентының төп вазифалары һәм вәкаләтләре нинди? Президентның башка дәүләт органнары белән үзара мөнәсәбәте ничек урнаштырыла? Президент вәкаләтләренең срогы нинди? 4. Федераль Җыелыш дәүләт органнары системасында нинди урын били? Аның конституцион статусы нинди? Федераль Җыелыш эшчәнлегенең структурасы һәм төп юнәлешләре нинди? 5. Россия Федерациясе Хөкүмәте ничек формалаша һәм үз эше өчен ул кем алдында җаваплы? Хөкүмәт нәрсә белән шөгыльләнә? 6. Суд хакимияте нәрсә ул һәм аның максаты нидән гыйбарәт? Судьяларның бәйсезлеге нәрсәдә чагыла һәм нәрсә белән гарантияләнә? 7. Суд хакимияте органнарына нинди органнар керә? Алар ничек формалаша? 8. Җирле үзидарә дип нәрсәне аңлыйбыз? Дәүләт һәм җәмгыять белән идарә итү системасында җирле үзидарә органнары нинди урын били? Җирле үзидарә органнары нинди мәсьәләләрне хәл итә? 9. Дәрескә әзерләнгәндә газеталардан мисаллар табыгыз: күптән түгел Федерация Советында, Дәүләт Думасында, Президент, Хөкүмәт, шулай ук җирле үзидарә органнары тарафыннан нинди мәсьәләләр каралган?

7. Татарстан Республикасы Конституциясе

Татарстан Республикасының дәүләт суверенитеты турындагы Декларация. Татарстан Республикасы үз территориясендә дәүләт суверенитеты игълан итүчеләр арасында беренчеләрдән булды.

Татарстанның автономияле республика статусы 80 нче еллар ахырында аның күпмилләтле халкының алга таба сәяси, икътисади, социаль һәм рухи үсеше мәнфәгатьләренә туры килми башлады. 1990 елның 30 августында ТАССР Югары Советы, халыкның үзбилгеләнүгә хокукын тормышка ашы-

рып, «Дәүләт суверенитеты турында» Декларация кабул итте. Шуның белән дәүләт суверенитеты игълан ителде һәм Татарстан АССР Татарстан Республикасы дип үзгәртелде. «Дәүләт суверенитеты турында»гы Декларация белән Татарстан Республикасы территориясендәге табигый байлыклар анда яшәүче халыкның милкенә тапшырылды, кеше һәм гражданның хокуклары һәм ирекләре, татар һәм рус телләренең тигез хокуклы дәүләт теле сыйфатында кулланылуы, шулай ук башка милләтләрнең телләрен саклау һәм үстерү гарантияләнде. Күпмилләтле республиканың дәүләт суверенитеты шулай ук Татарстан Республикасы Конституциясенең һәм законнарының аның бөтен территориясендә өстенлеген һәм Татарстан Республикасының Россия Федерациясе һәм башка республикалар белән тигез хокуклы шартнамәләр әзерләүдә һәм төзүдә катнашу хокукларын ныгытуда да чагылыш тапты. 30 август республикада бәйрәм буларак билгеләп үтелә һәм ял көне итеп исәпләнә.

Татарстан Республикасы Конституциясе — хокукый дәүләтнең Төп Законы. Татарстан Республикасы Конституциясе республиканың «Дәүләт суверенитеты турында»гы Декларациясенең иң мөһим положениеләрен исәпкә алып эшләнде һәм 1992 елның 6 ноябрендә кабул ителде. Бу көн республикада бәйрәм көне дип игълан ителде.

Татарстан Республикасы Конституциясе — суверен дәүләтнең Төп Законы ул. Татарстан Республикасының күп милләтле халкы ихтыярын чагылдырып, Конституция дәүләт суверенитетын Татарстан Республикасының аерылгысыз һәм асыл билгесе дип игълан итте һәм төп бурычны — демократик, хокукый дәүләт төзү бурычын беркетте.

Хокукый дәүләт төзү җәмгыятьнең, шәхеснең һәм дәүләтнең тигез хокуклы хезмәттәшлегенә нигезләнергә тиеш. Халыкара хокукның гомумтанылган принциплары һәм нормаларының, кеше хокуклары өлкәсендә төзелгән халыкара килешүләрнең өстенлеге игълан ителде. Татарстан Республикасы Конституциясе шул ук вакытта кеше һәм гражданның төп хокуклары һәм ирекләре исемлеген сизелерлек киңәйтте.

Татарстан Республикасында дәүләт аппаратын оештыру һәм аның эшчәнлеге хакимиятләрнең бүленеше принципларына яраклаштырып тормышка ашырыла. Беренчедән, Татарстан Республикасы Дәүләт Советыннан башлап халык депутатларының җирле Советларына кадәр, дәүләт хакимиятенең вәкиллекле органнары системасы; икенчедән, Татарстан Республикасы Президентын, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетын, дәүләт идарәсе органнарын, җирле администрацияне кертеп, дәүләт хакимиятенең башкарма органнары системасы, өченчедән, Татарстан Республикасының Конституцион Судыннан, Татарстан Республикасының Югары Судыннан, Татарстан Республикасының Югары Арбитраж Судыннан, шәһәр, район судларыннан торган суд органнары системасы эшли.

Барлык органнарның эшчәнлеге законнар өстенлеген исәпкә алып тормышка ашырыла. Барлык дәүләт органнары һәм урындагы кешеләр аларны тайпылышсыз үтәргә һәм закон нигезендә һәм шуңа яраклаштырып эш итәргә тиеш.

Республиканың өстенлеге, мөстәкыйльлеге һәм бәйсезлеге Татарстан Республикасы Дәүләт Советының, Татарстан Республикасы Президентының, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының конституцион вәкаләтләрендә чагылыш тапты. Бу турыда без сезнең белән алдагы параграфта җентекләбрәк сөйләшербез.

Республиканың хокукый статусының алга таба үсеше **Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары белән Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасындагы вәкаләтләрне һәм ике якка да караган эшләрне тапшырышу турындагы** 1994 елның 15 февралендә кул куелган һәм 1994 елның 25 февралендә үз көченә кергән шартнамәдә чагылыш тапты. Шартнамәнең әһәмияте Россия һәм Татарстан арасындагы дәүләти-хокукый мөнәсәбәтләргә ачыклык кертүдән гыйбарәт. Шартнамә ике дәүләтнең үзара мөнәсәбәтләре принципларын билгели, Россия һәм Татарстанның вәкаләтләрен аныклый, килешүнең положениеләрен тормышка ашыру һәм яклау механизмнарын ныгыта. Үзара бәйләнеш принципларына Шартнамә халыкларның үзбилгеләнүгә хокукын, тигез хокуклылык, ихтыяр белдерү ирекен, территориаль бөтенлекне, икътисади пространство бердәмлеген саклауны; тарихи һәм милли традицияләрне, культуралар һәм телләрне саклау һәм үстерүне; гражданнарның иминлеген һәм милләтара ризалыкны, халыклар куркынычсызлыгын тәэмин итүне; кеше һәм гражданның, аның милләтенә, диненә, тору урынына һәм башка аерымлыкларына бәйсез рәвештә, төп хокуклары һәм ирекләре өстенлеген кертә.

Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының ике якка да караган эшләр исемлеге Россия Конституциясе билгеләгән исемлектән шактый аерыла. Суверенитет һәм территориаль бөтенлекне яклау вәкаләтләре; гражданлыкның гомуми һәм коллизион мәсьәләләре; бәя сәясәтен координацияләү; региональ үсеш фондларын оештыру; акча сәясәтен үткәрү; гомуми энергетика системасы, магистраль, тимер юл, труба үткәргеч, һава һәм су транспортлары, элемтә, мәгълүмат системалары белән идарә итүне яраштыру һәм башка вәкаләтләр бергәләп тормышка ашырыла.

Татарстанга гына караган эшләргә нәрсәләр керә соң? Дәүләт хакимиятенең республика органнары:

1) кеше һәм гражданның хокукларын һәм ирекләрен яклауны тәэмин итәләр;

2) республика бюджетын төзиләр, республика салымнарын билгелиләр һәм түләтәләр;

3) адвокатура һәм нотариат мәсьәләләрен хәл итәләр;

4) административ, гаилә, торак мәсьәләләрен, әйләнә-тирә мохитне саклау һәм табигатьтән файдалануны хокукый җайга салу эшен тормышка ашыралар;

5) Татарстан Республикасы судлары тарафыннан хөкем ителгән кешеләрне ярлыкауны тормышка ашыралар;

6) федераль милек объектларын кертмичә, Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан һәм бары тик Татарстан халкының гына байлыгы һәм милке булып исәпләнгән җир, җир асты байлыклары, су, урман һәм башка табигый байлыклар, шулай ук дәүләт предприятиеләре, оешмалары, башка күчемсез дәүләт милкен биләү һәм файдалану мәсьәләләрен хәл итәләр. Дәүләт милкен аныклау аерым Килешү ярдәмендә эшләнә;

7) Татарстан Республикасы дәүләт органнары системасын, аларның оешу һәм эшләү тәртибен урнаштыралар;

8) республика гражданлыгы мәсьәләләрен хәл итәләр;

9) федераль закон буенча хәрби хезмәт үтүне алыштырырга хокукы булган гражданнарның Татарстан Республикасы территориясендә альтернатив гражданлык хезмәте үтү тәртибен урнаштыралар;

10) Россия Федерациясендәге республикалар, крайлар, өлкәләр, автомномияле өлкә һәм автономияле округлар, Мәскәү һәм Санкт-Петербург шәһәрләре белән Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы Конституцияләренә, Шартнамәгә һәм Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасындагы башка килешүләргә каршы килми торган мөнәсәбәтләр урнаштыралар, шартнамәләр һәм килешүләр төзиләр;

11) чит дәүләтләр белән элемтәләр урнаштыралар һәм алар белән Россия Федерациясе Конституциясенә һәм халыкара йөкләмәләргә, Татарстан Республикасы Конституциясенә һәм Шартнамәгә каршы килми торган килешүләр төзиләр, тиешле халыкара оешмалар эшчәнлегендә катнашалар;

12) аерым килешүләргә туры китереп, Милли банк төзиләр;

13) мөстәкыйль рәвештә тышкы икътисади эшчәнлекне тормышка ашыралар. Тышкы икътисади эшчәнлек өлкәсендәге вәкаләтләрне аныклау аерым Килешү нигезендә тормышка ашырыла;

14) Татарстан Республикасының дәүләт милке булып исәпләнгән предприятиеләрдәге конверсия мәсьәләләрен (ягъни хәрби промышленность комплексын тыныч тормыш продукциясе, киң куллану товарлары чыгаруга күчерү) аерым Килешү нигезендә хәл итәләр;

15) Татарстан Республикасының республика бүләкләрен һәм мактаулы исемнәрен билгелиләр.

Шул рәвешчә, республиканың конституцион статусы аңа тотрыклы үсәргә, гражданнарының хокукларын һәм ирекләрен тәэмин итәргә мөмкинлек бирә.

Сораулар һәм биремнәр: 1. Татарстан Республикасының дәүләт суверенитеты турындагы Декларациянең нинди әһәмияте булды? Аның «Документаль материал» бүлегендә урнаштырылган текстын өйрәнегез, аның преамбуласына игътибар итегез: шартнамәне төзегәндә һәм аңа кул куйганда ике дәүләт җитәкчесе нәрсәгә таянып эш иткәннәр? **2.** Татарстан Республикасы Конституциясенә тасвирлама бирегез, моның өчен аның «Документаль материал» бүлегендә урнаштырылган текстыннан файдаланыгыз. **3.** Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының дәүләт хакимиятләре органнары арасында үзара вәкаләтләрне бүлешү һәм ике якка да караган эшләрне тапшырышу турындагы 1994 елның 15 февралендә кул куелган Шартнамә республиканың хокукый статусы үсешендә ничек чагылды? **4.** Дәрескә әзерләнгәндә Декларация, Конституция һәм Шартнамәнең ничек тормышка ашырылуы турында газеталардан мисаллар китерегез.

8. Татарстан Республикасында дәүләт хакимияте органнары системасы

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы. Республика дәүләт хакимиятенең югары вәкиллекле, законнар чыгаручы һәм контроль органы булып **Татарстан Республикасы Дәүләт Советы** — Татарстан Республикасы парламенты исәпләнә.

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы 130 халык депутатыннан тора. Дәүләт Советы сессияләре парламентта даими нигездә эшли торган депутатлар составында чакырыла. Мөһимрәк исәпләнгән мәсьәләләрне карау өчен, барлык сайланган депутатлар составында Дәүләт Советының пленар сессияләре чакырыла. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы эшчәнлегенең тәртибе Конституция һәм Дәүләт Советы Регламенты тарафыннан билгеләнә.

Дәүләт Советы вазифаларына республика Конституциясен кабул итү һәм аңа үзгәрешләр кертү; законнар кабул итү һәм аларга аңлатма бирү керә. Закон проектлары һәм дәүләт тормышының башка әһәмиятле мәсьәләләре бөтенхалык тикшерүенә куелырга мөмкин. Законнар татар һәм рус телләрендә кабул ителә һәм бастырып чыгарыла.

Дәүләт Советы эчке һәм тышкы сәясәтне билгели; республиканың иң мөһим икътисади һәм социаль үсеш программаларын, дәүләт бюджетын раслый, салымнарны һәм башка керемнәрне билгели, халык хуҗалыгы һәм социаль-культура төзелеше белән идарә итүне оештыра. Әйләнә-тирә мохитне саклау һәм табигый байлыклардан файдалану проблемаларын законлы төстә көйли. Ул дәүләт хакимияте һәм идарәсенең республика һәм җирле органнарын, җирле үзидарә нигезләрен оештыра, аларның эшләү тәртибен билгели, халык депутатларының җирле Советлары эшчәнлегенә җитәкчелек итә. Дәүләт Советы республикадагы административ-территориаль

төзелеш, яңа районнар һәм шәһәрләр барлыкка килү, аларны бетерү, Татарстан Республикасы чикләренең үзгәрүе белән бәйле рәвештә исем кую һәм исем алыштыру мәсьәләләрен хәл итә.

Дәүләт Советы Татарстан Республикасы халык депутатларын һәм җирле Советларның халык депутатларын, Татарстан Республикасы Президентын сайлауларны билгели.

Дәүләт Советы вәкаләтенә республика гражданнарының конституцион хокукларын һәм ирекләрен, Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче барлык милләт гражданнарының тигез хокуклылыгын тәэмин итү белән бәйле мәсьәләләрне карау, милли мәдәният, тел үсеше һәм тарихи һәйкәлләрне саклау турындагы мәсьәләләрне хәл итү, республика судлары тарафыннан хөкем ителгән кешеләргә амнистия бирү турында карарлар кабул итү; шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләрен, Татарстан Республикасының мактаулы исемнәрен булдыру керә.

Дәүләт Советы Татарстан Республикасының халыкара шартнамәләрен ратификацияли һәм гамәлдән чыгара.

Республика парламентына аңа Конституция һәм законнар тарафыннан йөкләнгән башка вәкаләтләрне тормышка ашыру да, шулай ук гомумреспублика күләмендәге әһәмияткә ия булган башка мәсьәләләрне хәл итү дә йөкләтелгән. Дәүләт Советы аңа хисап бирергә тиешле барлык дәүләт органнары эшчәнлеген күзәтә, үзе оештыра һәм сайлый торган органнарның, шулай ук үзе сайлый һәм билгели торган урындагы кешеләрнең хисапларын даими рәвештә тыңлый.

Дәүләт Советы эшен Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Президиумы оештыра. Президиум Дәүләт Советына хисап бирә. Президиумга Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе, Рәиснең урынбасарлары, Секретарь һәм Дәүләт Советы сайлаган халык депутатлары керә. Дәүләт Советы Президиумына Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе җитәкчелек итә.

Дәүләт Советы халык депутатлары арасыннан закон проектлары эшләрен алып бару, Дәүләт Советы карамагындагы мәсьәләләрне алдан карап чыгу һәм әзерләү, шулай ук законнарны һәм башка карарларны тормышка ашыруда ярдәм итү, дәүләт органнары һәм оешмалары эшчәнлеген контрольдә тоту өчен даими комиссияләр оештыра.

Татарстан Республикасы халык депутаты Дәүләт Советы утырышларында Татарстан Республикасы Президентына, Дәүләт Советы Рәисенә, Министрлар Кабинетына, Премьер-министрга, министрларга, Дәүләт Советы оештыра яисә сайлый торган башка органнар (судлардан кала) җитәкчеләренә рәсми таләп белән чыгарга хокуклы. Таләп ясалган орган яки урындагы кеше өч көн эчендә Дәүләт Советына телдән яисә, халык депутаты кирәк дип тапса, язма җавап бирергә тиеш.

Татарстан Республикасы халык депутатлары Дәүләт Советы ризалыгыннан башка җинаять җаваплылыгына тартылырга, кулга алынырга яисә суд тәртибендә салынган административ җәза чараларына тартылырга тиеш түгел.

Татарстан Республикасы Президенты. Татарстан Республикасының башында Президент тора. Президент шәхес хокуклары һәм ирекләренең, республикабыз суверенитетының, Конституцияне һәм законнарны үтәүнең, шулай ук халыкара шартнамәләрнең гаранты булып исәпләнә.

Татарстан Президенты булып утыз биштән дә яшь булмаган, сайлау хокукына ия булган, аның территориясендә кимендә ун ел даими яшәгән һәм дәүләт телләрен белгән республика гражданы сайлана ала.

Президент сайлау тәртибе махсус закон белән билгеләнә. Президент республика гражданнары тарафыннан биш ел срокка гомуми, тигез һәм турыдан-туры сайлау нигезендә яшерен тавыш бирү юлы белән сайлана. Президент постына кандидатлар саны чикләнми. Әгәр сайлаучыларның яртысыннан артыграгы катнашса, сайлаулар хакыйкый дип исәпләнә. Тавыш бирүдә катнашкан сайлаучыларның яртысыннан артыграгының тавышын җыйган кандидат сайланган булып исәпләнә.

Үз вазифаларына керешкәнче, Президент халыкка һәм Татарстан Республикасы Конституциясенә тугрылык анты кабул итә.

Татарстан Республикасы Президентының вәкаләтләре түбәндәге схемадан күренә:

15 нче схема

Президент — Татарстан Республикасы дәүләтенең башлыгы булып тора

Татарстан Республикасы гражданнарының хокукларын һәм ирекләрен, Татарстан Республикасының дәүләт суверенитетын, республиканың куркынычсызлыгын һәм территориаль бөтенлеген, аның территориясендә законлылыкны һәм хокук тәртибен; Татарстан Республикасының дәүләт идарәсе һәм Татарстан Республикасының Дәүләт Советы органнары системасының	Татарстан Республикасының дәүләт идарәсе органнары **системасын җитәкли**; җирле хакимият эшчәнлегенә **юнәлеш бирә**; Халык депутатлары Советлары белән килешеп, республика буйсынуындагы район һәм шәһәрләрнең хакимият башлыкларын **билгели һәм эшләреннән азат итә**; Татарстан Республикасы Дәүләт Советы	**Татарстан Республикасы Дәүләт Советына:** ел саен Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджет проектын, республиканың тышкы хәле турындагы докладны; Татарстан Республикасы Премьер-министры постына кандидатураны; Татарстан Республикасы министрлыкларын һәм дәүләт комитетла-

үзара бәйләнешен **тәэмин итә;**

хакимият башлыгы урынына сайлау өчен гражданнарга кандидатура (әгәр ул әлеге территория депутаты булмаса) **тәкъдим итә;**

халыкара мөнәсәбәтләрдә Татарстан Республикасы **исеменнән эш итә;**

Татарстан Республикасының чит дәүләтләрдәге һәм халыкара оешмалардагы вәкилләрен **билгели һәм кире чакырып ала;**

чит дәүләтләр белән **килешүләр төзи;**

чит дәүләтләрнең вәкаләтле вәкилләреннән ышаныч һәм чакыртып алдыру грамоталары **кабул итә;**

Татарстан Республикасы судлары тарафыннан хөкем ителгән кешеләрне ярлыкауны;

Татарстан республикасы законнары һәм Конституциясе тарафыннан салынган, шулай ук Татарстан Республикасының халыкара йөкләмәләреннән чыга торган башка вәкаләтләрне **тормышка ашыра;**

Татарстан Республикасының барлык территориясендә Конституция белән килешеп, Татарстан Республикасының Министрлар Кабинетын **төзи, аның составына үзгәрешләр кертә;**

Татарстан Республикасы Премьер-министрын һәм Министрлар Кабинеты әгъзаларын **эшләреннән азат итә;**

Татарстан Республикасы законнарына **кул куя;**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарларын һәм боерыкларын, республика буйсынуындагы район һәм шәһәр хакимиятләре башлыкларының актларын **юкка чыгара;**

Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре белән **бүләкли;**

Татарстан Республикасының халыкара бүләкләрен **булдыра** һәм **тапшыра;**

гражданнарның куркынычсызлыгын тәэмин итү максатларында, законга туры китереп, Татарстан Республикасында яки аның аерым урыннарында, кабул ителгән карарны шул вакытта ук Татарстан Республикасы Дәүләт Советына раслау өчен тәкъдим итеп, гадәттән тыш хәл кертә;

Татарстан Республикасы Дәүләт Советына Татарстан Республикасы Югары суды һәм Югары арбитраж суды судьяларын, шулай ук район (шәһәр) судлары судьяларын сайлау һәм беторү турында тәкъдимнәр;

Татарстан Республикасының Милли банкы рәисе постына кандидатура;

Татарстан Республикасы Конституцион судының персональ составының яртысын;

Татарстан Республикасының халык депутатларын сайлау буенча үзәк сайлау комиссиясе әгъзаларының яртысын һәм аның рәисен;

Татарстан Республикасы Прокуроры постына, Татарстан Республикасы Тикшерү комитеты рәисе постына кандидатлар **тәкъдим итә;**

шулай ук Татарстан Республикасы Дәүләт Советына аларны азат итү турындагы **тәкъдимнәр белән керә;**

Татарстан Республикасы тормышының иң мөһим мәсьәләләре турында **хәбәр итә;**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы һәм аның президиумы эшендә **катнашырга хокуклы**

ституция һәм законнар нигезендә һәм аларны үтәү йөзеннән, үз вәкаләтләре кысаларында, мәҗбүри көчкә ия булган **указлар һәм күрсәтмәләр чыгара;** әгәр Татарстан Республикасы Президенты тәкъдиме буенча Дәүләт Советы шундый карар кабул итмәсә, Президент Аппаратын **оештыра**	ларга тәкъдим итеп, **гадәттән тыш хәл игълан итә;** Татарстан Республикасы гражданлыгы һәм сәяси сыену урыны бирү мәсьәләләрен **хәл итә;** республика күләмендә халык тавыш бирүен (референдум) үткәрү турында **игълан итә**	

Президентның шәхесе кагылгысыз, аның намусы һәм дәрәҗәсе закон тарафыннан саклана. Президент үз вазифаларыннан, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары белән, Конституцияне бозган өчен азат ителергә мөмкин.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты — Татарстан Республикасы Хөкүмәте — республика дәүләт хакимиятенең башкаручы һәм идарә итүче органы. Министрлар Кабинеты Премьер-министрдан, аның беренче урынбасарларыннан, урынбасарлардан, министрлардан, дәүләт комитетлары рәисләреннән, республика дәүләт идарәсенең башка органнары җитәкчеләреннән тора.

Министрлар Кабинеты Президент һәм Дәүләт Советы алдында җаваплы. Яңа оештырылган Министрлар Кабинеты үз вәкаләтләре чорына эшчәнлек программасын Дәүләт Советы каравына тәкъдим итә һәм үзенең эше турында кимендә елына бер мәртәбә аның алдында хисап бирә. Дәүләт Советы Министрлар Кабинетына ышанычсызлык белдерергә һәм аны отставкага җибәрергә мөмкин.

Министрлар Кабинеты дәүләт идарәсенең барлык мәсьәләләрен хәл итәргә хокуклы, чөнки Конституция буенча алар Президент вәкаләтләренә керми. Үз вәкаләтләре кысаларында Министрлар Кабинеты түбәндәге эшләрне башкара:

1) республиканың икътисади һәм социаль үсеше буенча агымдагы һәм перспектив дәүләт программаларын, бюджет проектын эшли; дәүләт программаларын һәм бюджетны тормышка ашыру буенча чаралар күрә; республиканың, районнар һәм шәһәрләрнең комплекслы икътисади һәм социаль үсешен тәэмин итә; тышкы икътисади эшчәнлекне тормышка ашыра;

2) халыкның тормыш дәрәҗәсен күтәрүне, хезмәтен һәм сәламәтлеген саклауны тәэмин итү, фән һәм техника үсеше, табигатьне саклау һәм табигый байлыклардан рациональ файдалану буенча чаралар эшли һәм гамәлгә ашыра; банк, акча һәм кредит системаларын ныгыту, дәүләт страхованиесен, хисап һәм статистиканың бердәм системасын оештыру буенча чараларны тормышка ашырырга ярдәм итә; бәяләр билгеләү, хезмәткә түләү, социаль тәэминат буенча гомумдәүләт сәясәтен тормышка ашыра; промышленность, төзелеш, авыл хуҗалыгы предприятиеләре һәм берләшмәләре, транспорт һәм элемтә предприятиеләре, шулай ук республиканың дәүләт милкенә караган башка объектлар белән идарә итүне оештыра;

3) дәүләт мәнфәгатьләрен яклау, милекнең барлык формаларын һәм җәмәгать тәртибен саклау, гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен тәэмин итү һәм яклау буенча чараларны тормышка ашыра; дәүләт куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча чаралар күрә;

4) министрлыклар, дәүләт комитетлары һәм ведомстволар турындагы положениеләрне раслый; кирәк булган очракта хуҗалык һәм социаль-культура төзелеше эшләре буенча комитетлар, идарәләр һәм башка ведомстволар оештыра; җирле хакимият эшчәнлегенә юнәлеш бирә.

Министрлар Кабинеты карарлар һәм боерыклар чыгара һәм аларның үтәлешен тикшерә. Карарлар һәм боерыклар республиканың барлык территориясендә һичшиксез үтәлергә тиеш. Министрлар Кабинеты республика буйсынуындагы район һәм шәһәр хакимиятләре башлыкларының карарларын һәм боерыкларын туктатып тора ала; республика министрлыклары һәм дәүләт комитетларының, үз карамагындагы башка органнарның актларын юкка чыгарырга хокуклы.

Министрлар Кабинеты министрлыкларның, дәүләт комитетларының һәм үзенә буйсынган башка органнарның эшләрен берләштерә һәм юнәлеш бирә. Министрлыклар, дәүләт комитетлары һәм дәүләт идарәсенең башка органнары тиешле идарә тармаклары белән җитәкчелек иткәндә яки тармагара идарәне тормышка ашырганда Президентка һәм Министрлар Кабинетына буйсыналар.

Дәүләт хакимияте һәм идарәнең җирле органнары. Районнарда, республика буйсынуындагы шәһәрләрдә, шәһәр районнарында дәүләт хакимиятенең вәкиллекле органнары булып халык депутатлары Советлары тора.

Халык депутатларының җирле Советлары үз вәкаләтләре кысаларында җирле әһәмияткә ия булган барлык мәсьәләләрне, шул исәптән икътисад һәм социаль-культура үсеше мәсьәләләрен мөстәкыйль рәвештә хәл итәләр, җирле бюджетны раслыйлар, җирле салымнар һәм җыемнарны билгелиләр. Җирле Советлар үз органнарын оештыралар, мөс-

тәкыйль рәвештә аларның структурасын һәм штатларын билгелиләр, Конституциягә һәм законнарга туры китереп карарлар кабул итәләр.

Халык депутатларының җирле Советлары карарлары халык депутатларының түбәнрәк торучы Советлары, җирле үзидарә органнары, алар территориясендәге барлык предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар, урындагы кешеләр һәм гражданнар тарафыннан мәҗбүри үтәлергә тиеш. Халык депутатларының түбәнрәк торучы Советларының закон боза торган карарлары югарырак торучы Советлар тарафыннан юкка чыгарылалар.

Халык депутатларының җирле Советлары депутатлар арасыннан җирле Советлар карамагындагы мәсьәләләрне алдан карау һәм хәзерләү, шулай ук Советларның карарларын тормышка ашырырга булышу, Советларга буйсына торган органнарның, предприятиеләрнең, учреждениеләрнең һәм оешмаларның эшчәнлеген контрольдә тоту өчен даими комиссияләр төзиләр.

Районда, шәһәрдә, шәһәр районында идарә итү эшен законнар нигезендә Дәүләт Советы, Президент һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, җирле Советлар карарлары нигезендә һәм аларны үтәү йөзеннән җирле администрация башкара.

Җирле хакимият, Советның башкаручы-идарә итүче органы буларак, гражданнарның хокукларын, ирекләрен һәм законлы мәнфәгатьләрен саклауны тәэмин итә; үз карамагындагы территориянең комплекслы икътисади һәм социаль үсешен тәэмин итү буенча чаралар күрә; үз карамагындагы предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар белән җитәкчелек итә; шул территориядәге дәүләт органнары, иҗтимагый берләшмәләр, предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар эшчәнлеген үз вәкаләтләре кысаларында координацияли һәм контрольдә тота; законда каралган башка вазифаларны тормышка ашыра.

Җирле администрация халык депутатларының тиешле җирле Советы һәм югарыдагы башкаручы һәм идарә итүче органнар алдында хисап бирергә тиеш.

Җирле хакимият эшчәнлеге белән администрация башлыгы җитәкчелек итә. Районның, республика буйсынуындагы шәһәрнең администрация башлыкларын тиешле халык депутатлары Советы ризалыгы белән Татарстан Республикасы Президенты билгели, яисә, әгәр ул әлеге территориянең депутаты булып тормаса, Президент тәкъдиме белән гражданнар тарафыннан сайлап куела. Уртак административ үзәге булган административ-территориаль берәмлекләрдә Президент карары белән бер хакимият башлыгы билгеләнергә мөмкин.

Җирле хакимият башлыгы үз вәкаләтләре чикләрендә карарлар һәм боерыклар чыгара. Җирле хакимият башлыгының

законнарга каршы килә торган актлары халык депутатлары Советы, югарыдагы башкаручы-идарә итүче орган яисә суд тарафыннан юкка чыгарылырга мөмкин.

Җирле үзидарә шәһәр, авыл җирләрендә һ. б. территорияләрдә тормышка ашырыла һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне, законга туры китереп, җирле үзенчәлекләрне һәм традицияләрне исәпкә алып, халык белән бергә мөстәкыйль хәл итүне тәэмин итә. Җирле үзидарә гражданнар тарафыннан референдум, сайлаулар, турыдан-туры үз ихтыярларын белдерү юлы белән, сайлау органнары һәм җирле үзидарәнең урындагы кешеләре аша тормышка ашырыла.

Җирле үзидарә органнары дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнары системасына керми.

Җирле үзидарәнең икътисади базасын җирле үзидарә милке тәшкил итә. Җирле үзидарә органнары җирле үзидарә милке белән мөстәкыйль рәвештә идарә итәләр, җирле бюджетны төзиләр, раслыйлар, үтиләр, җирле салымнарны һәм җыемнарны билгелиләр, җәмәгать тәртибен саклауны тормышка ашыралар, шулай ук җирле әһәмияткә ия булган башка мәсьәләләрне хәл итәләр. Җирле үзидарә органнарына закон буенча, тиешле матди һәм финанс чаралары белән бергә, аерым дәүләт вәкаләтләре дә бирелергә мөмкин. Әлеге вәкаләтләрне тормышка ашыру дәүләт тарафыннан контрольдә тотыла.

Татарстан Республикасында җирле үзидарә суд яклавы, дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнары кабул иткән карарлар нәтиҗәсендә барлыкка килгән өстәмә чыгымнарны компенсацияләү хокукы белән гарантияләнә. Җирле үзидарә органнарының Конституция һәм законнарга каршы килә торган актлары суд тәртибендә юкка чыгарыла.

Сораулар һәм биремнәр: 1. ТР Дәүләт Советы ничек формалаша? Аның вәкаләтләре нинди? Сез Дәүләт Советы депутатларыннан кемнәрне беләсез? 2. Ни өчен без Президент — дәүләт башлыгы дип әйтәбез? Бу положениене Татарстан Республикасы мисалында карагыз. 3. ТР Министрлар Кабинеты конкрет нинди эшләр белән шөгыльләнә? 4. Җирле үзидарә органнары эшчәнлеге дәүләт идарәсе органнары вәкаләтләреннән ни белән аерыла? 5. Татарстан Республикасының беренче Президенты М. Ш. Шәймиев турында чыгыш әзерләгез.

9. Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының хокук саклау органнары системасы

Барлык дәүләт органнары, үзләренең төп бурычларын тормышка ашыру белән беррәттән, төрле формада хокук тәртибен һәм законлылыкны саклыйлар. Кайсыларын хокук саклау органнарына кертергә мөмкин, ә кайсыларын — юк? «Хокук саклау органнары» дигән сүз аларның хокукый кур-

сәтмәләрне якларга, җәмгыятьтә законлылыкны һәм хокук тәртибе режимын сакларга тиешлеген күрсәтә.

Шулай итеп, хокук саклау органнары — хокукый дәүләт нигезләрен, законлылыкны һәм хокук тәртибен ныгытуны, кеше хокукларын һәм ирекләрен, аның гомерен, сәламәтлеген, намусын, абруен, милкен саклауны, шулай ук РФ Конституциясендә һәм ТР Конституциясендә беркетелгән иҗтимагый стройны, аның икътисади һәм сәяси системасын, дәүләт һ. б. предприятиеләрнең, учреждениеләрнең һәм оешмаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен саклауны, хокук бозуларны кисәтүне һәм булдырмауны, шулай ук хокук бозучыларга карата юридик яктан басым ясауны максат итеп куйган махсус вәкаләтле дәүләт органнары ул.

Шулардан чыгып, хокук саклау органнарына түбәндәге органнарны кертергә мөмкин:

16 нчы схема



Суд органнары. Россия Федерациясенең Конституцион Суды федераль законнарның, Россия Федерациясе Президенты, Федераль Җыелыш палаталары һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең норматив актларының, Россия Федерациясе субъектлары конституцияләренең, уставлары һәм норматив актларының, халыкара шартнамәләренең Россия Федерациясе Конституциясенә туры килүе турындагы эшләрне, хакимиятнең федераль органнары арасындагы, алар белән федерация субъектларының дәүләт хакимияте органнары арасындагы, федерация субъектлары дәүләт хакимиятенең югары органнары арасындагы вәкаләтлелек турындагы бәхәсләрне хәл итә; башка судлар тарафыннан билгеле бер эш каралганда, әгәр гражданның шикаяте һәм тиешле суд таләбе булса, бу очракта кулланыла торган законнарның конституционлыгын тикшерә; Россия Федерациясе Конституциясенә аңлатма бирә.

Гомуми юрисдикция судларына гомумгражданлык һәм хәрби судлар керә. Россия Федерациясенең Югары суды гражданлык, җинаять, административ һәм башка эшләр буенча иң югары суд органы булып тора. Ул аларның эшчәнлегенә суд күзәтүен оештыра, суд практикасы тәҗрибәсен өйрәнә һәм гомумиләштерә, суд статистикасын анализлый, суд практикасы, суд эшен башкару мәсьәләләре буенча аңлатма бирә. Үз вәкаләтендәге мәсьәләләр буенча Россия Федерациясенең Югары суды закон чыгару инициативасына ия. РФ Югары суды Югары суд Пленумы, Югары суд Президиумы, гражданлык һәм җинаять эшләре буенча суд коллегияләре, шулай ук хәрби коллегия составында эш итә.

Өченче тармакны арбитраж судлар тәшкил итә. Россия Федерациясенең Югары Арбитраж Суды икътисади бәхәсләрне хәл итү буенча иң югары суд органы булып тора һәм түбәнрәк торучы арбитраж судларның эшчәнлегенә суд күзәтүен оештыра, арбитраж практика мәсьәләләре буенча аңлатма бирә, суд статистикасын алып бара, икътисади эшчәнлек өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне көйләүче законнарны һ. б. норматив хокук актларын арбитраж судларның практикада ничек кулланууын өйрәнә һәм гомумиләштерә, шулай ук аның вәкаләтенә кергән башка мәсьәләләрне хәл итә. Арбитраж судлар системасына округларның федераль арбитраж судлары, республикаларның, крайларның, өлкәләрнең, федераль әһәмияткә ия булган шәһәрләрнең, автономияле өлкәнең, автономияле округларның арбитраж судлары керә (РФ субъектларының арбитраж судлары).

Югары Арбитраж суды түбәндәге составта эшли: РФ Югары Арбитраж суды Пленумы; гражданлык һәм башка хокук мөнәсәбәтләренә кагылган бәхәсләрне карау буенча суд коллегиясе; административ хокук мөнәсәбәтләренә кагылган бәхәсләрне карау буенча суд коллегиясе.

Татарстан Республикасында ТР Югары суды, ТР Югары Арбитраж суды эш итә. ТР Конституцион суды әле төзелмәгән,

аның урынына Конституция күзәтүе комитеты эшен дәвам итә.

Прокуратура органнары. Прокурор (латинча *prokuro* — кайгыртам, тәэмин итәм, кисәтәм) — законнарның төгәл үтәлүенә күзәтү оештыручы урындагы кеше. Россиядә прокуратура Петр I тарафыннан төзелгән. Ул аны «патшаның күзе» дип атаган.

РФ Прокуратурасының иң югары урындагы кешесе — РФнең Генераль прокуроры, Татарстанда — Татарстан Республикасы Прокуроры.

Прокуратура барлык органнарның, предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар, шулай ук гражданнарның законнарны төгәл һәм бер төрле үтәүләрен күзәтә. Прокуратура эшчәнлеге законның өстенлек итүенә, законлылыкны, кеше һәм гражданның хокукларын һәм ирекләрен, шулай ук җәмгыять һәм дәүләтнең закон тарафыннан саклана торган мәнфәгатьләрен ныгытуга юнәлтелгән.

Прокуратура РФ Генераль Прокуроры җитәкчелегендәге нык үзәкләшкән органнар системасын тәшкил итә. Генераль Прокурор Федерация Советы тарафыннан РФ Президенты тәкъдиме буенча билгеләнә. Генераль Прокурор республика (республикаларның иң югары органнары белән килешеп), край, өлкә, шәһәр һәм район прокурорларын билгели. Барлык бу прокурорлар җирле хакимияткә түгел, ә бары тик югарырак торучы прокурорга гына буйсыналар.

Прокуратура түбәндәге тармаклар буенча законнарның төгәл һәм бер төрле үтәлүен күзәтә:

17 нче схема

Федераль министрлыклар һәм ведомстволар, РФ субъектларының закон чыгаручы һәм башкаручы органнарының, җирле үзидарә органнарының, хәрби органнарның, контроль органнарның, аларның урындагы кешеләренең законнарны үтәвен, шулай ук алар чыгара торган хокукый актларның законнарга туры килүен күзәтү

Кеше һәм гражданның хокуклары һәм ирекләре үтәлүне күзәтү

Тармак — прокуратураның күзәтү эшчәнлегенең закон тарафыннан рөхсәт ителә торган юнәлеше

Җәзаны һәм суд билгеләгән мәҗбүр итү чараларын башкаручы органнар һәм учреждениеләр администрацияләренең, тоткыннарны сак астында тоту администрацияләренең законнарны үтәвен күзәтү

Оператив-эзләү эшчәнлеген, башлангыч сорау алуны һәм алдан тикшерүне тормышка ашыручы органнарның законнарны үтәвен күзәтү

Моннан тыш, прокуратура җинаятьчеләрне эзәрлекләүне тормышка ашыра. Куркынычрак җинаять эшләрен прокуратура тикшерүчеләре алып бара. Судта прокурор дәүләт гаепләүчесе сыйфатында чыгыш ясый.

18 нче схема



Прокуратура идарә һәм хуҗалык эшчәнлегенә тыкшынмый. Ул бары тик закон бозу турындагы хәбәрләр һәм мәгълүматлар нигезендә тикшерүләр генә үткәрә. Закон бозу факты буенча прокурор протест белдерергә, тәкъдимнәр кертергә, карарлар чыгарырга мөмкин. Протест хакимият органы яисә урындагы кеше тарафыннан кабул ителгән законсыз хокукый актларга карата белдерелә. Ул әлеге органга, яисә урындагы кешегә, яки судка белдерелә. Протестны карау нәтиҗәләре турында прокурорга язма формада хәбәр ителә. Закон бозуларны бетерү турындагы тәкъдимне прокурор тиешле органга, иҗтимагый, сәяси оешмаларга яисә урындагы кешегә кертә. Тәкъдим шунда ук каралырга һәм бер ай эчендә закон бозуларны бетерү буенча чаралар күрелергә тиеш. Җинаять эше кузгатылу, административ тәртип бозу һәм кайбер башка очраклар турында прокурор карар чыгара.

Эчке эшләр органнары. Эчке эшләр органнары законлылыкны һәм җәмәгать тәртибен саклыйлар, җинаять һәм башка хокук бозуларны кисәтәләр һәм бетерәләр, яшеренеп яшәүче кешеләрнең җинаятьләрен ачалар һәм эзлиләр, хөкем ителгәннәрне җәзага тартуны оештыралар.

Эчке эшләр органнары башкарма хакимиятнең дәүләт органнары системасын тәшкил итәләр. Бу системаның башында РФ Эчке эшләр министрлыгы тора. Бу системага криминаль милиция, җәмәгать куркынычсызлыгы милициясе (җирле

милиция), эчке гаскәрләр, янгыннан саклау органнары, җинаять җәзасын гамәлгә ашыру учреждениеләре, тикшерү изоляторлары һ. б. керә.

Үз вазифаларын үтәү өчен милиция хезмәткәрләренә билгеле бер хокуклар бирелгән: гражданнарның хаксыз гамәлләрен туктатуларын таләп итү һәм моңа көч ярдәмендә ирешү; штрафлар салу; хокук бозучыларны тоту һәм милиция бүлекчәсенә алып килү; аерым очракларда торак йортларга, производство, җәмәгать урыннарына керү; законда күрсәтелгән гадәттән тыш очракларда ату коралы куллану. Милиция хезмәткәрләренең законлы таләбен гражданнарның һәм урындагы кешеләрнең үтәве мәҗбүри. Бу таләпләрне үтәмәүчеләр юридик җаваплылыкка тартыла.

Милициянең тәртип саклау һәм җинаятьчелек белән көрәш буенча эше хәтәр, ул кыюлык һәм батырлык таләп итә.

Җинаять эше кузгату өчен нигез булып тора торган фактлар буенча милиция башлангыч сорау алу һәм алдан тикшерү үткәрә.

Башлангыч сорау алу — милиция хезмәткәрләренең җинаятьне кисәтү һәм үз вакытында ачу өчен алып бара торган оператив эзләү эшчәнлеге ул. Бу эшчәнлек һөнәри сер булып тора торган төрле ысуллар ярдәмендә алып барыла; шулай да аларның кайберләре, мәсәлән, җинаятьчел төркемгә агент җибәрү яисә хәбәр итеп торучыны яллау детектив кинофильмнар аша сезгә мәгълүм инде.

Алдан тикшерү үткәрелергә тиешле җинаять фактлары табылган очракта милиция, башлангыч сорау алып, җинаять эзләрен ныгыту, дәлилләрне саклау, шикле кешеләрне тоту һәм җинаять эше кузгату буенча барлык чараларны күрергә тиеш. Милиция кичектергесез тикшерү эшләрен башкара. Әгәр җинаять эше буенча алдан тикшерү үткәрелмәсә, башлангыч сорау алу чынлыкта тикшерү эше белән бергә кушыла һәм, алдан тикшерү кагыйдәләре нигезендә, башлангыч сорау алуны башлаган хезмәткәр тарафыннан башкарыла.

Куркынычсызлык органнары. Куркынычсызлык органнары илнең иминлегенә янаучы көчләр белән көрәш алып барырга тиеш.

Юстиция органнары. «Юстиция» сүзе үзе латин сүзе *justitia*дан чыккан, «гаделлек», «гадел хөкем» дигәнне аңлата. Бу термин, беренчедән, юрисдикцияне тормышка ашыручы яки аның белән идарә итүче (мәсәлән, Юстиция министрлыгы) барлык органнар җыелмасын, икенчедән, юрисдикцияне тормышка ашыручы органнар эшчәнлеген (судлар, арбитраж) аңлата. Юстиция органнары юстиция өлкәсендә дәүләт сәясәтен үткәрәләр. Аңа РФ составындагы республикаларның Юстиция министрлыклары, крайлар, өлкәләр, Мәскәү һәм Санкт-Петербург шәһәрләре, автономияле өлкә, автономияле округларның юстиция органнары керә. Бу органнарны РФ Юсти-

ция министрлыгы җитәкли. Министрлык каршында суд экспертизасының Россия федераль үзәге, хокукый мәгълүматның фәнни үзәге бар.

Юстиция органнары түбәндәге бурычларны башкара:

1) РФ Президенты һәм Хөкүмәтенең норматив актлар эшчәнлеген хокукый тәэмин итүдә катнашу;

2) Суд реформасы үткәрү өчен, гомуми юрисдикция һәм хәрби судлар эшчәнлеге өчен кирәкле шартлар тудыру;

3) Федераль башкарма хакимиятнең үзәк органнарының гражданнарның хокукларына, ирекләренә һәм законлы мәнфәгатьләренә кагылышлы норматив актларын яисә ведомствоара норматив актларны дәүләт күләмендә теркәү;

4) Иҗтимагый һәм дини берләшмәләрнең уставларын теркәү;

5) Юридик хезмәт системасын оештыру һәм үстерү. Мәсәлән, гражданнарга һәм юридик затларга мондый хезмәт эшчәнлеге алып бару өчен хокук лицензияләре бирелә;

6) Юстиция учреждениеләре һәм оешмалары кадрларының белем дәрәҗәсен күтәрү;

7) Гражданнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен саклау буенча халыкара-хокукый эшчәнлек;

Моннан тыш, министрлык гражданнарны хокукый агарту эшендә катнаша.

Нотариат органнары. Мөһим юридик һәм хокук саклау вазифаларын нотариат башкара. Нотариус (латинчадан тәрҗемә иткәндә «язу белән шөгыльләнүче, сәркатип» дигән сүз) үзенең имзасы һәм мөһере белән договорларны һәм башка килешүләрне раслый, мирас хокукларын рәсмиләштерә, документларның һәм аларның күчермәләренең юридик дөреслеген раслый. Мәсәлән, йорт сату һәм сатып алу шартнамәсе аны нотариус раслаган очракта гына көчендә була. Шулай ук васыятьнамә дә нотариус раслаганнан соң гына юридик көчкә ия дип исәпләнә. Мирас алу хокукы турындагы таныклыкны да нотариус бирә. Ниһаять, нотариус үзенең имзасы һәм мөһере белән төрле документларның, мәсәлән, урта белем турындагы аттестатның, туу турындагы таныклыкның күчермәләренең дөреслеген раслый. Шул ук вакытта нотариус үзе раслаган документларның законга туры килүен, мондый шартнамәләрнең рөхсәт ителәме, юкмы, якларның теге яки бу юридик гамәлләр кылырга хаклары бармы, юкмы икәнлеген бик яхшылап тикшерә. Мәсәлән, йорт сату һәм сатып алу шартнамәсен раслаганда, нотариус сатучының дөрестән дә йорт хуҗасы икәнлегенә яисә сату өчен башка юридик нигезләре барлыгына ышанырга тиеш.

Россиядә нотариат — дәүләт учреждениесе, ә нотариус дәүләт хезмәткәре булып тора. Хәзерге вакытта хосусый нотариаль конторалар эшчәнлеге дә рөхсәт ителә.

Сораулар һәм биремнәр: 1. Хокук саклау органнары системасына гомуми тасвирлама бирегез. Аңа нинди органнар керә? **2.** Прокуратура ничек оештырылган, һәм ул үз эшен ничек алып бара? **3.** Милициянең төп бурычлары нидән гыйбарәт? **4.** Россия Федерациясенең Юстиция министрлыгы нинди вазифалар башкара?

10. Җәмгыятьнең сәяси системасы

Сәяси система турында сөйләшкәндә без нәрсәне күздә тотабыз? Иң әүвәл берничә искәрмә хакында әйтеп үтәргә кирәк.

Беренче искәрмә. Сәясәт — кеше эшчәнлегенең аерым бер төре. Сәясәт — политика — грекчадан тәрҗемә иткәндә «дәүләт эшләре», «дәүләтне идарә итү сәнгате» дигәнне аңлата. Сәясәтче массалар белән, кешеләрнең төрле берләшмәләре белән эш итә. Алар табигатьләре белән генә түгел, мәнфәгатьләре буенча да бер-берсеннән аерылалар. Сәяси эшчәнлекне тормышка ашыру өчен төрле кораллар, институтлар таләп ителә. Мондый кораллар кешелек үсеше барышында барлыкка китерелгән: сәяси система, дәүләт.

Икенче искәрмә. Сәяси тормышның төрле төрләрен һәм үрнәкләрен ничек чагыштырырга? Җәмгыятьнең сәяси һәм сәяси булмаган өлкәләрендәге аермалыкларны, аларның үзара мөнәсәбәтләрен яхшырак аңлау өчен, аларга бербөтен итеп карарга кирәк. Моннан аерым бер төшенчәне — илнең «сәяси системасы» төшенчәсен тәгъбирләү кирәклеге килеп туа. Мәсәлән, Россиянең сәяси системасы, Татарстанның сәяси системасы. «Сәяси система» категориясе сыйныфларның сәяси мәнфәгатьләре, социаль төркемнәр, милләтләр арасындагы үзара мөнәсәбәтне, бәйләнешне ачыграк билгеләргә, тирәнрәк үтеп керергә, аларның мәнфәгатьләрен чагылдыручы сәяси күренешләрнең үзара мөнәсәбәтләрен һәм бәйләнешләрен аңларга мөмкинлек бирә.

Өченче искәрмә. «Система» сүзе нәрсәне аңлата? Бу — берберсе белән мөнәсәбәттә һәм бәйләнештә тора торган, билгеле бер бөтенлек хасил итүче кисәкләрдән, элементлардан төзелгән бөтенлек. Мисал итеп радиоалгычны китерик. Ул корпустан, төрле кисәкләрдән тора. Әгәр аларны аерым карасак, детальләр өеме генә күрербез. Ә билгеле бер механизмга, системага берләшкәч, алар радиодулкыннарны тота һәм тавыш чыгара алалар. Кыскача әйткәндә, җәмгыятьнең теләсә кайсы системасы, шул исәптән сәяси система да, бербөтен тәшкил иткән, тәртипкә салынган бик күп элементлардан тора. Бу элементларның үзара тәэсир итешүе аларның аерым кисәкләренә хас булмаган яңа сыйфат барлыкка китерә, ләкин ул кисәкләр барысы да соңгы максатка ирешүгә хезмәт итәләр.

Ә хәзер сәяси система төшенчәсенең үзенең ничек формалашуын карап үтик.

Җәмгыятьнең сәяси системасы — дәүләтне, илнең сәяси тормышында катнашучы һәм җәмгыятьтә хакимият урнаштырырга ярдәм итүче дәүләтнеке булмаган иҗтимагый оешмаларны бердәм комплекста карау ул. Сәяси системаның билгеләмәсен башкача аңлатырга да мөмкин: мәсәлән, ул — институтлар (дәүләт органнары, сәяси партияләр, иҗтимагый оешмалар һ. б.) җыелмасы, һәм аның кысаларында җәмгыятьнең сәяси тормышы бара һәм сәяси хакимият гамәлгә ашырыла; ул — сәяси хакимиятне оештыру һәм эшләтү механизмы.

Сәяси система төзелеше җәмгыятьнең билгеле бер сәяси оешмасы нинди элементлардан торуын белдерә. Андый элементлар күп. Сәяси системаның түбәндәге төп состав өлешләрен аерып күрсәтик:

сәяси оешмалар (дәүләт, сәяси партияләр, сәяси хәрәкәтләр, иҗтимагый оешмалар һәм берләшмәләр һ. б.);

сәяси мөнәсәбәтләр;

сәяси нормалар;

сәяси карашлар, концепцияләр, традицияләр.

Аларның үзара тәэсир итешүләрен түбәндәгечә күрсәтергә мөмкин:

19 нчы схема



Демократик җәмгыять тормышы нигездә дәүләттә туплана. Дәүләт күптөрле сәяси мәнфәгатьләрне үзендә җыйный. Ул, җәмгыять байлыкларыннан файдаланып һәм аның тормыш эшчәнлеген тәртипкә салып, «гомуммәҗбүри» призмасы аша идарә эшчәнлегенең төп өлешен башкара. Сәяси сис-

темада, аңа үзенә күрә бөтенлек һәм тотрыклылык биреп, дәүләт нәкъ менә шушы сыйфаты белән аерым бер роль уйный.

Җәмгыятьнең күпсанлы институтлары белән үзара тәэсир итешеп, дәүләт сәяси системаның үзәк өлеше булып тора, әйдәүче роль уйный, чөнки ул:

1) гражданлык билгеләре буенча үз территориаль чикләре эчендә берләшкән барлык халыкның бердәнбер рәсми вәкиле буларак чыгыш ясый;

2) суверенитетның бердәнбер иясе булып тора;

3) җәмгыять белән идарә итә торган махсус аппаратка (халык хакимияте) ия;

4) «көч куллану» структураларына (коралды көчләр, милиция, куркынычсызлык хезмәте һ. б.) ия;

5) хокук чыгару монополиясенә ия;

6) матди кыйммәтләрнең үзенчәлекле җыелмасына ия (дәүләт милке, бюджет, валюта һ. б.).

XX гасырга кадәр дәүләт асылда сәясәтнең бердәнбер коралы халәтен саклап килде. Хәзерге заман җәмгыятендә дәүләтнеке булмаган күпсанлы демократик институтлар да бар. Алар җәмгыять һәм дәүләт арасында арадашчы ролен үтиләр. Аларның бурычлары уртак — дәүләт хакимиятен яулап алу, тотып тору һәм файдалану. Мәсәлән, андыйларга сәяси партияләр, иҗтимагый берләшмәләр һәм хәрәкәтләр, мәгълүмат һәм пропаганданың дәүләтнеке булмаган органнары, иҗтимагый йогынты һәм тәрбия, иҗтимагый фикер институтлары керә. Алар дәүләтнеке булып исәпләнмиләр, ләкин аның эшчәнлегенә шактый зур йогынты ясыйлар. Бу оешмаларның сәясәт белән турыдан-туры элемтәсе аларның үзенчәлекле сыйфаты булып тора. Аларның төзелү һәм эшләвенең турыдан-туры максаты булып сәяси максат исәпләнә. Алар мәнфәгатьләрне җыярга, үзара килештерергә һәм соңыннан төрле сәяси программаларда, сайлауларда, хакимият органнарында вәкилләкләр системасы аша, иҗтимагый фикер механизмнары аша белдерергә һәм шул рәвешчә дәүләт сәясәтен формалаштыруга йогынты ясарга сәләтле. Күп партиялелек системасы җәмгыятьнең тотрыклылыгы факторы булып исәпләнә.

Әмма иҗтимагый берләшмәләр сәяси системага механик төстә түгел, билгеле бер рәвештә юридик яктан нигезләнгәннән, рәсми хокукый статус алганнан соң гына керәләр. Мәсәлән, массакүләм мәгълүмат чаралары һәм сәяси партияләр закон билгеләгән тәртиптә теркәлергә тиеш. Ә менә төрле җинаятьчел берләшмәләр, төркемнәр «сәяси система» төшенчәсенә кертелмиләр. Моннан тыш, сәяси булмаган берләшмәләрдән саналучы оешмаларны аерып күрсәтергә кирәк. Андыйларга икътисади һәм башка сәбәпләр аркасында барлыкка килә һәм үсә торган оешмалар керә. Болар — профсоюз, дини, коопера-

тив һәм башка оешмалар. Әлеге институтлар үзләренең эшчәнлекләрен сәясәттә түгел, ә җәмгыять тормышының җитештерү, социаль-көнкүреш, рухи һ. б. өлкәләрендә тормышка ашыралар. Аларның оешуы һәм эшчәнлегенең төп максаты сәяси максат түгел. Бик аз гына сәяси аспекты булган оешмалар да бар. Алар теге яки бу катлау кешеләрнең билгеле бер эшчәнлеккә һәвәслекләре нигезендә барлыкка киләләр һәм эшлиләр. Мондыйлар исәбенә спортчылар, филателистлар, туристлар һ. б. шундый берләшмәләрне кертергә мөмкин. Дәүләтнеке булмаган институтлар, шулай итеп, дәүләт белән бергә җәмгыятьнең тулаем сәяси тормышында үзара тәэсир итешүче, ә кайчак бер-берсенә каршы торучы, каршы көрәшүче звенолар тәзиләр. Сәяси системаны законнарда тормышка ашырылган сәяси идеяләрдән, шулай ук сәяси максатлары булган аерым гражданнар һәм кешеләр төркемнәренең билгеле бер гамәлләреннән башка күз алдына китереп булмый. Бу максатлар митингларда, җыелышларда, сайлаулар вакытында һ. б. чагыла.

Ахыр чиктә сәяси система дәүләт хакимиятеннән файдалану, анда катнашу, аның өчен көрәшү нигезендә социаль берлекләр арасында җитештерүне һәм социаль уңайлыкларны бүлешүне көйли.

Карап үтелгән система билгеләреннән чыгып, теләсә кайсы илгә төгәл сәяси тасвирлама бирергә, илләр арасындагы аермаларны күрергә мөмкин.

Ә Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикаларының сәяси системаларында нинди үзенчәлекләр күрергә мөмкин соң?

Россия Федерациясе — идарә итүнең республика формасы булган демократик федератив хокукый дәүләт. Татарстан Республикасы Конституция буенча суверен демократик дәүләт — республика. Алар тоталитар халәттән демократик халәткә күчү баскычында торалар. Күчеш авыр бара, эзлекле генә дә булып бетми. Әмма бу күчеш һәм дәүләтләрне үзгәртеп кору — вакыт таләбе, искегә кире кайту мөмкин түгел.

Россиядә һәм Татарстанда хакимиятнең өч тармагы аерым яши. Һәр ике республикада да — президент идарәсе. Җәмгыятьнең хакимияткә контрольлек итү мөмкинлеге хәзергә зур түгел, чөнки Россиядә дә һәм Татарстанда да гражданнар җәмгыяте формалашып кына килә. Яңа партияләр хәзергә халыкның сәяси тормышын активлаштыруда көчле чара булып өлгермәгән әле. Гражданнарның сәяси һәм хокукый активлыклары әллә ни зур түгеллеген танырга кирәк.

Әйдәгез, кыскача нәтиҗә ясыйк. Сәяси система ул — асылда җәмгыять белән идарә итү, ягъни хакимият системасы. Ул дәүләтне, сәяси режимны, сәяси хәрәкәтләр һәм партияләрне эченә алган, үзара шактый тыгыз бәйләнгән һәм буйсындырылган катлаулы структура булып тора. Шуңа күрә алар турында система буларак сүз алып барыла.

Сораулар һәм биремнәр: 1. «Система», «системалы якын килү» төшенчәләренең мәгънәсе нидән гыйбарәт? **2.** Ни өчен җәмгыятьнең сәяси характеры турында фикер йөртү кыен? **3.** Җәмгыятьнең сәяси системасы нәрсә ул? Җәмгыятьнең сәяси системасының төп элементлары нинди? Дәүләтне җәмгыятьнең башка сәяси оешмаларыннан нинди сыйфатлар аерып тора? **4.** Мәктәп сәяси институт булып торамы? **5.** Сәяси системаның сыйфаты кешеләрнең сәяси һәм хокукый культурасына бәйлеме? Ни өчен кешеләр партияләргә берләшә? Кайсы сәяси система демократиграк: бер сәяси партия булгандамы, әллә күп партияме? Ни өчен? **6.** Бүгенге Россия һәм Татарстан җәмгыятьләре сәяси системаларының нинди үзенчәлекләре бар?

III бүлек

Кешенең юридик хокуклары һәм бурычлары

11. Гражданның хокуклары һәм бурычлары нәрсә ул?

Кеше һәм гражданның хокуклары һәм ирекләре. Нинди дә булса бюрократ начальникның ветеран хокукларын бозуы турында газетадан укыганыгыз бардыр. Телевизордан кайсыдыр бер илдә кеше хокукларының тупас бозылуы хакында да күргәнегез һәм ишеткәнегез булгандыр. Ә укытучыгыз сезгә укучы бурычларын үтәмәвегез, дәрескә соңга калуыгыз турында әйтә. Гражданның хокуклары, ирекләре, бурычлары нәрсә соң ул? Иң әүвәл хокуклар һәм ирекләрнең нәрсә икәнлеген ачыклыйк. Кеше хокуклары — кешеләр белән дәүләт арасындагы үзара мөнәсәбәтләрнең кешегә үзе теләгәнчә эшләргә (хокукның бу өлешен гадәттә ирекләр дип атыйлар) яисә билгеле бер уңайлыклар алырга (бусы хокукның үзе) мөмкинлек бирүче нормалар ул.

Алар һәрвакытта да кешегә хас булганмы соң? Тарихка күз салыйк

Һәрбер халык хокукларны һәм ирекләрне үзенчә күз алдына китергән. Борынгы Афинада аларга бары тик ирекле шәһәр кешесе генә ия булган, коллар да, варварлар да (ягъни башка халыклар) кеше дип исәпләнмәгән, аларга хайваннарга карагандай караганнар. Борынгы римлылар колны «сөйли торган машина» дип кенә йөрткәннәр. Төньяк Америкадагы кара тәнле коллар шулай ук «кеше» дигән хокукый статустан мәхрүм булганнар. Россиядә крепостной крестьяннар 1861 елга, ягъни крепостной хокук бетерелгәнгә кадәр алпавыт ихтыяры белән генә яшәгәннәр, аңа шәхсән бәйле булып исәпләнгәннәр.

Кыскача әйткәндә, озак вакытлар дәвамында хокуклар һәм ирекләрдән халыкның бер өлеше генә файдаланган. Хәзерге заманның хокукый дәүләтендәгечә, бер яктан, кешенең хокуклары, ирекләре һәм аның бурычлары, икенче яктан, дәүләт

һәм җәмгыять мәнфәгатьләре арасында үзара бәйләнешкә ирешкәнче, күп гасырлар узган.

РФ Конституциясенең 17 статьясында «кешенең хокуклары һәм ирекләре аерылгысыз һәм алар аңа тумыштан ук бирелә» диелгән. Бу хокукларны һәм ирекләрне кайвакыт табигый хокуклар һәм ирекләр дип атыйлар, чөнки алар, законга язылганмы, юкмы икәнлегенә бәйсез рәвештә, кешегә тумыштан ук биреләләр, дәүләтнең ихтыярына һәм теләгенә карамыйлар. Алар гүя кешенең табигатенә салынган, алардан башка ул тулы канлы шәхес булып яши алмый. Россиядә яшәүче һәр кешегә хокуклар һәм ирекләр парламент яисә президент тарафыннан бирелми, ул аларга Россия җирендә туганлыгы һәм яшәгәнлеге аркасында ия. Төп хокуклар, ирекләр һәм бурычлар шәхестән аерылгысыз, димәк, какшамас. Какшамаслыкны таләп итү дәүләт өчен дә, кеше өчен дә бер үк дәрәҗәдә мәҗбүри. Төп хокукларның, ирекләрнең һәм бурычларның табигыйлеген игълан итеп, дәүләт шәхеснең бәйсезлеген һәм мөстәкыйльлеген, аның белән мөнәсәбәтләрдә суверенитетны таный, аларны төрле чаралар ярдәмендә саклауны үз өстенә ала.

Төп хокуклар һәм ирекләр — кешелек үсеше нәтиҗәсендә объектив рәвештә барлыкка килгән элементар, шәхеснең җәмгыятьтәге һәм дәүләттәге имин һәм ирекле яшәеше өчен гаять әһәмиятле уңайлыклар һәм шартлар. Дәүләт аларны Конституция билгеләгәнчә танырга һәм сакларга, якларга тиеш. Бу — кеше, җәмгыять һәм дәүләт арасындагы гаять әһәмиятле мөнәсәбәтләр.

Кешеләрнең хокукый хәле хокукның барлык тармаклары нормалары белән билгеләнә, хокуклар, ирекләр һәм бурычларның бердәмлеге белән характерлана. Әмма аларның нисбәте Россиядә яшәүчеләрнең барысы өчен дә бер төрле түгел. Халыкның ниндидер төркемнәренең хокуклары чикләнәме? Юк! Аңлаешлырак булсын өчен, әйдәгез, гражданлык төшенчәсен карап үтик, закон хокуклар, ирекләр һәм бурычлар күләменең нисбәтен нәкъ менә шуның белән бәйли.

Гражданлык — кешенең дәүләт белән тотрыклы хокукый элемтәсе, бу элемтә аларның уртак хокуклары, бурычлары һәм җаваплылыклары җыелмасында чагыла. Россия Федерациясе гражданнарына, Россия территориясендә яшәүче, ләкин граждан булмаган башка кешеләрдән аермалы буларак, сәяси хакимиятне тормышка ашыру өлкәсендә хокуклар бирелгән. Бары тик алар гына дәүләт хакимияте органнарына сайлый һәм сайлана, дәүләт аппаратында билгеле бер урын били, Ватанны саклау вазифасын үти ала һ. б. Россия дәүләте чит илдә яшәүче гражданнарын яклауны һәм саклауны гарантияли.

Гражданлык рәсми төстә шушы дәүләтнеке булуны гына түгел, аның эшләрендә катнашуны да белдерә. Нәкъ менә шуның өчен дә гражданга әлеге территориядә яшәүче, ләкин

гражданин булмаган башка кешеләр белән чагыштырганда зуррак хокуклар, ирекләр бирелә, бурычлар йөкләнә.

Хәзер исә түбәндәге нәтиҗәне ясарга мөмкин: кеше хокукларына Россия территориясендә яшәүче барлык кешеләр дә ия, алар дәүләт ихтыярына һәм теләгенә бәйле түгел. Гражданның хокуклары дәүләткә бәйле, ул кешенең теге яки бу дәүләткә каравыннан тора.

Кеше һәм гражданның төп хокуклары һәм ирекләре Россия Федерациясе Конституциясенең 2 нче бүлегендә һәм Татарстан Республикасы Конституциясенең 2 нче бүлегендә беркетелгән. Анда илебездә шәхес статусын билгеләүче гаять әһәмиятле принциплар чагылыш тапкан (20 нче схеманы карагыз).

20 нче схема

Россия Федерациясендә һәм Татарстан Республикасында шәхеснең хокукый хәле принциплары

- Кеше, аның хокуклары һәм ирекләре — дәүләтнең һәм җәмгыятьнең иң югары кыйммәтләре
- Төп хокукларның һәм ирекләрнең аерылгысызлыгы, аларның һәр кешегә тумыштан килүе
- Башка кешеләрнең хокукларын һәм ирекләрен хөрмәт итү
- Барлык хокукларның һәм ирекләрнең гарантияләнүе
- Кеше һәм граждан хокуклары һәм ирекләренең турыдан-туры гамәлдә булуы
- Юридик тигезлек

Төп хокуклар, ирекләр һәм бурычлар турыдан-туры гамәлдә булып исәпләнәләр. Бу билге шәхеснең төп хокукларын, ирекләрен һәм бурычларын тормышка ашыру механизмы аспектларының берсен ачып бирә. Төп хокукларның һәм ирекләрнең турыдан-туры гамәлдә булуы барлык дәүләт органнары һәм беренче чиратта суд органнары эшчәнлегенең максатын җәмгыять яисә дәүләт мәнфәгатьләре түгел, нәкъ менә кеше хокук-

лары һәм ирекләре билгеләргә тиеш икәнлеген белдерә. Бу — шәхеснең хокуклары һәм ирекләре бозылу белән бәйле булган билгеле бер эшне карау вакытында кирәкле хокукый акт булмаса яисә бу акт Конституция статьясына каршы килсә, суд яки эшне караучы башка орган, Конституциянең шәхес хокукларын яклаучы нормасын дәлил итеп китереп, карар чыгарырга тиеш дигәнне аңлата.

Юридик тигезлек принцибы һәммә кеше дә суд һәм закон каршында тигез икәнлекне һәм, бернинди социаль, милек, региональ һәм башка шартларга бәйсез рәвештә, тигез хокукка ия икәнлекне белдерә (РФ Конституциясенең 19 нчы статьясы, ТР Конституциясенең 20 нче статьясы).

Хокуклар һәм ирекләрнең гарантиялелеге принцибы аларны гомумсоциаль шартлар һәм шулай ук махсус юридик чаралар ярдәмендә тормышка ашыру һәм яклауны белдерә. Россия Федерациясе Конституциясе һәм Татарстан Республикасы Конституциясе гражданнарны дәүләт органнарының һәм урындагы кешеләрнең законсыз гамәлләреннән саклаучы хокуклар һәм ирекләрне тәэмин итә торган гомуми юридик шартлар, чаралар һәм ысулларны беркетәләр. Алар кешеләргә үзләренең хокукларын һәм ирекләрен тормышка ашырырга мөмкинлек бирәләр. Иң әүвәл бу дәүләтнең демократик, хокукый һәм социаль характеры, дәүләт аппаратын хакимиятләрнең бүленеше принцибы буенча төзү, милекнең барлык формаларының тигезлеге нигезендә икътисади эшчәнлек иреге принцибын тормышка ашыру. Моннан тыш, конституцион законлылыкны, хокукларның һәм ирекләрнең үтәлешен күзәтүче махсус органнар булу, шулай ук барлык суд системасы һәм башка хокук саклау органнары эшчәнлеге.

Кеше һәм гражданның хокуклары һәм ирекләре шартлы рәвештә биш төркемгә бүленә (21 нче схеманы карагыз).

21 нче схема

Хокуклар һәм ирекләрнең һәрбер төркеме кешенең тормыш эшчәнлегенең билгеле бер өлкәсен үз эченә ала, һәр кеше

кертә ала торган икътисади, социаль һәм мәдәни мөнәсәбәтләрнең күп төрлелеген чагылдыра. Россия Федерациясе Конституциясе һәм Татарстан Республикасы Конституциясе аларның эчтәлегенә һәм күләменә, кеше хокуклары өлкәсендәге халыкара стандартларга туры китереп, төзәтмәләр керттеләр, кеше һәм гражданның төп хокуклары һәм ирекләре системасындагы урыннарын үзгәрттеләр. Әлеге хокуклар һәм ирекләр төркемнәренең һәркайсы турында тулырак итеп 12—18 нче параграфларда сөйләрбез.

Кеше һәм гражданның бурычлары. Хокуклар һәм ирекләрне тормышка ашыру җәмгыятьнең нормаль үсеше өчен кирәкле бурычларны үтәүдән аерылгысыз. Хокуклар һәм ирекләрнең булуы аларны тормышка ашырганда чикләнмәгән башбаштаклык эшләргә яки законны бозарга мөмкин дигән сүз түгел. Атаклы Рим ораторы Квинтилиан (б.э.ның I гасыры) бу турыда болай дип әйткән: «Иреклелек һәм йөгәнсезлек — берберсенә бик нык каршы килә торган төшенчәләр». Берәүнең хокуклары һәм ирекләре бозылган урында һәм бозылган вакытта икенче берәүнең хокуклары һәм ирекләре бетә. Кешенең төп хокуклары һәм ирекләрендә аның мөмкин булган тәртибенең төре һәм чамасы чагылса, төп бурычларында тиеш булган тәртибенең төре һәм чамасы чагыла. Үзенең хокукларын бурыч дип кабул итү сәләте кешенең әхлакый үсеш дәрәҗәсе, башкалар хакына үз-үзен чикләргә әзерлеге турында сөйли.

Хокукларга һәм ирекләргә ия булу кешегә кайбер чикләүләр, җәмгыять һәм дәүләт алдында билгеле бер бурычлар йөкли дигән положениене күп кенә бөек фикер ияләре әйтеп калдырган. Француз мәгърифәтчесе Шарль Луи Монтескье (1689—1755) болай дигән: «Ирек ул — закон рөхсәт иткән һәммә нәрсәне дә эшләргә хокуклылык». Ә немец шагыйре Маттиас Клаудиус (1740—1815): «Ирек ул — башкаларга зарар китерми торган һәммә нәрсәне дә эшләү хокукы»,— дип язган. Бу — халыкара хокук документларында һәм Россия законнарында чагылыш тапты. 1789 елда, Бөек француз революциясенең башында, кабул ителгән Кеше һәм гражданның хокуклары декларациясендә: «...һәр кешенең табигый хокуклардан файдалану чиге — җәмгыятьнең башка әгъзаларының да шушы ук хокуклардан файдалануын тәэмин итә торган чик ул. Бу чикне бары тик закон гына билгели ала». Ә Кеше хокукларының гомуми декларациясенең (1948) 29 статьясы күрсәткәнчә, демократик җәмгыятьтә башкаларның хокукларын һәм ирекләрен тану һәм хөрмәтләүне тәэмин итүне, әхлаклылык, иҗтимагый тәртип һәм барлык кешеләр өчен дә мул тормыш таләп итүне канәгатьләндерү максатыннан закон тарафыннан билгеләнә торган чикләүләр дә булырга мөмкин. Конституция, төп закон буларак, хокукларның билгеле бер дәрәҗәсен раслый: кеше һәм гражданның хокукларын һәм ирекләрен тормышка ашыру башка кешеләрнең хокукларын

һәм ирекләрен бозарга тиеш түгел. Башкача әйткәндә, хокуклар һәм ирекләрдән файдалану абсолют һәм чиксез түгел, аның кысалары закон тарафыннан билгеләнә.

Әйтелгәннәрдән чыгып, конституцион бурычларның гомуми төшенчәсен дә билгеләргә мөмкин:

Конституцион бурычлар — иң югары хокукый таләпләр ул, алар хокукый дәүләттәге һәр кешегә һәм гражданга кагыла, иң мөһим кыйммәтләрне саклауга һәм яклауга, шәхси һәм иҗтимагый мәнфәгатьләрне канәгатьләндерүгә хезмәт итүче гамәлләрне тормышка ашыру белән бәйле.

Шәхеснең юридик бурычлары төрле законнарда беркетелгән. Конституция шуларның иң әһәмиятлеләрен аерып күрсәтә:

— һәр граждан дәүләт территориясендә гамәлдә булган Конституцияне һәм башка законнарны сакларга тиеш (РФ Конституциясенең 15 статьясы, ТР Конституциясенең 52 статьясы);

— һәр граждан башка кешеләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен хөрмәт итәргә, дәүләт һәм җәмгыять иминлегенә, иҗтимагый тәртипкә, халыкның сәламәтлегенә һәм әхлагына, башка кешеләрнең хокукларына һәм ирекләренә зарар китерүче гамәлләрдән тыелырга тиеш (РФ Конституциясенең 17 статьясы, ТР Конституциясенең 51 статьясы);

— башка гражданнарның намусын һәм милли горурлыгын хөрмәт итү — һәр гражданның бурычы; социаль, расачыл, милли һәм дини дошманлык һәм нәфрәт уята торган пропаганда һәм агитация алып бару рөхсәт ителми; социаль, раса, милли, дини һәм тел өстенлеген пропагандалау тыела (РФ Конституциясенең 29 статьясы, ТР Конституциясенең 53 статьясы);

— граждан табигатьне һәм әйләнә-тирә мохитне сакларга, табигый байлыкларга сак мөнәсәбәттә булырга тиеш (РФ Конституциясенең 58 статьясы, ТР Конституциясенең 55 статьясы);

— һәр граждан тарихи һәм мәдәни мирас турында кайгыртырга, тарихи һәм мәдәни һәйкәлләрне сакларга тиеш (РФ Конституциясенең 58 статьясы, ТР Конституциясенең 56 статьясы);

— гражданнар башка ил халыклары белән дуслык һәм хезмәттәшлек мөнәсәбәтләрен үстерүгә, гомуми танылган халыкара хокук нормалары нигезендә бөтен дөньяда тынычлыкны ныгытуга ярдәм итәргә тиеш (ТР Конституциясенең 57 статьясы);

— гражданнар хәрби хезмәт үтәргә һәм Ватанны сакларга тиеш. Закон тарафыннан хәрби хезмәттән азат итү һәм хәрби хезмәтне альтернатив бурычлар үтәү белән алыштыру мөмкинлеге каралган (РФ Конституциясенең 59 статьясы, ТР Конституциясенең 58 статьясы);

— һәр граждан закон билгеләгән салымнарны һәм җыемнарны түләргә тиеш (РФ Конституциясенең 52 статьясы, ТР Конституциясенең 54 статьясы).

Гражданның күрсәтелгән бурычларны үтәүне бозуы, кылган гамәленең иҗтимагый куркынычлылык дәрәҗәсенә бәйле рәвештә, аңа карата законлы юридик җаваплылык чаралары куллануга китерә.

Сораулар һәм биремнәр: 1. Тигез хокуклылык тигезлектән нәрсә белән аерыла? Ул законнарда чагылыш табамы? Тигезлек һәм ирек арасында каршылык юкмы — тигезлек таләп итү үз-үзеңне тоту юлын сайлаганда комачауламыймы? **2.** Шәхеснең хокукый статусының аеруча мөһим элементлары нинди? Нәрсә ул гражданлык? Шәхеснең хокукый хәленең төп принциплары нинди? Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы Конституцияләрендә хокук һәм ирекләрнең нинди төрләре беркетелгән? Россия гражданнарының хокуклары, ирекләре һәм бурычлары аның территориясендә законлы төстә яшәгән, ләкин аның гражданнары булып исәпләнмәгән кешеләрнең хокуклары, ирекләре һәм бурычлары күләменнән аерыламы? Мондый аермалык нәрсә белән аңлатыла? **3.** Соңгы ике гасыр дәвамында Россиядә кеше хокуклары өлкәсендә нинди реаль үзгәрешләр күзәтелгән? Бүгенге көндә Россиядә кеше һәм гражданның төп хокуклары һәм ирекләре ничек классификацияләнә? Бу төркемнәрнең эчтәлеге нинди? **4.** Шәхес хокуклары һәм ирекләренең юридик гарантиясе нәрсә ул? Аның нинди төрләре бар? Конституцион законлылыкның, хокук һәм ирекләрнең үтәлешен нинди махсус органнар күзәтә? Суд системасы һәм башка хокук саклау органнарының эшчәнлеге хокуклар һәм ирекләрнең үтәлешенә йогынты ясыймы? **5.** Хокуклар һәм ирекләр турында сүз алып барганда: «Иң әүвәл илне туйдырырга кирәк, аннан соң хокуклар турында сөйләшергә булыр»,— дип мыгырданучы табылмый калмый. «Икмәк белән ит булсын, хокуксыз да яшәр идек әле»,— диючесе дә була. Чыннан да, кызыклы гына сорау туа: кешене реаль хокуклар һәм ирекләр белән кайчан тәэмин итәргә мөмкин? Тамаклары тук, өсләре бөтен булгандамы? Әллә алар кешенең һәрчак юлдашы булырга тиешме? **6.** Гражданнарның ирекләрен һәм хокукларын чикләүләр бармы? Алар нинди чикләүләр һәм нәрсәгә нигезләнгән? Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы Конституцияләрендә кешенең җәмгыять һәм дәүләт алдында нинди хокукый бурычлары билгеләнгән?

12. Кеше хокуклары турында халыкара документлар. Кеше хокукларының гомуми декларациясе

Бөтендөнья бергәлеге кеше хокуклары турындагы халыкара документларның тоташ бер комплексын эшләде. Берләшкән Милләтләр Оешмасының үзенең яшәү дәверендә кеше хокуклары өлкәсендә 70 тән артык халыкара документ — декларацияләр, конвенцияләр, тәкъдимнәр, пактлар һ. б. кабул итү-

ен әйтү дә җитә. Кеше хокуклары турындагы халыкара шартнамәләрдә катнашучы дәүләтләр аларда билгеләнгән хокуклар һәм ирекләрне сакларга йөкләмә алдылар. Бу — тиешле хокуклар һәм ирекләр дәүләт эчендәге гамәл генә булып калмыйча, яңа сыйфатка да ия булалар дигән сүз: алар халыкара кеше хокуклары булып китәләр, ә ул — хокукый көйләүнең иң югары дәрәҗәсе. Кагыйдә буларак, халыкара актларда дәүләтнең алган йөкләмәләрен үтәвен күзәтү буенча контроль механизмы төзү карала. Кеше хокукларын халыкара-хокукый тануның әһәмиятен билгеләп үткән хәлдә, бу хокукларны нәтиҗәле саклау һәм яклау бары тик дәүләт аларны таныганнан соң, закон чыгару органнарында юридик беркетелгәннән соң гына мөмкин икәнлеген истә тотарга кирәк. Башкача әйткәндә, халыкара документлар мөстәкыйль яшәмиләр, ә «эчке», дәүләт хокуклары аша гамәлгә кертеләләр, алар ил эчендәге законнарда чагылырга тиеш.

Бүгенге Россиядә кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен көйләүнең үзенчәлекле сыйфаты булып аларның кеше хокуклары турындагы халыкара актларга туры килүе исәпләнә. Без кеше һәм гражданның хокукларын һәм ирекләрен көйләүче законнарның өч дәрәҗәсен билгеләп үтә алабыз. Беренчедән, кеше хокуклары һәм ирекләре турында халыкара актлар. Россиядә хокуклар һәм ирекләр гомумтанылган халыкара хокук принципларына һәм нормаларына, Россия Федерациясенең халыкара шартнамәләренә ярашлы рәвештә таныла һәм гарантияләнә. Алар Россия хокук системасының состав өлеше булып торалар. Икенчедән, РФ Конституциясе кеше хокуклары турындагы төп халыкара документларның иң әһәмиятле положениеләрен үз эченә ала. Өченчедән, халыкара актларга һәм Конституциягә туры китереп, кеше һәм гражданның теге яки бу хокукларын һәм ирекләрен көйләүче законнар. Әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә дәүләтнең эчке законнарында каралмаган кагыйдәләр булса, ул чагында халыкара шартнамә кагыйдәләре кулланыла.

Мондый төр документлар эшләүдә һәм кабул итүдә активлык озак вакытлар буена өзлексез дәвам итте, чөнки, демократик күзлектән караганда, кеше хокукларын һәм ирекләрен тупас бозуга һич тә юл куелырга тиеш түгел. Әмма әлеге идеяләр кыенлык белән генә тормышка ашырылды, һәм бары тик XX гасыр гына бу процессны тизләтте. Хәзерге заманның кеше хокуклары турындагы күпсанлы халыкара документларыннан Кеше хокукларының гомуми декларациясен, Гражданлык һәм сәяси хокукларның халыкара пактын, Икътисади, социаль һәм мәдәни хокуклар турындагы халыкара пактны, Бала хокуклары турында конвенцияне атарга мөмкин. Алар кеше хокуклары турындагы белемнәрнең нигезен тәшкил итәләр.

Хокуклар өлкәсендәге документлар арасында иң күренекле урынны Кеше хокукларының гомуми декларациясе алып

тора. Ул 1948 елның 10 декабрендә Берләшкән Милләтләр Оешмасы (ООН) Генераль Ассамблеясы тарафыннан кабул ителде. Бу икенче бөтендөнья сугышында фашизмны җиңгәннән соң озак та үтмичә булды. Ул ирек һәм демократия идеяләре җиңүнең юридик нәтиҗәсе иде. XX гасырда социаль хокуклар өчен көрәш тәҗрибәсе шушы Декларациядә чагылдырылды. Ул «барлык халыклар һәм барлык дәүләтләр үтәргә тиешле бурычлар сыйфатында» гәүдәләндерелгән. Анда кешенең табигый, тигез һәм аерылгысыз хокукларын тану һәр шәхеснең иреген һәм аның кешелек дәрәҗәсен ихтирам итү нигезе генә түгел, гомуми тынычлыкны, халыклар арасында гадел мөнәсәбәтләрне саклау шарты да булып тора дип билгеләнгән. Кеше хокукларын санга сукмау, аларга нәфрәтләнеп карау үз вакытында, аерым алганда икенче бөтендөнья сугышында, Декларациядә әйтелгәнчә, кеше намусын хурлый торган вәхши актларга китерде.

Декларацияне кабул итү өчен 48 делегация тавыш бирде. Бу документның дөньякүләм тарихи ролен тану йөзеннән, дөньяның һәр мәдәниятле илендә 10 декабрь Халыкара кеше хокукларын яклау көне итеп билгеләп үтелә.

Ул вакытта СССР делегациясенең (Белоруссия ССР, Чехословакия, Польша, Сәгуд Гарәбстаны, Украина ССР, Көньяк Африка Союзы, Югославия делегацияләре белән беррәттән) Декларация өчен тавыш бирми калу фактын фаҗига итеп кабул итми мөмкин түгел. Җиңүгә иң зур өлеш керткән, иң зур югалтулар кичергән илебез бу Декларациягә 1989 елга кадәр кул куймады. Алай гына да түгел, Декларация үзе дә 1989 елга кадәр массакүләм матбугатта игълан ителмәде. Ни өчен шулай килеп чыкты соң? Декларациянең күп кенә статьялары илдә хөкем сөргән сәяси хакимият өчен кулай түгел иде шул.

Декларация гомумкешелек нормаларының һәм кыйммәтләренең беренче җыентыгы иде, ул кеше хокукларына, аның дәрәҗәсе һәм намусы кебек сыйфатларын ассызыклап күрсәтеп, әхлакый нигез салды. Кешелек тарихында беренче тапкыр милләте, расасы, җенесе, дине нинди булуга карамастан, шулай ук нинди илдә яшәвенә карамастан, планетада яшәүче барлык халыкка кагылышлы декларация кабул ителде. Декларациядә игълан ителгән хокуклар һәм ирекләр Җир планетасында яшәүче һәммә кешегә дә карый.

Декларация преамбуладан һәм 30 статьядан тора. Кыска һәм аз сүзле булуына карамастан, документта тормыш эшчәнлегенең барлык төп өлкәләрендәге кеше хокуклары беркетелгән. Бу — шәхси (гражданлык) хокуклар һәм ирекләр, кешенең сәяси, шулай ук икътисади, социаль һәм мәдәни хокуклары.

Хәзерге заманда кешенең җәмгыятьтәге хокукый хәле, әгәр ул өч табигый башлангычка: яшәү хокукына, иреккә һәм шәхси кагылгысызлыкка, тигезлеккә нигезләнгән булса, демократиянең тиешле бөтендөнья стандартына туры килә дип исәпләнә. Әлеге өч хокукны берләштерү очраклы гына түгел: ирек — кеше тормышының иң югары кыйммәте, ә шәхси кагылгысызлык ирекнең беренче алшарты булып тора.

22—25 статьяларда кешенең төп социаль-икътисади хокуклары беркетелгән, алардан башка кешелек дәрәҗәсен тәэмин итү мөмкин түгел. Декларациянең 29 статьясы хокуклардан тыш бурычлар да бар икәнлеген искә төшерә: «Һәр кешенең җәмгыять алдында бурычлары бар, чөнки аның шәхесе җәмгыятьтә генә ирекле һәм тулы үсешкә ирешә ала». Хокуклар һәм бурычлар бердәмлеге гражданлыкның нигезен тәшкил итә.

1991 елның ноябрендә безнең илдә Кеше һәм гражданның хокуклары һәм ирекләре декларациясе кабул ителде. Ул Кеше хокукларының гомуми декларациясен, кайбер ачыклаулар һәм өстәмәләр белән, милли законнарда яңартты.

Гомуми декларациягә салынган идеяләр һәм принциплар кеше хокуклары турындагы күпсанлы халыкара хокукый актларда тагын да үстерелде.

Шуларның иң әһәмиятлеләре арасыннан 1966 елның 19 декабрендә БМОның Генераль Ассамблеясы тарафыннан кабул ителгән ике пакт аерылып тора: Гражданлык һәм сәяси хокуклар турындагы пакт һәм Икътисади, социаль һәм мәдәни хокуклар турындагы пакт. Бу пактларның «Кеше хокуклары турында пактлар» дигән гомуми исеме бар.

БМО тарафыннан халыкның аерым төркемнәре (хатын-кызлар, балалар, инвалидлар, качаклар һ. б.) хокукларын һәм ирекләрен яклау максатында кабул ителгән башка күп кенә актлар да бар. Алар арасында БМОның Генераль Ассамблеясы кабул иткән Бала хокуклары декларациясе (1959) һәм Бала хокуклары турында конвенция (1989) әһәмиятле урын алып тора. Бу соңгы ике документ турында 17 параграфта җентекләбрәк аңлатырбыз.

Кеше хокуклары өлкәсендәге халыкара хокук нормаларының әһәмияте шунда, алар, бер яктан, дәүләткә халыкара-хокукый актларда беркетелгән кеше хокукларын реаль тәэмин итүне йөклиләр; икенче яктан, бу документлар билгеле бер кешегә дәүләттән халыкара йөкләмәләрен үтәвен таләп итү хокукы бирәләр. Шулай итеп, кеше хокукларын халыкара-хокукый тану җәмгыять һәм шәхеснең үзара мөнәсәбәтләре характерына, һәрбер аерым дәүләттә кеше хокукларын тәэмин итү процессына турыдан-туры йогынты ясый.

Хәзерге заманда шәхес хокукларын саклау һәм билгеле бер күләмдә тулыландыру дәүләтнең эчке һәм тышкы сәясәте-

нең, аның кешегә мөнәсәбәтенең әһәмиятле күрсәткече булып тора. Кеше хокукларына хөрмәт белән карау аша аерым дәүләтләрдә һәм тулаем бөтен дөньяда шәхеснең кыйммәте раслана.

Сораулар һәм биремнәр: 1. Кеше хокуклары һәм ирекләре турындагы халыкара-хокукый документларның әһәмияте нәрсәдә? Аларның милли законнар белән бәйләнеше нинди? 2. Кеше хокукларының гомуми декларациясе XX гасырда кеше хокуклары өлкәсендә нинди реаль үзгәрешләрне чагылдырды? Моңа инде илле елга якын вакыт узды, бүгенге көнгә аның положениеләре искермәдеме? 3. Китап ахырында Кеше хокукларының гомуми декларациясеннән һәм ТР Конституциясеннән өземтәләр бирелгән. Алардан файдаланып, чагыштыру таблицасы төзегез: хокуклар һәм ирекләрнең исемнәре һәм алар бу документларның кайсы статьяларында чагылдырылган.

13. Гражданлык хокуклары һәм ирекләре

Гражданлык хокуклары һәм ирекләре — һәр гражданның шәхси тормыш өлкәсендәге мөмкинлекләре ул. Алар кешенең шәхси тормышындагы бәйсезлеген һәм мөстәкыйльлеген тәэмин итәргә, аның эчке дөньясына тыкшынулардан сакларга тиеш. Шәхси хокуклар һәм ирекләр гомумкешелек кыйммәтләренең киң даирәсен үз эченә ала, аларны саклаудан башка кешенең мөстәкыйль һәм бәйсез шәхес буларак яшәве мөмкин түгел.

Кешенең гражданлык хокуклары һәм ирекләре дәүләт тарафыннан танылa, РФ һәм ТР Конституцияләрендә һәм Кеше хокукларының гомуми декларациясенә, кеше хокуклары турындагы халыкара пактларга, шулай ук башка халыкара нормаларга туры килә торган башка законнарда беркетелә. Кешегә хокуклар һәм ирекләр аның гражданлыгына бәйсез рәвештә бирелә.

Гражданлык хокукларын һәм ирекләрен җентекләбрәк карап үтик.

Һәр кеше **яшәүгә хокуклы** (РФ Конституциясенең 20 статьясы, ТР Конституциясенең 25 статьясы). Бу — кешенең төп һәм аерылгысыз хокукы, аның кешелек дәрәҗәсенең гарантиясе.

Дәүләт кешеләрне аларның гомерләренә законсыз төстә кул сузудан саклауны үз өстенә ала. Беркем дә нигезсез үтерелергә тиеш түгел. Кеше үтерү кебек иң авыр җинаятьләр өчен үлем җәзасы, гадәттән тыш чара буларак, федераль закон белән билгеләнә. Үтерү, әгәр ул җинаятьчел һөҗүмнән саклану нәтиҗәсе булса, яисә сугыш вакытында эшләнсә, кешенең яшәүгә хокукын бозу дип исәпләнми.

Иреккә һәм шәхси кагылгысызлыкка хокук кешене аның гомеренә, сәламәтлегенә, шәхси ирегенә законсыз төстә янаудан саклау тәэмин ителә дигәнне белдерә (РФ Конституциясе-

нең 22 статьясы, ТР Конституциясенең 26 статьясы). Иреккә омтылу — кешенең иң көчле хисләреннән берсе. Үз планнарының һәм теләкләренең тормышка ашуын кеше ирек белән бәйли. Кыскача әйткәндә, ирекле кеше генә аңлы рәвештә теләгәнен сайлау мөмкинлегенә ия.

Гражданин ирекле һәм законга каршы килми торган теләсә нинди гамәлне кылырга хокуклы. Бу очракта ул нинди дә булса мәҗбүр итүләргә яисә хокукый чикләүләргә юлыгырга тиеш түгел. Гражданин, үзенә һәм вакытына үзе хуҗа булган хәлдә, тиеш дип тапкан гамәлләрен үзе билгели. Ирек һәм шәхси кагылгысызлык бары тик вәкаләтле дәүләт органнары тарафыннан һәм закон нигезендә генә чикләнергә мөмкин. Мәсәлән, берәү дә суд карары яисә прокурор санкциясе булмаган килеш кулга алынырга яки ябылуда тотылырга тиеш түгел. Кулга алынган һәм сак астында тотылган очракта, гражданин бу гамәлләр өстеннән судка шикаять бирергә хокуклы.

Хокук бозган өчен җаваплылыкка тартылган һәр кеше, әгәр гаебе тиешле хокукый процедура кысаларында закон буенча ачыкланмаган икән, гаепсез дип исәпләнә. Ирекләреннән мәхрүм ителгәннәр гуманлы мөнәсәбәткә һәм кешелек дәрәҗәләренә ихтирам белән карауга хокуклы. Беркем дә газаплауга, рәхимсез, кешелексез мөнәсәбәткә яисә җәзалануга дучар ителергә тиеш түгел. Үзенең ризалыгыннан башка кеше медицина, фәнни яки башка тәҗрибәләргә тартылырга тиеш түгел.

Дәүләт **яклануга хокукны** гарантияли (ТР Конституциясенең 26 статьясы). Әгәр кеше адвокат хезмәте өчен түли алмый икән, аңа юридик ярдәм бушлай күрсәтелә.

Дәүләт **шәхеснең кешелек дәрәҗәсен** сакларга тиеш (РФ Конституциясенең 21 статьясы, ТР Конституциясенең 33 статьясы), кешене кимсетергә бернәрсә дә нигез була алмый. Бу положениенең катгый, бер генә мәгънәдә икәнлегенә игътибар итәргә кирәк. Шәхесне кимсетү берни белән дә aклана алмый.

Кешелек дәрәҗәсе дип без нәрсәне аңлыйбыз? Ул — кешедәге аерым бер рухи-әхлакый, ихтыяри һәм интеллектуаль сыйфатларны тану. Кешелек дәрәҗәсен саклау әйләнә-тирәдәгеләрнең ихтирамына хокук дигәнне аңлата. Кешеләр үзләренең физик, интеллектуаль һәм башка сыйфатлары, милекләре һәм социаль хәлләре буенча аерылалар. Әмма закон аларның кешелек дәрәҗәләрен бертигез саклый. Күпләр үзләренең кешелек дәрәҗәләренә һәм намусларына кагылуны авыр кичерәләр. Немец шагыйре һәм драматургы Иоганн Фридрих Шиллер (1759—1805) болай дип язган: «Намус акчадан кыйммәтрәк». Элек намусларын һәм кешелек дәрәҗәләрен мыскыл иткән өчен дуэльгә чакырганнар һәм еш кына шунда һәлак булганнар.

А. С. Пушкинның үлүе тарихын искә төшерегез. Хатыны Натальяның хыянәте турында Дантес исеме кергән сүзләр ишетелә башлагач, ул Дантесны дуэльгә чакыра. Шагыйрьнең дошманнары әлеге

пычрак гайбәтне кыздырып торалар. Пушкин үзенең һәм хатынының намусын дуэльдә якларга карар кыла. Ул үзенең һәлак булуы мөмкин икәнлеген аңлый, әмма хурлыктан үлемне өстенрәк күрә. Пушкинның бүтән юлы булганмы соң? Ул чакта кешелек дәрәҗәсен һәм намусын саклау турындагы закон булган булса, судка мөрәҗәгать итә алган булыр иде.

Граждан, Россия законнары буенча, судтан аның намусын, кешелек дәрәҗәсен яисә абруен пычратуны юкка чыгаруны һәм шуның аркасында килгән матди һәм мораль зыянны каплауны таләп итә ала. Әгәр кешелек дәрәҗәсенә һәм намуска кул сузуда җинаять составы билгеләре була икән, ул очракта гаепле кеше җинаять җаваплылыгына тартыла.

Һәр гражданга **торак кагылгысызлыгы** тәэмин ителә (РФ Конституциясенең 25 статьясы, ТР Конституциясенең 27 статьясы). Бу — кеше ирегенең мөһим элементы. Закон тарафыннан каралган очрактан тыш, беркемнең дә анда яшәүче кешеләрнең рөхсәтеннән башка торакка керергә һәм тентү яки тикшерү үткәрергә хакы юк. Тентү тикшерүченең дәлилле күрсәтмәсе һәм прокурор санкциясе буенча җинаять эше кузгатылган очракта гына рөхсәт ителә.

Хат язышу, телефоннан сөйләшү, телеграфтан хәбәр итешү һ. б. элемтә чараларыннан файдалану серен саклау закон тарафыннан гарантияләнә (РФ Конституциясенең 23 статьясы, ТР Конституциясенең 28 статьясы). Беркем дә чит кешегә адресланган хатларны укырга һәм телефоннан чит кешеләрнең сөйләшүләрен тыңларга тиеш түгел. Бу хокукны бозган кеше юридик җаваплылыкка тартыла. Әлеге кагыйдәдән чыгарма бары тик закон тарафыннан каралган очракларда дәүләтнең хокук саклау органнары өчен генә ясала. Корреспонденциягә арест салу һәм телефоннан сөйләшүне тыңлау бары тик җинаять эшен тикшерү барышында һәм прокурор санкциясе белән яисә суд билгеләмәсе яки карары буенча гына рөхсәт ителә.

Конституция һәркемнең **шәхси тормышының кагылгысызлыгын, гаилә серен, намусын һәм кешелек дәрәҗәсен яклау хокукын беркетә.** Шәхси тормыш — кешеләрнең гаилә, эш, дуслык мөнәсәбәтләре өлкәсе ул.

Леонид Гайдайның «Бриллиант кул» дигән атаклы комедиясендә шундый эпизод бар. Фильм герое ишек төбеннән генә таксига утыра, кулында — букча. Сизгер җәмәгать эшлеклесе, моны күргәч: «Совет кешеләре яшелчә кибетенә таксида йөрми»,— ди. Фаш итәргә теләп, ул аның артыннан күзәтү оештыра, «җәмәгатьчелек фикере» тудырырга тырыша. Бер йортта яшәүче кешегә шикләнеп карау һәм аның шәхси тормышына тыкшынырга омтылу, ягъни башкаларга кагылмаган нәрсәне күрергә тырышу бу гражданның хокукын бозуга китерә. Баксаң, әлеге кеше тәртип бозмаган, киресенчә, үзе хокук саклау органнарына булышып йөри икән бит. Сез ничек уйлыйсыз, әгәр әлеге граждан җинаятьче булып чыкса, җәмәгать эшлеклесенең тәртибенә икенче төрле бәя куелыр идеме?

Кешенең үзенә ничек ошый, шулай яшәргә хокукы бар. Шәхси тормышында ул шәхси мәнфәгатьләрен канәгатьләндерергә тырыша. Кешенең үзенең рөхсәтеннән башка аның шәхси тормышы турындагы информацияне җыю, саклау һәм файдалану, тарату рөхсәт ителми. Гражданин үзенең хокукларына һәм ирекләренә турыдан-туры кагылышлы документлар һәм материаллар белән танышырга хокуклы (әгәр закон буенча башкасы каралмаган булса).

Һәр кеше ил эчендә ирекле рәвештә күчеп йөрү, яшәү һәм тору урынын сайлау, илдән ирекле рәвештә чыгу һәм керү хокукына ия (РФ Конституциясенең 27 статьясы, ТР Конституциясенең 31, 32 статьялары). Бу хокукны бары тик закон гына чикли ала. Гражданнар Россиядән һәм Татарстаннан ирекле рәвештә китәргә һәм теләсә кайчан әйләнеп кайтырга хокуклы, чит илгә сөрелергә тиеш түгел.

Әле күптән түгел генә бу хокук безнең илдә тупас рәвештә бозыла иде. Тору урыны эчке эшләрнең җирле органында теркәлү мөмкинлегенә бәйле, ә күчеп китү махсус рөхсәт булган урыннарга гына мөмкин иде. Чит илгә, «ышанычлылык» тикшерүен үткәннән соң, бик аз кешеләр генә чыга алды. «Ярамаган» кешеләрне, яңадан кире кайтмаслык итеп, илдән сөрделәр. Язучы А. И. Солженицын белән, мәсәлән, шундый хәл булды. Атаклы музыкантыбыз М. Ростропович һәм аның хатыны талантлы җырчы Г. Вишневская да гражданлыктан мәхрүм ителделәр һәм кире илгә кертелмәделәр.

Гражданнарга **вөҗдан һәм дин ирекe** тәэмин ителә (РФ Конституциясенең 28 статьясы, ТР Конституциясенең 29 статьясы). Үз инануларына карап, һәркем теләсә кайсы динне ирекле сайларга һәм тотарга яисә бернинди динне дә тотмаска, дини яки атеистик карашларга ия булырга һәм аларны таратырга, аларга туры килә торган гамәлләр кылырга, балаларына дини яисә атеистик тәрбия һәм белем бирү белән шөгыльләнергә хокуклы. Дәүләт ата-аналарның балаларына үз инанулары буенча дини тәрбия бирүне сайлауларын ихтирам итә. Дини табынулар һәм йолалар ирекe дә рөхсәт ителә. Дини һ. б. берләшмәләр төзү, дини белем алу хокукы да гарантияләнгән.

Аллага ышанучыны дини инанулары өчен эзәрлекләү — куркыныч күренеш. Дини фанатизм, башка динне тотучыларны дошман күрү дә куркыныч. Тарих курсыннан Франциядә, Англиядә, Россиядәге канлы дини сугышларны искә төшерегез.

Дини инануларга бәйле дошманлык һәм нәфрәт уяту тыела. Гражданнарның, дингә мөнәсәбәтләре нинди булуга карамастан, тигез хокуклылыгы закон белән гарантияләнә. Закон буенча барлык дини берләшмәләр бертигез. Дини һәм атеистик берләшмәләр дәүләттән аерылган, дәүләт органнары һәм урындагы кешеләр аларның эшчәнлеге мәсьәләләренә тыкшынмыйлар. Шул ук вакытта дәүләт дини оешмаларның законлы

эшчәнлеген саклый. Дин һәм вөҗдан иреге турындагы законны бозуда гаепләнгән кешеләр юридик җаваплылыкка тартылалар.

Һәр граждан **үзенең милләтен билгеләргә һәм күрсәтергә хокуклы, ул аралашу, тәрбия, уку һәм иҗат телен сайлауда ирекле, шул исәптән ана теленнән файдалану хокукына ия** (РФ Конституциясенең 26 статьясы, ТР Конституциясенең 20 статьясы). Кешене милләтен билгеләргә һәм күрсәтергә мәҗбүр итәргә ярамый. Ана теленнән файдалану хәзергә күпләр өчен кыенрак әле. Бу хокукны тормышка ашыру балалар ана телендә укый алырлык мәктәпләрне, мәктәпкәчә учреждениеләрне арттыруны таләп итә.

Һәр гражданга **фикер һәм сүз иреге** гарантияләнә, беркемне дә үз фикерен һәм мәсләген белдерергә яисә аннан баш тартырга мәҗбүр итәргә ярамый (РФ Конституциясенең 29 статьясы, ТР Конституциясенең 35 статьясы). Бу хокуклар кешенең рухи һәм әхлакый бәйсезлегенә, димәк, сәяси һәм идеологик күп төрлелеккә булышлык итә. Бу хокуклардан башка җәмгыятьнең чын үсеше мөмкин түгел.

Гражданнар шулай ук **мәгълүмат алу иреге** белән дә тәэмин ителә (РФ Конституциясенең 29 статьясы, ТР Конституциясенең 35 статьясы). Бу хокук киңрәк, ул мәгълүмат алуны гына түгел, аны законлы юл белән ирекле төстә эзләүне, башка берәүгә бирүне, булдыруны һәм таратуны да белдерә. Массакүләм мәгълүмат чараларын (вакытлы матбугат, радио-, теле-, видеопрограммалар, кинохроникалар) ирекле рәвештә оештыру хокукы гарантияләнә. Цензура тыела. Күрсәтелгән хокуктан файдалануда бары тик бер максаттан — дәүләт серен, әхлаклылыкны, башка кешеләрнең хокукларын һәм ирекләрен саклау максатыннан гына кайбер чикләүләр булырга мөмкин. Массакүләм мәгълүмат ирегеннән законсыз, җинаятьчел максатта файдалану тыела.

Күргәнегезчә, закон шәхси хокукларның һәм ирекләрнең киң даирәсен исәпкә алган. Әмма, РФ Конституциясенең 17 нче, ТР Конституциясенең 51 нче статьяларында күрсәтелгәнчә, гражданның шәхси хокукларын һәм ирекләрен тормышка ашыруы башка кешеләрнең шәхси хокукларына һәм ирекләренә каршы куелырга тиеш түгел. Бу хокукларны һәм ирекләрне тормышка ашыру шулай ук дәүләт һәм җәмәгать куркынычсызлыгына, иҗтимагый тәртипкә, халыкның сәламәтлегенә һәм әхлагына, башкаларның хокукларын һәм ирекләрен яклауга зыян китерергә тиеш түгел.

Сораулар һәм биремнәр: 1. Ни өчен шәхси ирекләр кешегә аның гражданлыгына бәйсез рәвештә бирелә? 2. Дустыгыз сезгә дигән хатны укыды, ди. Болай эшләргә аның хакы бар идеме? Моның өчен ул нинди җаваплылыкка тартылырга мөмкин? Укытучы дәрестә укучы язган хатны тартып алып укырга хокуклымы? 3. Оператив милиция хезмәткәре

җинаять кылуда шик астына алынган кешегә карата көч кулланган, һәм тегесе гаебен таныган. Тикшерү тануның дөреслеген раслаган. Милиция хезмәткәре дөрес эшләгәнме? Шик астына алынган кеше чыннан да җинаять эшләгән бит, көч кулланганлыгы өчен милиционер җавап бирергә тиешме? Шик астына алынган кешеләргә карата көч, җәза куллануның хәтәрлеге нидә? **4.** Кеше газетадан үзен хурлый торган мәгълүматлар бирелгән мәкалә укыды, ди. Ул ни эшләргә мөмкин (дәшми калырга, автор белән көч куллану юлы аша «аңлашырга», редакциягә хат язарга, судка мөрәҗәгать итәргә)? Мөмкин булган гамәлләрнең һәркайсын дәлилләгез. **5.** Торак кагылгысызлыгы турындагы кагыйдә иң беренче булып барлыкка килгән Англиядә мондый әйтем бар: «Йортым минем — ныгытмам минем». Ул нәрсәне аңлата? Санап кителгән чараларның кайсысы торак хокукын саклауда иң ышанычлысы булып тора: тимер ишекләрме, махсус сигнализацияме, законмы, каравылчымы? Торакка үтеп керү өчен һәрвакыт хуҗаның ризалыгы кирәкме? **6.** Безнең дәүләт дөньяви дәүләт булып исәпләнә. Дәүләт радиосы һәм телевидениесе каналлары буенча дини вәгазьләр тапшыру, шулай ук дәүләт мәктәпләрендә дин белеме укыту бу кагыйдәгә каршы киләме?

14. Сәяси хокуклар һәм ирекләр

Гражданның сәяси тормышта, дәүләт хакимиятен гамәлгә ашыруда, дәүләт эшләрен идарә итүдә катнашу өчен билгеле бер хокуклары һәм ирекләре бар. Аларны сәяси хокуклар һәм ирекләр дип атыйлар. Сәяси хокуклар, бер яктан, җәмгыять яки дәүләт эшләрен хәл иткәндә кешенең мөстәкыйльлеген һәм бәйсезлеген, икенче яктан, аның актив рәвештә ил яисә аерым коллективлар тормышында катнашуын тәэмин итәргә тиеш. Бу хокуклар кешегә башкалар белән бергә җәмгыять һәм дәүләт алдында торган мәсьәләләрне хәл итүдә катнашырга, хакимияткә йогынты ясарга мөмкинлек бирә. Сәяси хокуклар һәм ирекләргә җентекләбрәк тукталыйк.

Дәүләт эшләрен идарә итүдә турыдан-туры да, вәкилләр аша да катнашу хокукы гражданнарның сәяси хокуклары һәм ирекләренең гомуми чагылышы булып тора (РФ Конституциясенең 32 статьясы, ТР Конституциясенең 2 статьясы). Бу хокук ике төрле — эчтәлеге буенча таррак, әмма чынлыкта тормышка ашырыла ала торган хокуклар һәм ирекләр белән бергә үтәлә. Аларга түбәндәгеләр керә: сайлау хокукы, ягъни дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарына сайлау һәм сайлану, шулай ук референдумда катнаша алу хокукы; дәүләт хезмәтендә һәм суд эшчәнлегендә катнашу хокукы; ирекле рәвештә митинглар, җыелышлар, демонстрацияләр, пикетлар уздыру хокукы; сәяси партияләргә, җәмәгать оешмаларына, профсоюзларга берләшү хокукы; дәүләт органнарына һәм җирле үзидарә органнарына шәхси мөрәҗәгать итү һәм индивидуаль, күмәк мөрәҗәгатьләр юллау хокукы.

Гражданнар дәүләт эшләре белән идарә итүдә **референдум** — закон проектлары, гамәлдәге законнар һәм дәүләт күләмендәге башка мәсьәләләр буенча бөтенхалык тавыш бирүе ярдәмендә катнашырга хокуклы. Россия гражданнарының җәмәгать һәм дәүләт эшләре белән идарә итүдә турыдан-туры катнашуларына 1993 елның 12 декабрендә Россия Федерациясе Конституциясе проекты буенча бөтенхалык тавыш бирүен мисал итеп китерергә була.

Россия Федерациясендә һәм Татарстан Республикасында күп кенә җәмәгать оешмалары, хәрәкәтләр, фондлар, учреждениеләр, иҗтимагый үзешчән органнар бар. Уртак мәнфәгатьләрне яклау һәм гомуми максатларга ирешү өчен иҗтимагый берләшмәләргә **берләшү хокукы**, беренчедән, гражданның ирекле нигездә башка гражданнар белән берлектә теләсә нинди берләшмә (сәяси партия, җәмәгать оешмасы, профсоюз, дини җәмгыять, коммерция яисә башка ирекле форма) оештыра алуын, икенчедән, гражданның аның мәнфәгатьләрен чагылдыручы иҗтимагый берләшмәгә керә алуын, өченчедән, аларга керүдән тукталып тора алуын, шулай ук алардан тоткарлыксыз чыга алу хокукын күздә тота (РФ Конституциясенең 30 статьясы, ТР Конституциясенең 37 статьясы). Беркем дә нинди дә булса оешмага мәҗбүри кертелергә тиеш түгел.

Дәүләт хезмәте дәүләт эшләре белән идарә итү хокукын тормышка ашыру формасы булып тора. Дәүләт хезмәтенә керү хокукына Россия Федерациясенең 18 яшьтән ким булмаган, дәүләт телен белгән һәм профессиональ белеме булган гражданнары ия була ала. Мондый хокук ТР Конституциясенең 39 статьясында беркетелгән. Дәүләт хезмәтенә кергәндә, шулай ук бу хезмәтне үтәгәндә кешенең расасына, җенесенә, милләтенә, теленә, социаль чыгышына, тору урынына, дингә мөнәсәбәтенә, инануына, иҗтимагый берләшмәләрдә торуына бәйле нинди дә булса турыдан-туры яисә өлешчә чикләүләр рөхсәт ителми. Дәүләт хезмәтенә кабул ителгәндә яисә дәүләт урынын биләгәндә, законда кайбер чикләүләр каралган. Бу, әйтик, гражданны суд юридик хокукка сәләтсез яки юридик хокукы чикләнгән дип тапкан; аны суд дәүләт хезмәтендә эшләү хокукыннан билгеле бер срокка мәхрүм иткән; медицина учреждениесе анда дәүләт хезмәте вазифаларын үтәргә комачаулаучы авыру тапкан очракларда булырга мөмкин.

Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы гражданнары судларда гражданлык һәм җинаять эшләрен караудa, ягъни **суд эшчәнлегендә** антлы утырышчы һәм халык утырышчысы буларак катнаша алалар.

Шәхеснең аерылгысыз сәяси хокукларына һәм ирекләренә **җыелышлар, митинглар һәм демонстрацияләр, пикетлар** керә (РФ Конституциясенең 31 статьясы, ТР Конституциясенең 36 статьясы). Бу чаралар аша гражданнар үз ихтыярларын белдерә һәм дәүләт, җәмәгать органнарына йогынты ясый ала-

лар. Әлеге хокук реаль халык хакимиятен тормышка ашырырга булыша. Аннан конституцион стройны көч куллану юлы белән үзгәртү, расачыл, милли, сыйнфый, дини нәфрәт уты кабызу, көчләү һәм сугыш пропагандалау өчен файдалану тыела. Эчке эшләр органнары мондый чараларны үткәргәндә иҗтимагый тәртипне саклыйлар, хокук бозу гамәлләрен кисәтәләр һәм туктаталар. Кирәк булган очракта, гаеплеләр юридик җаваплылыкка тартыла.

Гражданнарның дәүләт органнарына һәм җирле үзидарә органнарына **шәхси һәм күмәк мөрәҗәгатьләр** җибәрергә конституцион хокукы объектив рәвештә бу органнар эшчәнлеген яхшыртуга да, шәхеснең хокукларын һәм ирекләрен яклауга да юнәлдерелгән (РФ Конституциясенең 33 статьясы, ТР Конституциясенең 37 статьясы). Мөрәҗәгатьне кабул иткән орган закон куйган срокта үз вәкаләте кысаларында аны карарга, аның буенча карар кабул итәргә һәм дәлилле җавап бирергә тиеш.

Сәяси хокуклар һәм ирекләр дәүләт белән идарә итүдә катнашу чарасы булып тора.

Сәяси хокуклар алу һәм аларны тормышка ашыру Россия яисә Татарстан гражданлыгына ия булу белән (гражданлыгы булмаган кешеләр һәм чит ил кешеләре ул хокукларга ия түгел) һәм билгеле бер яшькә (гражданлыкка ия булу өчен 18 яшь, Федераль Җыелыш депутаты булу өчен 21 яшь, судья булу өчен 25 яшь, президент булу өчен 35 яшь, Конституцион Суд әгъзасы булу өчен 40 яшь) җитү белән бәйле.

Сораулар һәм биремнәр: 1. Кешегә сәяси хокуклар һәм ирекләр ни өчен кирәк? **2.** Халыкара шартнамәләр ил гражданнарының хәленә ничек йогынты ясый? **3.** Россия һәм Татарстан гражданнарының сәяси хокукларыннан файдаланулары турында газеталардан мисаллар китерегез.

15. Икътисади хокуклар

Икътисади хокуклар кеше эшчәнлегенең төрле матди уңайлыклар һәм товарлар җитештерү, алмаштыру, бүлү һәм куллану өлкәсендәге ирекен үз эченә ала. Алар шәхеснең тормыш эшчәнлеге өчен матди һәм социаль шартлар тудыруга ярдәм итәләр. Икътисади хокукларга җентекләбрәк тукталыйк.

Эшмәкәрлек һәм закон тарафыннан тыелмый торган башка эшчәнлек өчен үзенең сәләтеннән һәм милкеннән ирекле файдалану хокукына (РФ Конституциясенең 34 статьясы, ТР Конституциясенең 42 статьясы) гражданнар да, аларның берләшмәләре дә ия. Закон тарафыннан тыелган икътисади эшчәнлек рөхсәт ителми.

Хосусый милеккә хокук — Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы хокукында чагыштырмача яңа күренеш.

«Ат юк аранда — кайгы юк буранда» ди халык мәкале. Бер нәрсәсе дә булмаган кешенең югалтыр нәрсәсе дә юк. «Юкның башы авыртмый» дигән мәкаль дә бар. Андый кеше берни өчен дә борчылмый. Дистә еллар дәвамында илебездә дәүләт милке яшәп килде, аны бөтен кешенең милке дип аңлаттылар. Бөтен кешенеке, — димәк, беркемнеке дә түгел. Шуңа күрә хезмәт кешесендә бу милек өчен җаваплылык тойгысы булмады.

Бөтен дөньяда милекне изге һәм кагылгысыз дип исәплиләр. Һәм монда бернинди начарлык та юк. Милек кешене икътисади яктан бәйсез итә, димәк, рухи һәм сәяси бәйсезлек мөмкинлеге тудыра. Милеккә хокук кеше һәм гражданның хокукый хәленең икътисади нигезе булып тора. Милек ул — милекченең әйбер белән идарә итүе, үзең генә дә, башка кешеләр белән дә аңа ия булу, аннан файдалану мөмкинлеге. Милеккә хокук турында киңрәк итеп без 21 параграфта сөйләрбез.

Россия Федерациясе Конституциясе хосусый милек хокукына кеше һәм гражданның хокуклары һәм ирекләре турындагы бүлектә ике аерым статья багышлый. Аның беренчесе хосусый милеккә хокукны һәр кешенең аерым яисә башка кешеләр белән берлектә, суд карарыннан башка яки, дәүләт тарафыннан алдан каралып, бердәй кыйммәттәге милеккә алмаштырылмаганда, тартып алынырга тиеш булмаган милеккә ия булу, аннан файдалану һәм эш итү хокукы сыйфатында карый (35 статья). Икенче статья җир һәм башка табигый байлыкларга кагыла: Россия гражданнары һәм аларның берләшмәләре, әгәр бу әйләнә-тирә мохиткә зыян китермәсә, башка гражданнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен бозмаса, ул байлыкларга ия була һәм ирекле файдалана ала (36 статья).

Татарстан Республикасы Конституциясенең 11 статьясы буенча хуҗалык эшчәнлеге, дәүләт милке, җирле үзидарә милке һәм җәмәгать берләшмәләре милке белән беррәттән, шулай ук хосусый милек нигезендә дә тормышка ашырыла. Хосусый милектә җир участоклары һәм эшчәнлекнең закон тарафыннан тыелмый торган өлкәсендә файдаланыла торган башка объектлар булырга мөмкин.

Мирас хокукы шулай ук закон тарафыннан таныла һәм саклана (РФ Конституциясенең 35 статьясы, ТР Конституциясенең 41 статьясы). Бу хокук милек хокукы белән тыгыз бәйләнгән. Беркем дә мирас сыйфатында алына торган мөлкәттән мәхрүм ителергә тиеш түгел.

Хезмәткә хокук һәм ялга хокук (РФ Конституциясенең 37 статьясы, ТР Конституциясенең 42, 43 статьялары). Ә нәрсә соң ул хезмәт? Хезмәт — кешеләрнең матди яки рухи кыйммәтләр тудыруны максат итеп куйган мөстәкыйль, индивидуаль яки күмәк эшчәнлеге. Бөек рус язучысы А. П. Че-

хов болай дип язган: «Кеше, ул кем генә булмасын, тир түгеп хезмәт итәргә тиеш, тормышның мәгънәсе һәм максаты, бәхет һәм шатлык шуннан тора да инде». Хезмәт кешенең тамагын туйдырырга гына түгел, аның рухи ихтыяҗларын канәгатьләндерергә дә, аңа кызыклы булырга да тиеш.

Хокук хезмәтнең эчтәлеген түгел, хезмәт мөнәсәбәтләрен оештыру формасын көйли. Һәркемнең үзенең хезмәткә сәләтеннән ирекле файдаланырга, эшчәнлек төрен һәм профессиясен ирекле сайларга хакы бар. Мәҗбүри хезмәт тыела. Эш вакытының озынлыгы, ял һәм бәйрәм көннәре, түләнә торган еллык ял закон тарафыннан билгеләнә.

Сораулар һәм биремнәр: 1. Эшмәкәрлек яисә закон тарафыннан тыелмый торган башка икътисади эшчәнлек ирегенә хокук нәрсә ул? 2. Җирне һәм башка табигый байлыкларны да кертеп, хосусый милеккә хокук нәрсәне аңлата? Милекченең һәм милке булмаган кешенең психологияләре ничек аерыла? 3. Сәләтеңнән һәм милкеңнән ирекле файдалануга хокукны сез ничек аңлыйсыз? 4. Ирекле хезмәткә хокук Конституциягә нинди максат белән кертелгән?

16. Социаль хокуклар. Мәдәни хокуклар

Социаль хокуклар эшкә алынган хезмәткәрләрне яклау белән бәйле хезмәт мөнәсәбәтләренең күпчелек өлешенә: хезмәт куркынычсызлыгына, ялга, хезмәткә сәләтлелекне торгызуга, кешеләрнең яшәү мохитенә, аларның сәламәтлекләренә һәм социаль тәэмин ителү мәсьәләләренә кагыла. Нинди хокуклар соң болар?

Эшсезлектән саклауга хокук. Бу хокук эшсез калган очракта дәүләт гражданга ярдәм итә, эш табарга яисә җәмгыятькә кирәкле башка белгечлеккә өйрәнергә булыша дигән сүз. Эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт сәясәтенең төп юнәлешләренә түбәндәгеләр керә: Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының барлык гражданнарының хезмәткә һәм хезмәтне ирекле сайлауга хокукларын тормышка ашыруда тигез мөмкинлекләр тәэмин итү; хезмәт һәм эшмәкәрлек инициативасын хуплау, профессиональ һәм иҗади эш сәләтен үстерергә булышу; хезмәт ирегең, гражданнарның эш төре сайлауда иреклелеген саклау; эш белән тәэмин итүдә социаль яклау оештыру; эш эзләүдә кыенлык кичерүче гражданнарны эш белән тәэмин итү өлкәсендә махсус чаралар үткәрү; эш белән тәэмин итү өлкәсендәге эшчәнлекне икътисади һәм социаль сәясәтнең башка юнәлешләре белән яраштыру; керем үсешен һәм бүленешен көйләү, инфляцияне кисәтү; беренче чиратта социаль яклауга мохтаҗ булган һәм эш эзләүдә кыенлыклар кичерүче гражданнар өчен яңа эш урыннары булдыручы эшмәкәрләргә булышу һ. б.

Социаль тәэмин ителүгә хокук аерым категориядәге гражданнарның (картлар, авырулар, инвалидлар һ. б.) дәүләт пенсияләре, социаль пособиеләр һәм закон тәртибендә куелган башка төр ярдәм алуга булган хокукларын күздә тота (РФ Конституциясенең 39 статьясы, ТР Конституциясенең 46 статьясы). Моның өчен ирекле социаль страхование, социаль тәэминат һәм хәйрия җәмгыятьләренең өстәмә формаларын төзү хуплана. Пенсияләр һәм пособиеләр тормыш дәрәҗәсен яшәү өчен кирәкле минимумнан төшермичә тәэмин итәргә тиеш.

Һәркем **торакка хокуклы** — бу иң кирәкле тормыш уңайлыкларының берсе (РФ Конституциясенең 40 статьясы, ТР Конституциясенең 47 статьясы). Торак дип без гражданнарның даими яисә вакытлыча яшәве өчен билгеләнгән, уңайлыклары булган бинаны атыйбыз. Бу хокук дәүләт, муниципаль, кооператив һәм индивидуаль төзелешне үстерү һәм саклау аша тәэмин ителә. Торакка мохтаҗ булган аз милекле һ. б. гражданнарга ул бушлай бирелә яисә закон тарафыннан куелган нормага туры килә торган бәягә сатыла.

Сәламәтлекне саклауга һәм медицина ярдәменә хокук. Һәркем сәламәтлеген саклауга һәм медицина ярдәменә хокуклы (РФ Конституциясенең 41 статьясы, ТР Конституциясенең 44 статьясы). Бу хокук сәламәтлек саклауны да, авырган очракта аны торгызу мөмкинлеген дә белдерә.

Сәламәтлек саклауның дәүләт һәм муниципаль учреждениеләрендә гражданнарга медицина ярдәме тиешле бюджет, страховой взнос һәм керемнәр хисабына бушлай күрсәтелә. Сәламәтлек саклау хокукы халыкның сәламәтлеген саклау һәм ныгыту программаларын финанслау, сәламәтлек саклауның дәүләт, муниципаль, хосусый системасын үстерү буенча чаралар кабул итү, кеше сәламәтлеген ныгытуга ярдәм итүче эшчәнлекне хуплау, физик культура һәм спортны, экологик һәм санитария-эпидемиология иминлеген үстерү юлы белән тәэмин ителә.

Һәркем куркынычсызлык һәм гигиена таләпләренә җавап бирә торган шартларда хезмәткә, бернинди дискриминацияләүсез һәм федераль законнар яисә Татарстан законнары тарафыннан билгеләнгән минималь күләмнән ким булмаган хезмәт хакы алуга хокуклы.

Законлы ысуллардан файдалану юлы белән шәхси һәм күмәк хезмәт бәхәсләренә хокук та, эш ташлау хокукын да кертеп, танылa (РФ Конституциясенең 37 статьясы, ТР Конституциясенең 50 статьясы).

Әйләнә-тирәдәге табигый мохитне саклау (РФ Конституциясенең 42 статьясы, ТР Конституциясенең 18 статьясы), яхшы сыйфатлы азык-төлек сату гражданнарның сәламәтлеген саклау хокукын гарантияләү булып тора. Гражданнарның уңайлы мохиткә хокуклары аның турында дөрес мәгълүмат

алу һәм экологияне бозу аркасында сәламәтлеккә һәм милеккә килгән зыянны каплау хокукы белән тыгыз бәйләнгән.

Ананың, балачакның, гаиләнең дәүләт яклавына хокукы, шулай ук ата-ананың балалары турында кайгыртуга һәм аларны тәрбияләүгә хокукы мөһим социаль хокуклардан санала (ТР Конституциясенең 30 статьясы).

Мәдәни хокуклар җәмгыять тудырган матди һәм рухи байлыкларга ия булу хокукын беркетә. Бу хокук булган байлыкларны саклый, яңаларын тудыруга ярдәм итә, мәдәният казанышларыннан файдалануда һәртөрле киртәләрне юкка чыгара.

Белем алуга хокук һәрвакыт иң әһәмиятле мәдәни хокук булып исәпләнде (РФ Конституциясенең 43 статьясы, ТР Конституциясенең 48 статьясы). Белем алу — кешенең тормышка, хезмәткә әзерлек чорында билгеле бер күләмдә белемгә ия булуы, аның профессиональ һәм фәнни белемнәрне үзләштерүе. Гражданнарга дәүләт яисә муниципаль гомуми белем учреждениеләрендә һәм предприятиеләрендә мәктәпкәчә, төп гомуми һәм урта профессиональ белем алуның мөмкинлеге һәм түләүсез булуы гарантияләнә. Белем алуның барлык төрләре арасында гомуми урта белем мәҗбүри булып исәпләнә, шуңа күрә ата-аналар һәм аларны алмаштыручы кешеләр балаларның гомуми урта белем алуларын тәэмин итәргә тиешләр. Һәркем дәүләт яисә муниципаль белем бирү учреждениеләрендә һәм предприятиеләрендә конкурс нигезендә түләүсез югары белем алырга хокуклы.

Гражданнарның белем алуга булган хокукларын тәэмин итү өчен дәүләт федераль белем алу стандартларын билгели, белемнең һәм үзлегеңнән укуның төрле формаларын хуплый. Күп милләтле дәүләт шартларында милли мәдәниятне һәм региональ мәдәни традицияләрне саклау дәүләтнең белем бирү өлкәсендәге сәясәтенең төп принципларыннан берсе булып исәпләнә. Россия һәм Татарстан гражданнары тәрбия һәм аралашу телен ирекле сайлау хокукына ия.

Әдәби, сәнгати, фәнни, техник һәм башка иҗат төрләрен һәм укыту хокукын, мәдәни тормышта катнашу һәм мәдәният учреждениеләреннән, мәдәният байлыкларыннан файдалану хокукын РФ Конституциясенең 44 статьясы, ТР Конституциясенең 49 статьясы беркетә. Иҗади эшчәнлекләре белән гражданнар рухи мәнфәгатьләрен тормышка ашыралар, ә аның нәтиҗәсе матди кыйммәткә — интеллектуаль байлык тудыруга китерә.

Сораулар һәм биремнәр: 1. Безнең тормышта хезмәт шартларының куркынычсызлыгына; эш бирүче белән хезмәт бәхәсенә һәм эш таплауга; эшсезлектән саклауга; социаль тәэминатка, закон билгеләгән дәүләт пенсияләре һәм пособиеләренә; хезмәткә федераль һәм Татарстан законы куйган минималь күләмнән ким булмаган түләүгә; ялга хокуклар ничек гамәлгә ашырыла? 2. Гаиләгездә торакка хокукның ничек тормышка ашырылуы турында сөйләгез. 3. Сәламәтлек саклау һәм медицина ярдәменә хокукны; ана булуның, балачакның, гаиләнең дәүләт

саклавына хокукын сез ничек аңлыйсыз? 4. Белем алуга хокук нәрсәне аңлата? Мәсәлән, урта мәктәпне тәмамлаган егетне, музыкаль сәләте җитәрлек түгел дип, консерваториягә алмыйлар. Ул үзен профессияне ирекле сайлауга һәм белем алуга хокуклы дип исәпли. Егет хаклымы? Мондый мәсьәләләрне хәл иткәндә шәхеснең сәләте һәм һәвәслеге хокукый мәгънәгә ияме? 5. Әгәр илдә икътисади кыенлыклар хөкем сөрә икән, әдәби, сәнгати, фәнни, техник һәм башка иҗат төрләре ирегенә, укыту ирегенә хокук, мәдәни тормышта катнашу хокукы, мәдәният учреждениеләреннән файдалану хокукы, мәдәни байлыкларга ия булу хокукы кирәкме?

17. Бала хокуклары турында халыкара документлар

Берничә дәрес дәвамында без сезнең белән зурларның хокуклары һәм бурычлары турында сөйләштек. Нинди хокуклар барлыгын белдек. Бүгенге көндә алар барлык илләрдә дә һәм тулы күләмендә үтәлми. Балаларны яклау исә бөтенләй җитәрлек түгел. Бу проблема әле һаман да кискенлеген югалтмый.

Дөньяда бала хокукларын үтәүнең торышы борчылу уята. Ул бер генә илдә дә уңышлы хәл ителмәгән. Әмма бу уңышсызлыкның дәрәҗәсе төрле илдә төрлечә. Россия дә моның белән мактана алмый. Балалар арасында җинаятьчелек үсә, ата-ана җылысыннан мәхрүм ителгән балалар саны арта, физик һәм психик җитешсезлек белән туган балалар саны да кимеми. Балалар арасында үлүчеләр саны да күп. Радиациядән зарарланган зоналардагы балаларны җитди дәвалау таләп итела. Милләтара ызгышлар тагын бер проблема өстәде — качак балалар саны арта. Илдәге икътисади кыенлыклар бала мәнфәгатьләрендә чагыла — эшсезлек шартларында иң әүвәл балалар газап чигә. Төрле сәбәпләр аркасында дәүләт балаларны яклау буенча үз вазифаларын һәрвакытта да үтәп бетерә алмый.

Бала хокукларын тулырак тәэмин итү өчен, Берләшкән Милләтләр Оешмасы берничә документ кабул итте. Инде игълан ителгән халыкара хокуклардан башка, балаларның үзләренә генә хас хокуклар да бар, алар махсус дәүләт яклавыннан файдаланалар.

Иң әүвәл шуны ачыклыйк: «бала» төшенчәсенә кем керә? БМО үзенең документларында, һәр кеше заты, әгәр ул аңа карата кулланылган закон буенча балигъ булу яшенә иртәрәк җитмәсә, унсигез яше тулганчы бала дип исәпләнә, дип белдерә. Мәсәлән, әгәр унсигез яшькә җитмәгән яшьләр куелган тәртип нигезендә никахка керәләр икән, балалар турындагы документларның положениеләре аларга кагылмый.

Бала хокуклары турындагы халыкара-хокукый документлар арасында БМОның Генераль Ассамблеясы кабул иткән Бала

хокуклары декларациясе (1959) һәм Бала хокуклары турында конвенция (1989) әһәмиятле урын алып тора. Алар Кеше хокукларының гомуми декларациясе буенча һәрбер кеше файдалана торган барлык хокукларны да диярлек балалар өчен дә беркетәләр. Бер караганда, ни өчен аларны кабатлап торырга? Бала кеше түгелмени, ул һәр граждан кебек бер үк проблемалар белән яшәмимени? Мәсьәлә шунда, күп кенә өлкән кешеләр бала әле яшәми, яши башларга әзерләнә генә, ул гүя ата-анасының милке, шуңа күрә аңа нәрсә кирәген ата-ана әйбәтрәк белә, дип уйлыйлар. Менә ни өчен бала хокуклары һәм ирекләре аерым, махсус эшләнгән документларда беркетелгән. Бу документларда бала аерым кайгыртуга һәм ярдәмгә хокуклы дип игълан ителә, аңа, физиологик үзенчәлекләрен, хокукый һәм социаль яклау кирәклеген, күп яклы үсеше өчен тиешле шартлар тудырылу кирәклеген исәпкә алып, киң гражданлык, социаль һәм мәдәни хокуклар гарантияләнә.

Бала хокуклары декларациясе кеше хокукларының кайберләре балаларга турыдан-туры кагыла дип раслый, чөнки алар, яшьлекләре сәбәпле, кайгыртуга һәм игътибарга аеруча мохтаҗ.

Декларация балаларны яклауда зур роль уйнады, аның эчтәлеге балаларга карата шәфкатьлелеккә, гаделлеккә чакыру булып яңгырый.

Бала хокуклары турында конвенция. БМОның Кеше хокуклары буенча комиссиясе конвенция эшләүгә Халыкара балалар елында (1979) керешге. Бу вакытка инде кеше хокуклары турында гаять әһәмиятле халыкара документлар дөнья күрде, бала хокуклары турындагы күзаллаулар да тирәнәйде. Хәтерегездәдер, конвенция — аңа кул куйган кешеләр тарафыннан үтәлергә тиешле шартнамә ул. Документның әлеге статусы аның эчтәлеге турындагы бәхәсләрнең кискенлеген, аны эшләүнең катлаулылыгын һәм дәвамлылыгын (ун ел) билгеләде. 1989 елның 20 ноябрендә БМОның Генераль Ассамблеясы бердәм рәвештә Бала хокуклары турында конвенцияне кабул итте. 1990 елда ул безнең илдә дә ратификацияләнде.

Конвенция бала хокуклары халыкара хокук нормалары көченә кергән иң тулы документ булып исәпләнә. Конвенция киләчәккә вәгъдә булып торуы ягыннан да кыйммәтле, чөнки ул гуманлы, гадел җәмгыятьне үз куллары белән төзиячәк балаларның үсеше өчен уңайлы шартлар тудыруга хезмәт итә. Конвенциянең төп принцибы шуннан гыйбарәт: балаларга карата барлык гамәлләрдә, алар кем тарафыннан кылынса да, игътибар беренче чиратта бала мәнфәгатьләрен тиешенчә тәэмин итүгә юнәлдерелергә тиеш. Бала мәнфәгатьләренә кагылышлы мәсьәләне хәл иткәндә, теләсә кайсы дәүләт органы иң әүвәл шушы мәнфәгатьләрне тәэмин итәргә тиеш. Конвенциядә күрсәтелгән нормалар хөкүмәтләр, партияләр, оешмалар һәм хәрәкәтләр өчен балалар тормышына уңай үзгәрешләр

кертүдә, моңа кирәкле байлыклар туплауда ориентир булып хезмәт итәчәк.

Бу конвенциядә катнашучы дәүләтләр бала хокукларының киң даирәсен тану һәм тәэмин итү бурычын үз өсләренә алдылар. Конвенциянең күп сандагы нормаларын яхшылабрак күз алдына китерү өчен, без аларны, эчтәлекләре буенча аерым төркемнәргә берләштереп, схема рәвешендә бирдек:

22 нче схема

Бала хокуклары турында конвенция
БМО Генераль Ассамблеясы тарафыннан 1989 елның 20 ноябрендә кабул ителде

Нигез хокуклар:
— яшәүгә;
— исемгә;
— хокукларны тормышка ашырудагы тигезлеккә;
— башка хокуклар

Балага гаилә уңайлыклары тәэмин итүче хокуклар:
— ата-ананың балалары турында кайгыртуы;
— дәүләтнең ата-анасыз калган балаларга ярдәм итү бурычы;
— башка хокуклар

Бала шәхесенең ирекле үсешен тәэмин итүче хокуклар:
— үз фикерен ирекле белдерү хокукы;
— ассоциацияләргә берләшү хокукы;
— фикер ирегенә ия булу хокукы;
— вөҗдан һәм дин ирегенә хокук;
— башка хокуклар

Балаларның сәламәтлеген тәэмин итүче хокуклар:
— сәламәтлек саклау системасында иң камилләшкән хезмәт күрсәтүдән файдалану хокукы;
— башка хокуклар

Баланы яклаучы хокуклар:
— икътисади һәм башка төрле эксплуатациядән;
— наркотиклар җитештерү һәм таратуга тартудан;

Балаларга белем алырга һәм аларның мәдәни үсешенә ярдәм итүче хокуклар:
— түләүсез белем алуга хокук;
— мәдәнияттән файдалану хокукы;
— башка хокуклар

Конвенция буенча бала туу мизгеленнән алып исемгә, гражданлыкка, шулай ук мөмкин булганча ата-аналарын белүгә һәм аларның кайгыртуына хокуклы. Баланы көчләп гаиләсеннән, иленнән аеру, исемен алыштыру тыела.

Конвенциядә кызыклы положение бар — бала үзенә кагыла торган барлык мәсьәләләр буенча үз карашын белдерергә хокуклы (әгәр ул аны әйтеп бирергә сәләтле булса) дип тану. Конвенциядә катнашучы дәүләтләр бу карашларга «баланың яшен һәм өлгергәнлек дәрәҗәсен исәпкә алып, тиешле игътибар бирергә» йөкләмә алдылар. Безнең өчен, өлкән кешеме без, әллә баламы, фикеребезгә хөрмәт белән карау гаять әһәмиятле.

«Дүшәмбегәчә яшик әле» кинофильмында өлкән класс укучылары «Нәрсә ул бәхет?» дигән темага сочинение язалар. Бер укучы бик кыска сочинение язып бирә: «Бәхет ул — сине аңлаулары».

Бала үз фикерен ирекле рәвештә белдерергә, шул ук вакытта мәгълүматны һәм теләсә нинди идеяне эзләргә, табарга һәм телдән, язмача яки басмача, яисә сәнгать әсәре формасында һәм башка чаралар ярдәмендә башкаларга тапшырырга хокуклы. Конвенция бала корреспонденциясенең серен саклый. Аңа адресланган хатны берәүнең дә ачарга хакы юк. Бу хокукларны тормышка ашыру башка кешеләрнең хокукларын саклау, дәүләт куркынычсызлыгы һәм җәмәгать тәртибе хакына гына чикләнергә мөмкин.

Конвенция ата-аналарга баланың фикер, вөҗдан, дин ирекен тормышка ашыруында җитәкчелек итү хокукларын һәм вазифаларын йөкли.

Барлык балалар, никахтан туса да, никахсыз туса да, бер үк хокуклардан файдаланырга тиеш. Ата-аналарын югалткан балалар турында кайгыртуны дәүләт үз өстенә ала.

Бала хокуклары һәм аларны социаль яклау турындагы нормаларны билгеләгәндә конвенция, тулы һәм күпкырлы үсеш алсын өчен бала гаилә мохитендә бәхет, мәхәббәт һәм аңлашу эчендә яшәргә тиеш, дигән күзлектән чыгып эш итә. Бу исә баланың шәхесен, намусын һәм хокукларын хөрмәт иткәндә генә мөмкин. Шушындый шартларда тәрбияләнгәндә генә бала иминлек, азатлык, тигезлек һәм бердәмлек идеаллары хөкем сөргән җәмгыятьтә мөстәкыйль тормышка сәләтле була.

Конвенция положениеләренең иң зур өлеше хөкүмәт органнарына, учреждениеләренә, оешмаларына — балачакны яклау өчен кирәкле һәм тәэсирле чаралар кабул итүнең реаль мөмкинлекләренә ия булган куәтле инстанцияләргә юнәлдерелгән. Бала үзен җитәрлек дәрәҗәдә уңай хис итсен өчен, ата-аналар, гаиләнең башка әгъзалары күп нәрсә эшли ала. Шулай булгач, бу положениеләрне сезгә ни өчен өйрәнергә кирәк соң? Беренчедән, сез үзегезнең нәрсәгә хокуклы икәнлегегезне белергә тиеш. Икенчедән, хокукларыгызны хәтерегездә саклап, үзегез дә өлкән кешеләр, ата-аналар булгач, Бала хокуклары турындагы конвенция принципларына тугрылыклы булырсыз.

Конвенциядә бала хокуклары турында гына түгел, күбесенчә анда катнашучы дәүләтләрнең бала хокукларын тәэмин итүдәге йөкләмәләре турында сүз бара. Безнең ил Бала хокуклары турындагы конвенциягә кул куйды һәм аны ратификацияләде. Әмма аның кайбер положениеләре безнең законнарда чагылыш тапмады әле — тормыш моны үзе рөхсәт итми. Озакламый Россиядә бала хокукларының реаль нигезе булыр.

Сораулар һәм биремнәр: 1. Балаларны яклау ни өчен кирәк? Дәүләт, төрле оешмалар, аерым кешеләр тарафыннан бала хокуклары бозылу очракларына мисаллар китерегез. Алар нәрсәдә чагылды, ни өчен иҗтимагый яктан куркыныч булды? 2. Бала хокуклары декларациясе нинди максат белән эшләнде һәм кабул ителде? 3. Бала хокуклары турында конвенция нәрсә ул? Баланың нинди хокуклары бар? 4. Баланың халыкара документларда беркетелгән нинди хокуклары гадәттән тыш булып тоела? Ни өчен? Аларны махсус аерып күрсәтергә һәм беркетергә кирәкме?

18. Кеше хокукларын бозулар һәм аларны саклау

Хокукларның һәм ирекләрнең бозылу очраклары еш була. Моның сәбәпләре төрлечә: җинаятьчелек, бюрократлык, коррупция, эш урыныннан законсыз файдалану. Һәр кешенең алардан законлы төстә сакланырга, ягъни кеше һәм гражданның хокукларын һәм ирекләрен яклауны (саклауны) тәэмин итәргә хокукы булырга тиеш. Бозылган хокукларны яклау — бик зур проблема. Гражданнарның төп хокуклары һәм ирекләре үзләреннән-үзләре тормышка аша дип исәп тоту кыен. Тормышта бу процесслар еш кына конфликтлы төс ала. Шуңа бәйле рәвештә гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен тиешенчә саклау кирәклеге беренче дәрәҗәдәге әһәмияткә ия булган мәсьәләгә әверелә. Гомумиләштереп әйтсәк, бөтен законнар теге яки бу күләмдә кеше хокукын саклауга юнәлтелә.

Төп хокукларны һәм ирекләрне гарантияләү — бу иң әүвәл аларны реаль тормышка ашыруның икътисади, сәяси, шулай ук махсус-юридик (хокукый) чаралары. Хокукый гарантияләрнең тәэсире хокукый дәүләт төзелгән очракта нәтиҗәлерәк була (РФ Конституциясенең 45—54 статьялары, ТР Конституциясенең 21, 33, 34 статьялары). Гражданнарның төп хокуклары һәм ирекләренең хокукый гарантияләре иң әүвәл Конституция һәм халыкара-хокукый стандартларга җавап бирә торган башка хокукый актларда беркетелүдә чагыла. Аларда бу хокукларның һәм бурычларның тәртибе һәм куллану кагыйдәләре төгәл билгеләнә, аларга кул сузу очраклары булганда юридик җаваплылык чаралары карала. Дәүләт кешене аның гражданлыгы, тору урыны, социаль, милек һәм эш уры-

ындагы хәле, расасы, милләте, җенесе, яше, белеме, теле, дингә мөнәсәбәте, сәяси һ. б. инанулары нинди булуга карамастан яклый.

Үзенең хокукын һәм ирекен сакларгамы, юкмы икәнлеген хокук иясе үзе генә хәл итәргә тиеш.

Хокукларны һәм ирекләрне саклау — дәүләт бурычы (РФ Конституциясенең 2 статьясы, ТР Конституциясенең 3 статьясы), хокукларның һәм ирекләрнең дәүләт тарафыннан яклануы гарантияләнә (РФ Конституциясенең 1 бүлеге, 45 статьясы, ТР Конституциясенең 25 статьясы). Шәхес хокукларын һәм ирекләрен яклау тоташ бер чаралар комплексын эченә ала. Аларның иң әһәмиятлеләренә түбәндәгеләр керә:

1. *Шәхеснең ирекләре һәм хокуклары бозылу фактларын ачыклау, кисәтү һәм булдырмау.* Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының иң югары вәкиллекле һәм башкарма органнары хокукларны һәм ирекләрне нығытуга, аларны яклауны камилләштерүгә, аларны үтәүдәге җаваплылыкны арттыруга юнәлдерелгән норматив актлар кабул итәләр. Хокук саклау органнары хокук бозуны кисәтү белән шөгыльләнәләр, гражданнарның хокукларына һәм ирекләренә кул сузучы җинаятьләрне ачалар һәм тикшерәләр.

2. *Шәхеснең бозылган хокукларын һәм ирекләрен торгызу.* Ул, кагыйдә буларак, законсыз юридик актларны юкка чыгару (мәсәлән, кешене эштән азат итү турындагы боерыкны); китерелгән зыянны каплау бурычын йөкләү (зарарланган транспорт средствосын ремонтлаган өчен түләү һ. б.); милекне иясенә кире кайтару (урланган әйберне суд карары белән иясенә кире бирү һ. б.); намусны һәм кешелек дәрәҗәсен пычрата торган мәгълүматларны кире кагу юлы белән тормышка ашырыла.

3. *Юридик җаваплылык нормаларын куллану.* Бу — шәхеснең ирекләрен һәм хокукларын бозу фактларына дәүләтнең шактый кискен җавабы. Гаепле кешене билгеле бер уңайлылыклардан мәхрүм ителү рәвешендәге тискәре нәтиҗәләр көтә, әйтик, җәза чаралары билгеләнә. Алар хокук бозучының үзенә дә (иректән мәхрүм итү, эштән азат итү һ. б.), аның милкенә дә (конфискация, штраф һ. б.) кагылырга мөмкин.

Дәүләт эчендә шәхеснең хокукларын һәм ирекләрен яклау. Кеше һәм гражданның хокуклары һәм ирекләренең гомуми гаранты булып югары һәм җирле хакимият һәм идарә органнары тора.

Конституциядә һ. б. закон актларында шәхес хокукларын беркетү һәм аларны гарантияләү 23 нче схемада күрсәтелгән.

23 нче схема



Россия Федерациясе Президенты (РФ Конституциясенең 2 бүлеге, 80 статьясы) һәм Татарстан Республикасы Президенты (ТР Конституциясенең 107 статьясы) гарант булып торалар.

Махсус бер вазифа да бар — кеше хокуклары буенча вәкаләтле кеше (Дәүләт Думасы тарафыннан билгеләнә).

Барлык дәүләт органнары үз вәкаләтләре кысаларында кеше хокукларын һәм ирекләрен тәэмин итәргә һәм сакларга тиеш. Шул ук вакытта махсус органнар да бар, алар өчен гражданнарның төп хокукларын һәм ирекләрен саклау төп вазифа булып тора. Аларга суд, прокуратура, җәмәгать тәртибен саклау органнары, алдан тикшерү органнары, адвокатура, юстиция органнары, арбитраж, нотариат һ. б. керә. Аларның һәркайсы, үзләренә генә хас чаралар, ысуллар, формалар һәм методлар кулланып, үз вәкаләтләре кысаларында эш итәләр.

Дәүләтнең кеше һәм гражданның хокукларын һәм ирекләрен яклавы һәркемнең үз хокукларын закон тарафыннан тыелмый торган барлык ысуллар белән мөстәкыйль рәвештә актив яклавын да кире какмый. Саклану чаралары төрлечә: җинаятьчел төстә кул сузуны мөстәкыйль рәвештә кире кайтару, массакүләм мәгълүмат чараларына, җәмәгать оешмаларына мөрәҗәгать итү һ. б. Әмма бу очракта җәмәгать тәртибен бозу, дәүләт органнары эшендә буталчыклык китереп чыгару, хокук саклауның рөхсәт ителгән чигеннән чыгып китү тыела.

Моннан тыш, әгәр бу аларның вазифалары даирәсенә керсә (сәламәтлек саклау, мәгариф органнары, балигъ булмаганнар эше буенча комиссияләр һ. б.), яшүсмер хокукларын идарә органнары һәм җәмәгать оешмалары да яклый ала. Никахны өзгәндә, әгәр гаиләдә бала бар икән, бу органнар баланы ата-ананың кайсысы тәрбиясендә калдырырга кирәклеге турында белешмә бирәләр.

Шәхес хокукларын һәм ирекләрен халыкара яклау. Дәүләт эчендәге хокук яклау чаралары кулланылып бетсә, һәр кеше Россия Федерациясенең халыкара шартнамәләре нигезендә кеше хокукларын һәм ирекләрен яклау буенча дәүләтара органнарга мөрәҗәгать итә ала (РФ Конституциясенең 3 бүлеге, 46 статьясы). Кеше хокукларын халыкара яклау дәүләтләрнең хокук бозуларны кисәтү һәм бетерү буенча уртак гамәлләре нәтиҗәсендә барлыкка килде. Дәүләтләрнең бу юнәлештәге эшләрен БМО берләштерә.

Кеше хокуклары өлкәсендәге эшчәнлекне яраштыручы орган сыйфатында, БМО Уставына туры китереп, 1946 елда Кеше хокуклары буенча комиссия төзелде. Комиссия тәкъдимнәр әзерли, БМОның кеше хокуклары өлкәсендәге документларын эшли, кеше хокукларын бозу турындагы шикаятьләрне һәм хәбәрләрне карый. Кирәк очракта комиссия бәйсез экспертлар ярдәмендә тикшерү үткәрергә хокуклы. Ул шулай ук ел саен үзенең ачык утырышларында кеше хокукларын бозу фактларын тикшерә.

БМОда тагын бер махсус орган — Кеше хокуклары комитеты да оештырылган. Ул дәүләтләрнең, шул исәптән Россиянең, Гражданлык һәм сәяси хокуклар турында пакт (1966) буенча алган йөкләмәләренең үтәлешен тикшерә, хөкүмәтләрнең игътибарын кеше хокукларын тәэмин итү зарурлыгына юнәлтә.

БМО нинди дә булса дәүләтне үзенең практикасын яки сәясәтен үзгәртергә ничек мәҗбүр итә? Бу халыкара оешманың мәҗбүр итү ысуллары юк, ул ышандыру, халыкара иҗтимагый фикер туплау, икътисади санкцияләр кертү юлы белән эш итә. Хәрби катнашу — Куркынычсызлык Советы карары белән күрелә торган гадәттән тыш чара.

Сораулар һәм биремнәр: 1. Шәхес хокукларын һәм ирекләрен яклау төшенчәсен сез ничек аңлыйсыз? Шәхеснең хокукларын һәм ирекләрен яклау ни өчен кирәк? 2. Граждан үзенең хокукларын һәм ирекләрен нинди ысуллар белән яклый ала? Дәүләтнең нинди органнары эшчәнлеге шәхес хокукларын һәм ирекләрен турыдан-туры яклауга юнәлдерелгән? 3. Суд яклавы төшенчәсе нәрсә ул? Суд яклавы хокукының асылы нидән гыйбарәт? Суд яклавының нинди ысулларын беләсез? 4. Кеше хокукларын һәм ирекләрен халыкара яклау нәрсәдә чагыла?

IV бүлек

Гамәлдәге законнар

19. Ватанны саклау — һәр гражданның изге бурычы

Бөтендөнья тарихы битләрен актарып карагыз әле, кешеләрнең беркайчан да сугышларсыз яшәмәгәнлеген күрерсез. Бүгенге көндә дә сугышалар. Аларның һәркайсы — фаҗига. Бүген дөньяда күп нәрсә үзгәреш кичерә. Акыл өстенлек алыр һәм кешеләр сугыш дигән афәтне онытырлар дигән өмет арта бара. Әмма хәзергә әле моңа ышаныч аз, дөньяда агрессив көчләр һаман да кимеми. Армиясез яшәргә мөмкин түгел. Шуңа күрә дәүләтебез оборона сәләтен, Кораллы Көчләрен ныгыта. Тыныч хезмәт халкын яклау — дәүләтебезнең иң мөһим бурычы. Дәүләт органнарының, иҗтимагый оешмаларның, урындагы кешеләрнең һәм гражданнарның ил куркынычсызлыгын һәм аның оборона сәләтен ныгыту буенча вазифалары Россия Федерациясе Конституциясе һәм Россия законнары тарафыннан билгеләнә.

Ватанны саклау вазифасы Россия Федерациясе Конституциясендә гражданның бурычы итеп билгеләнгән. «Бурыч» сүзе биредә ике мәгънәдә — хокук һәм әхлак мәгънәсендә кулланыла. Ватанны саклау — Россия гражданнарының юридик кына түгел, әхлакый бурычы да. Чөнки Ватан — дәүләт кенә түгел, иң әүвәл ул — гаилә, дуслар, туганнар, безнең табигатебез, ягъни туган илгә булган мәхәббәтебезне тәэмин итүче әйләнә-тирәдәге һәммә нәрсә.

Татарстан Республикасы Конституциясенең 58 статьясы республика гражданнарына закон нигезендә хәрби хезмәтне үтәү бурычын йөкли.

Туган илгә мәхәббәт, җәмгыять алдындагы бурыч һәр гражданны Ватанны саклау буенча изге бурычын үтәргә мәҗбүр итә. Батырлык һәм фидакарьлек үрнәкләренә мисаллар күп. Тарих буенча Александр Невский, Дмитрий Донской, Кузьма Минин һәм Дмитрий Пожарский, Александр Суворов, Михаил Кутузов һ. б. бик күп күренекле шәхесләрнең байрагы ас-

тында тупланып, фидакарьләрчә көрәшкән сугышчылар батырлыгын исегезгә төшерегез. Ни өчен Туган илне саклау бурычы — изге вазифа? Чөнки көрәш гаделлек өчен барган.

Тарихтан бер эпизодны искә төшерегез.

Россия тормышында драматик чор — 1812 елда Бородино сугышыннан соң рус армиясенең башкомандующие Михаил Илларионович Кутузов Мәскәүне французларга калдырырга әмер бирә. Бу карар армиядә дә, җәмгыятьтә дә бер төрле генә кабул ителми. Кутузов һәммә нәрсәне дә куркыныч астына куя. Әгәр аның гомуми планы тормышка ашмаса, ул императорның каты җәзасына дучар булыр, ә халык хәтеренә куркак җан булып кереп калыр иде. Наполеон белән хәлиткеч сугышка керсә, җиңелгән очракта да намусы чиста калыр иде. Әмма ул болай фикер йөртә: Мәскәүне югалту — Россияне югалту түгел, ә армияне югалту — бөтен нәрсәне югалту. Һәм Кутузов үзенең исемен, дәрәҗәсен куркыныч астына куя. Ватанны саклау бурычы аның өчен шәхси иминлектән өстен була.

Ватанны сакларга, үзеңнең изге бурычыңны үтәргә әзерләнү мәктәптә үк башлана. 17 яше тулган егетләр медицина тикшерүе узалар һәм яшәү урыннары буенча хәрби комиссариатлар тарафыннан район (шәһәр) хәрби хезмәткә алыну участокларында теркәләләр, теркәлү таныклыклары алалар һәм хәрби хезмәткә алынучылар дип йөртелә башлыйлар.

Закон буенча хәрби бурыч гамәлдәге хезмәттән һәм запаста торудан гыйбарәт. Гамәлдәге хәрби хезмәткә, расасы, милләте, дине, белеме, яшәү урыны, социаль хәле һәм мөлкәте нинди булуга карамастан, хәрби хезмәткә алыну вакытына унсигез яше тулган егетләр чакырыла. Хәрби уку йортларында белем алырга теләүчеләр унҗиде яшьтән дә чакырылырга мөмкин.

Гамәлдәге хәрби хезмәткә чакырылу Россия Федерациясенең оборона министры боерыгы буенча елга ике тапкыр (май — июнь һәм ноябрь — декабрь айларында) үткәрелә. Хәрби хезмәткә алыну участокларына килүнең төгәл срогы чакыру кәгазендә күрсәтелә. Чакыру кәгазен алгач, хәрби хезмәткә алынучы төгәл срокта үзенең участогына килергә тиеш. Предприятие, оешма, уку йортлары җитәкчеләре моның өчен хәрби хезмәткә алынучыны эштән яки укудан азат итәргә, командировкалардан чакырып кайтарырга тиешләр.

Кайбер очракларда егетләргә хәрби хезмәткә алынуны кичектерү мөмкинлеге бирелә. Ул чакыру комиссиясе тарафыннан гаилә хәле, мәсәлән, ике яисә аннан күбрәк баласы булган очракта, әтисе яки әнисе хезмәткә яраксыз булган очракта (ул вакытта граждан аларны карарга тиеш), урта мәктәпне тәмамлау өчен, шулай ук югары уку йортының көндезге бүлеге студентларына бирелә. Тәртипсезлекләре һәм начар укулары аркасында укудан чыгарылган студентлар мондый хокукларын югалталар.

Гражданнар гамәлдәге хәрби хезмәткә 27 яшькә җиткәнче чакырыла. Шуннан соң (тыныч тормышта) запаска теркәләләр.

Кайбер очракта законда гамәлдәге хәрби хезмәткә хатын-кызларны чакыру да каралган. Медицина буенча яисә башка махсус әзерлекле 19 яшьтән 40 яшькә кадәрге хатын-кызлар тыныч тормышта хәрби исәпкә алынырга һәм өйрәнү пунктларына чакырылырга мөмкин. Алар үз теләкләре белән гамәлдәге хәрби хезмәткә дә алынырга мөмкин.

Законда гамәлдәге хәрби хезмәтнең түбәндәге сроклары каралган:

солдатлар һәм сержантлар өчен (шулай ук Хәрби-Диңгез Флотының яр буе частьлары, чик буе һәм эчке гаскәрләр өчен) — 2 ел;

югары белеме булган солдатлар һәм сержантлар өчен — 1 ел;

Хәрби-Диңгез Флоты корабльләре, суднолары һәм яр буе частьлары матрослары һәм старшиналары (шулай ук чик буе гаскәрләренең диңгез частьлары) өчен — 3 ел;

югары белеме булган матрослар һәм старшиналар өчен — 1,5 ел.

Офицерлар составы өчен закон билгеле бер яшьне куя, шул яшькә җиткән гражданнар гамәлдәге хәрби хезмәттән запаска чыгарыла. Өлкән офицерлар составы өчен бу 45—50 яшьне тәшкил итә.

Хәрби хезмәткәрләр һәм хәрби хезмәттә булырга тиешле кешеләр строй алдында туган илләренә, халыкка тугры булырга тантаналы төстә хәрби ант кабул итәләр, хәрби хезмәтнең Уставта беркетелгән кагыйдәләрен үтәргә вәгъдә бирәләр. Антның тексты имза белән ныгытыла. Һәркем өчен хәрби анттагы сүзләр изге булып исәпләнә. Теләсә нинди шартларда да антка тугры булып калу — иң югары сугышчан батырлык. Меңнәрчә кеше сугышчан бурычларын үтәгәндә гомерләрен дә кызганмадылар.

Василий Быковның «Сотников» повестенда гаять катлаулы хәлдә калган сугышчылар турында сөйләнә. Ике партизан — Рыбак һәм Сотников — фашистлар кулына төшә. Рыбак хәйләләмәкче була: немецлар ягына чыккан булып, уңайлы очракны көтеп торырга һәм партизан отрядына качарга. Моның өчен полицай булырга туры килә. Немецлар аңа яңа хуҗаларга тугрылыгын эш белән расларга кушалар. Сотников исә алар белән хезмәттәшлек итүдән кискен рәвештә баш тарта, аны җәзалыйлар. Тешләрен кысып булса да, Сотников төрлечә мыскыллауларга түзә, сынмый. Эшафотка да антына тугрылыклы калып, халкы алдындагы изге бурычын үтәгән батыр булып күтәрелә. Рыбак аны җәзалаган вакытта якында гына басып тора. Аңа үзен аклау мөмкинлеге була: автоматын күтәреп, дошманнарга атасы гына. Әмма ул куркак, әлеге моменттан файдаланмый. Язучы Рыбакның ничек газаплануын сурәтли, әмма бу — куркак җанның газаплануы; ул үз-үзенә кул салырга да маташа, ләкин барып чыкмый. Язмыш аны тагын да катырак җәза — вөҗдан газабы кичерүгә дучар итә. Ике кеше — ике төрле язмыш, һәрберсе аны үзе сайлый. Кеше яшәү белән үлем арасында торганда әхлакый дәрәҗәсе кушканны сайлап ала. Берсе — үлемне, икенчесе — хыянәтне...

Гамәлдәге хәрби хезмәткә чакырылучы гражданнарга һәм аларның гаиләләренә кайбер өстенлекләр каралган. Әгәр граждан армиягә уку йортыннан алынса, аның запаска җибәрелгәннән соң әлеге уку йортына кабул ителү хокукы саклана. Хезмәт законнары буенча хәрби хезмәткәрләрнең элекке эш урыннарына кайту хокукы да саклана. Торак турындагы законнар аларның торак мәйданын яисә аны алу чиратын саклый. Хезмәт итү вакыты эш стажына керә. Җирле идарә органнары гамәлдәге хәрби хезмәткә алынучыларның гаиләләре турында да онытмаска тиешләр. Хәрби хезмәткәрнең хатыны бер ай эчендә — эшкә, ә баласы балалар бакчасына яисә яслегә аның нинди ведомствога керүенә карамастан урнаштырылырга тиеш. Билгеле бер срокка чакырылган хәрби хезмәткәрнең баласына дәүләт акчалата ярдәм күрсәтә.

Хәрби хезмәткәрләр һәм хәрби хезмәтне үтәргә тиешле кешеләр гражданнарның Конституциядә каралган барлык хокукларыннан файдаланалар. Бер үк вакытта закон аларга бурычлар йөкли һәм хәрби хезмәт таләпләреннән чыга торган катгый җаваплылык билгели. Хәрби учет кагыйдәләрен бозган, хәрби комиссариат чакыруына сәбәпсез килми калган, хәрби билетны яки теркәлү таныклыгын югалткан кеше штрафка тартыла. Гамәлдәге хәрби хезмәттән баш тарту җинаять дип исәпләнә һәм РФ Җинаять кодексының 328 статьясы буенча («Хәрби хезмәт һәм альтернатив гражданлык хезмәтен үтәүдән баш тарту») җинаять җаваплылыгына тартыла. Хәрби хезмәт үтү тәртибенә каршы булган башка гамәлләр дә җинаять дип исәпләнә: боерыкны үтәмәү, часть урнашкан җирдән рөхсәтсез китү, дезертирлык, хәрби серне сакламау. Ватанга хыянәт итү иң авыр җинаять буларак хөкем ителә.

Сораулар һәм биремнәр: **1**. Ни өчен Ватанны саклау изге бурыч булып исәпләнә? «Изге бурыч» сүзен сез ничек аңлыйсыз? Әдәби әсәрләрдән яисә вакытлы матбугаттан Ватанны саклау бурычын Россия гражданнарының ничек үтәгәнлекләрен һәм үтәүләрен күрсәткән мисаллар китерегез. Үз якташларыгызның героик батырлыкларын сурәтләүче мисаллар табыгыз. **2.** Ни өчен Кораллы Көчләрдә хезмәт итү мактаулы бурыч булып исәпләнә? Ватанны сакларга әзер булыр өчен кеше нинди сыйфатларга ия булырга тиеш? Хәрби антның эчтәлеге нидән гыйбарәт? Аның төп мәгънәсе нәрсәдә? **3.** Санап кителгән хәрби гамәлләрнең кайсыларын Ватанны саклау бурычы дип исәпләргә мөмкин, ә кайсыларын — юк:

— тыныч вакытта хәрби объектка ясалган һөҗүмне кире кайтару;
— үз иленнең гражданнарын «тынычландыру»;
— чит дәүләт территориясенә гаскәрләр кертү;
— ил чикләрен чит илләр һөҗүменнән саклау;
— хәрби куркыныч туу турында үз вакытында хәбәр итү өчен сугышчан дежурда тору;
— чит территорияләрне басып алырга әзерләнү;
— союзникларыңа ярдәм күрсәтергә әзерләнү?

4. Әфган сугышы нинди бәя алды? «Әфганчылар» кемнәр алар? «Әфганчылар»га карата миһербансызлык һәм каты күңелллелек кайда чагыла? Бу кешеләргә карата нинди мөнәсәбәт булырга тиеш? **5.** Хәрби хезмәткәрләр һәм аларның гаиләләре өчен законда нинди өстенлекләр каралган? Хәрби хезмәткәрләрнең һәм хәрби хезмәт үтәргә тиешле кешеләрнең юридик җаваплылыгы нинди? **6.** Туганнарыгыздан һәм танышларыгыздан аларның армия хезмәте, анда бигрәк тә нәрсә хәтерләрендә калганлыгы, аны ничек бәяләүләре турында сорашыгыз. Аларның истәлекләреннән, фоторәсемнәреннән файдаланып, хикәя әзерләгез.

20. Административ хокук

Административ хокук чыганаклары. Административ хокук нормалары Россия Федерациясенең 1984 елның 20 июнендә кабул ителгән административ хокук бозулар турындагы Кодексында урын алган. Административ санкцияләр күрсәтелгән хокукый актлар Федерация субъектларының хакимият органнары тарафыннан чыгарылырга мөмкин. Халык депутатларының район, шәһәр, шәһәр районнары, округ, өлкә һәм край Советлары, үз вәкаләтләре кысаларында, эпидемияләр һәм табигый бәла-казалар белән көрәш мәсьәләләре буенча административ санкцияле актлар кабул итәргә хокуклы. Административ хокуктагы норматив актларның күләме шактый зур, аның исемлеге өчен генә дә берничә китап кирәк булыр иде.

* * *

Хокукның әлеге тармагының килеп чыгуы һәм исеме турында берничә сүз. Административ хокук хокукның шактый «иске», фундаменталь тармакларына керә. Тарихи яктан бу тармак XVII—XVIII гасырларда Көнбатыш Европаның зур тизлек белән үсүче эре шәһәрләрендә җәмәгать тәртибен җайга салу ихтыяҗыннан барлыкка килә. «Администрация» сүзе латин телендә «идарә итү», «җитәкчелек» дигәнне аңлата. Шуңа күрә административ хокук юридик фәндә идарә итү хокукы буларак билгеләнә.

Дөрестән дә, административ хокук нормалары идарә аппаратының оештырылуын һәм эшләвен, дәүләт идарәсе органнарының һәм гражданнарның үзара мөнәсәбәтен җайга сала. Шуның белән беррәттән административ хокук нормалары җәмәгать тәртибен, гражданнарның гомерләрен, хокукларын һәм ирекләрен саклау өлкәсендәге тәртипне тәэмин итүгә юнәлдерелгән. Бу нормалар җәмгыять тормышының гадәттән тыш киң өлкәсен үз эченә ала. Мөгаен, беркемнең дә административ хокук тәэсиренә эләкми калган көне юктыр.

Дәүләт идарәсенең нәрсә икәнлеген карап үтик. Идарә аша башкаручы хакимият гражданга һәм җәмгыятькә хезмәт

итәргә «чыга». Идарә итү тармагын, кагыйдә буларак, министрлык җитәкли, аның башында министрлыкка йөкләнгән вазифаларның үтәлүе өчен персональ җаваплы министр тора. Бүгенге көндә федераль дәрәҗәдә социаль тормышның төрле өлкәләрендә 20 дән артык министрлык эшли, алар арасыннан эчке эшләр, тышкы эшләр, финанс, икътисад, оборона, юстиция һ. б. министрлыкларны атарга була.

Мәгариф, җәмәгать тәртибен саклау һәм җинаятьчелек белән көрәш өлкәсендә идарә итүнең ничек тормышка ашырылуын карап үтик.

Мәгариф өлкәсендә идарә. Белем алуга хокук — Россия һәм Татарстан гражданнарының төп һәм аерылгысыз хокукларыннан берсе. Дәүләт гомуми урта һәм махсус урта белем алуның бушлай булуын, дәүләт яисә муниципаль учреждениеләрдә һәм предприятиеләрдә конкурс нигезендә бушлай һөнәри белем алуны гарантияли. Мәгариф учреждениеләре дәүләтнеке, муниципаль һәм дәүләттән тыш (хокукый, иҗтимагый һәм дини) булырга мөмкин. Шул ук вакытта аларның һәркайсы өчен бердәм дәүләт мәгариф стандарты бар, ул аны үзләштерүгә тиешле контроль ясауны күздә тота. Шуның белән бөтен җәмгыятьнең мәнфәгатьләрен исәпкә алу тәэмин ителә.

Мәгариф органнары системасын Россия Федерациясендә РФ Мәгариф министрлыгы, Татарстан Республикасында ТР Мәгариф министрлыгы җитәкли. Федерация субъектларына һәм хакимиятнең муниципаль органнарына мәгариф идарәсен оештыруда киң хокуклар бирелгән.

Һәр мәктәп коллективының тормышы Устав дигән норматив акт ярдәмендә оештырыла. Уку йорты өчен ул үзенә күрә бер закон булып тора, аның таләпләрен укытучылар, укучылар, шулай ук ата-аналар үтәргә тиеш. Укучыларның һәм аларның ата-аналарының хокуклары һәм бурычлары Устав белән билгеләнгән. Хокуклар, табигый ки, бурычлардан аерылмаска тиеш. Аларны бер бөтен итеп карарга кирәк. Хокуклар һәм бурычлар сурәтләнгән схеманы җентекләп өйрәнегез.

24 нче схема

Укучыларның хокуклары һәм бурычлары

Хокуклар:	**Бурычлар:**
— түләүсез белем алуга; — белем алу формасын сайлауга (белем бирү учреждениесендә, үзлегеңнән уку яки экстернат); — шәхси план буенча укуның тизләтелгән курсына;	— гомуми белем бирү учреждениесе Уставының барлык положениеләрен төгәл үтәү; — намус белән уку; — учреждение милкенә сакчыл мөнәсәбәттә булу;

— китапханә фондыннан түләүсез файдалануга; — өстәмә (шул исәптән түләүле) белем алуга; — учреждение уставы билгеләгән формада белем бирү учреждениеләре белән идарә итүгә катнашуга; — кешелек дәрәҗәсенең ихтирам ителүенә, вөҗдан һәм мәгълүмат ирегенә, үз карашларыңны ирекле белдерүгә	— башка укучыларның һәм педагогларның намусын һәм кешелек дәрәҗәсен хөрмәт итү; — Устав нигезендә эш итүче учреждение хезмәткәрләренең таләпләрен үтәү; — эчке тәртип кагыйдәләренә буйсыну

Тәртип укучыларның һәм педагогларның кешелек дәрәҗәсен хөрмәт итүгә нигезләнә. Әмма Гомуми белем бирү учреждениеләре уставы кагыйдәләрен бозган очракта укучыларга карата төрлечә йогынты ясау ысуллары да каралган. Хәтта соңгы чара — хокук бозган, Уставны берничә тапкыр тупас рәвештә үтәмәгән өчен 15 яшькә җиткән укучыларны мәктәптән чыгару чарасы да бар. Программаны үзләштермәгән укучылар гомуми белем бирү учреждениеләренең киләсе баскычына үткәрелмиләр. Зуррак хокук бозулар өчен укучыларга тәрбияви характердагы мәҗбүр итү чаралары кулланыла, мәсәлән, махсус укыту-тәрбия учреждениеләренә җибәрү. Бу учреждениеләр ачык яки ябык типта булырга мөмкин. Ачык типтагы учреждениеләр тәртипләре закон кысаларына сыймаган балалар һәм яшүсмерләр (гомуми белем мәктәпләренә йөрүдән баш тартучылар, ата-аналары белән мөнәсәбәтләре начарланганнар) өчен төзелә. Ябык типтагы учреждениеләр Җинаять кодексында каралган иҗтимагый куркыныч гамәлләр кылган укучылар өчен төзелә. Мондый учреждениеләрдә территорияне саклауны һәм аларның үз теләкләре белән территориядән китү мөмкинлеген бетерүне, тәүлек әйләнәсендәге күзәтү һәм контрольне, тәрбияләнүчеләрнең шәхси әйберләрен, аларга җибәрелгән посылкаларны, бандерольләрне тикшереп торуны күздә тоткан махсус режим булдырыла. Ябык типтагы учреждениеләрдә тәрбияләнүчеләрне бередә өч елдан да артык тотмыйлар.

Җәмәгать тәртибен саклау һәм җинаятьчелек белән көрәш өлкәсендә идарә. Җәмәгать тәртибен саклау һәм җинаятьчелек белән көрәшү — дәүләт идарәсенең әһәмиятле функцияләре. Һәр граждан гомеренә, сәламәтлегенә, үз йортындагы һәм җәмәгать урыннарындагы милкенә куркыныч янаудан имин булса гына дәүләт хокукый дип атала ала. Җәмәгать тәртибе — иҗтимагый әһәмияткә ия булган урыннардагы (урамнар, проспект, мәйдан, вокзал, базар, кибетләр, күңел ачу урыннары һ. б.) тәртип ул. Җәмәгать урыннарында бул-

мый гына яшәргә мөмкинме соң? Юк, билгеле. Шуңа күрә җәмәгать тәртибен саклау җәмгыять һәм аерым бер граждан өчен зур әһәмияткә ия.

Җәмәгать тәртибен саклау — җәмгыятебезнең барлык әгъзаларының, шул исәптән балигъ булмаганнарның да, конституцион бурычы. Культурасызлык, тәрбиясезлек, тотнаксызлык, кешеләргә һәм җәмгыятькә карата ихтирамсызлык, эчүчелек еш кына хулиганлыкка һ. б. хокук бозуларга китерә. Нәкъ менә җәмәгать тәртибен саклау, тынычлык һәм куркынычсызлык мәсьәләләрендә әхлак һәм хокук нормаларының тыгыз бәйләнгән булуы очраклы түгел. Әлеге бурычны үтәүдә төп вазифа Россия Эчке эшләр министрлыгы органнары системасына керә торган җәмәгать куркынычсызлыгы милициясенә йөкләнгән. Үз бурычларын тормышка ашыру өчен милиция хезмәткәрләренә мәҗбүр итү чаралары куллану хокукы бирелгән: граждааннардан һәм урындагы кешеләрдән хокук бозуларны туктатуны таләп итү; гражданнарның һәм урындагы кешеләрнең, әгәр хокук бозуда шик тудыручы нигез җитәрлек булса, шәхесләрен раслаучы документларын тикшерү; гражданнардан һәм башка кешеләрдән кирәкле аңлатмалар, белешмәләр, мәгълүматлар алу; административ хокук бозу турында беркетмә язу һәм административ тоткарлауны, җинаять кылынган очракта — җинаять-процессуаль тоткарлауны тормышка ашыру; җинаять кылуда шикләнелгән кешеләрне эзәрлекләгәндә, гражданнарның торакларына яисә башка урыннарына тоткарлыксыз үтеп керү һ. б.

Милиция хезмәткәре көч куллана аламы? Әйе, ала. Хәтта алай гына да түгел, махсус чаралар һәм утлы корал да куллана ала. Мондый хәлләрне һәр граждан белергә, аңлашылмаучылык булмасын өчен, милиция хезмәткәрләренең гамәлләренә дөрес бәя бирә алырга тиеш. Милиция хезмәткәре хокук бозучыны тоткан вакытта, әгәр тегесе каршылык күрсәтсә һәм башка тоткарлау ысуллары җитәрлек булмаса, көрәш алымнарын да кертеп, көч кулланырга хокуклы. Махсус чараларны (резин таяклар, кул богаулары, яшь агызучы газ һ. б.) милиция хезмәткәрләре җинаятьченең гражданнарга һөҗүмен туктатканда; кешенең гомеренә, сәламәтлегенә, милегенә зыян салучы җинаятьче аны тоту һәм милициягә алып килү вакытында каршылык күрсәткәндә; массакүләм тәртипсезлекләрне бастырганда; кушылган таләпне үтәмәгән шоферның машинасын туктатканда кулланырга хокуклы. Махсус чаралар кече яшьтәгеләргә карата (аларның кораллы каршылык күрсәтүе, төркемнәре белән һөҗүм итүе яки гражданнарның гомеренә һәм сәламәтлегенә кул сузуы очракларын исәпләмәгәндә) кулланылырга тиеш түгел.

Утлы корал куллану гадәттән тыш хәл булып исәпләнә, ләкин, кызганыч, алар тормышта торган саен ешрак очрый. Милиция хезмәткәрләренең гражданнарны аларның гомере һәм

сәламәтлеге өчен куркыныгч булган һөҗүмнәрдән саклаганда; милиция хезмәткәренең коралын тартып алу куркынычы булганда; заложникларны азат иткәндә; авыр җинаять кылган яки кораллы каршылык күрсәткән кешене тотканда; гражданнарның торакларына яки башка объектларга төркем белән яки кораллы һөҗүмне туктатканда; сак астыннан качучыны тотканда; шоферы кешеләрнең гомере һәм сәламәтлеге өчен куркыныч тудыручы хәл китереп чыгарган транспорт чарасын туктатканда; гражданнарны куркыныч җанвар һөҗүменнән саклаганда корал кулланырга хокукы бар. Балигъ булмаганнарга карата корал куллану (аларның төркем белән яки кораллы һөҗүмен исәпләмәгәндә) тыела. Милиция хезмәткәре, үзенең таләпләрен үтәү өчен вакыт биреп, корал яки башка махсус чаралар кулланачагы турында алдан кисәтергә тиеш. Әгәр билгеле бер шартларда мондый кисәтү урынсыз һәм мөмкин булмаган хәл булса, ул чагында нишләргә? Ул очракта милиция хезмәткәренә закон алдан кисәтүсез генә корал кулланырга рөхсәт итә. Шулай ук тоткарланучы милиция хезмәткәренә тиешле ераклыктан якынрак килгән очракта да корал кулланырга мөмкин.

Административ хокук бозу төшенчәсе. Җәмгыятькә каршы юнәлгән, гомуммәҗбүри кагыйдәләрне боза торган, белеп яки саксызлык аркасында эшләнгән гаепле гамәл (хәрәкәт) яки хәрәкәтсезлек административ хокук бозу дип исәпләнә һәм аның өчен административ җәза бирү чарасы кулланыла. Аңлаешлырак булсын өчен, берничә мисал карап үтик.

Граждан кинотеатрга исерек хәлдә килә, сеанс вакытында сызгырып утыра, экранда сурәтләнгән хәлләргә кычкырып һәм затсыз рәвештә аңлатма биреп бара, башкаларга фильмны карарга комачаулый. Аны милициягә алып киләләр. Бүлек начальнигы аңа штраф сала.

Икенче мисал. Казанның үзәк универмагы янында берәү «уймак» уены оештыра, өч уймакның кайсысы астында борчак ятуын белергә кирәк. Уенда катнашучылар билгеле бер суммадагы акчаны алдан биреп куялар. Белә алсаң — акча синеке, юк икән, ул уенны оештыручыга күчә. Акчаның күпчелек очракта әлеге алдакчыга күчүе ачыклана. Милиция хезмәткәре азартлы уен оештыручыга штраф сала. Һәр ике мисал административ гаепкә керә.

Административ гаеп җинаятьтән аерыла: аның зыяны судка бирерлек үк зур түгел. Шуңа күрә административ гаеп өчен суд каршында түгел, ә дәүләт идарәсе органнары алдында җавап тотарга кирәк. Хокук бозуларның кайберләрен карап үтик. Җәмәгать тәртибен саклау өлкәсендә нинди хокук бозулар күзәтелә? Иң әүвәл, вак хулиганлык. Җәмәгать урыннарында сүгенү, гражданнарга бәйләнү һәм шуңа охшашлы башка гамәлләр җәмәгать тәртибен һәм кешеләрнең тынычлыгын боза. Бу — әхлаксызлык, кешелексезлек. Нәрсә рөхсәт

ителә, ә нәрсә тыела — моның чиге кайда соң? Җавап бик гади. Үзеңә эшләүләрен теләмәгән нәрсәне башкаларга карата да эшләмә.

Тормышта була торган ике очракны карап үтик. Сез магнитофонны кычкыртып куйдыгыз, яңа музыкаль язмалар тыңлыйсыз, ди. Сезгә шулай ошый. Ләкин моның яңа гына эштән кайткан, яисә, киресенчә, иртәгә иртүк эшкә китәргә тиешле күршеләргә ошамаска мөмкин икәнлеген уйламыйсыз. Аларның кисәтүен урынсыз дип саныйсыз — фатир сезнеке бит. Ә хәзер хәлне үзгәртеп карыйк. Сез иртәгә булачак контроль эшкә әзерләнәсез, үтелгән теманы кабатлыйсыз. Һәм кинәт күршеләрдән көчле музыка тавышы ишетелә башлый, ул сезгә фикер туплаpга комачаулый, игътибарыгызны читкә юнәлтә. Сез борчыласыз. Әмма алар да бит музыканы үз фатирларында тыңлыйлар!

Моннан нинди нәтиҗә чыгарырга була? Әгәр берәүләрнең мәнфәгатьләрен канәгатьләндерүе (ял сәгатьләрен уздыруның бер төреме ул, әллә күңел ачу чарасымы) башкаларга комачаулый, аларның тынычлыкларын боза, уңайсызлыклар, күңелсезлекләр китереп чыгара, зыян, зарар сала икән, мондый гамәлне дөрес, гадел дип исәпләп булмый. Моңа тәртип, куркынычсызлык, җәмгыять иминлеге сагында торучы закон килеп катнаша. Һәм бу дөрес тә.

Техника белән үзара мөнәсәбәтне көйләүче нормалар да шактый. Шуларны бозуның кайберләрен санап үтик: урам хәрәкәте куркынычсызлыгын тәэмин итүче кагыйдәләрне бозу; тимер юлга поезд хәрәкәтенең бозылуын китереп чыгаручы предметлар кую; телефон-автоматларны зарарлау; хәрәкәтне көйләүче техник чараларны явыз ният белән яисә ялгыш эштән чыгару; радиотапшыру җайланмаларыннан законсыз файдалану һәм аларны законсыз ясау; законсыз урман кисү, ау һәм балык тоту белән шөгыльләнү.

Табигый байлыкларга зарар китерә торган гамәлләр өчен штраф салу, законсыз балык тоту яки аучылык белән шөгыльләнү коралларын конфискацияләү, аучылык билетыннан мәхрүм итү кебек административ җәза чаралары каралган.

Тарихи һәм мәдәни һәйкәлләр (җәмгыять һәм дәүләт үсеше белән бәйле корылмалар, истәлекле урыннар һәм предметлар, тарихи, фәнни, әдәби яки башка мәдәни кыйммәткә ия булган матди һәм рухи иҗади әсәрләр) — халкыбызның милли байлыгы. Тарихи һәм культура һәйкәлләрен зарарлаган яки юкка чыгарган өчен, әгәр бу гамәлләргә җинаять җаваплылыгы каралмаган булса, граждан штраф түләү кебек административ җаваплылыкка тартылырга мөмкин.

Административ гаеп өчен җаваплылыкка 16 яшькә җиткән кешеләр тартыла. Әмма, кагыйдә буларак, 16—18 яшьтәгеләргә балигъ булмаганнар эше буенча комиссияләр турындагы положениеләрдә каралган чаралар кулланыла. Бу җәзаның тәрби-

яви йогынтысын күтәрергә мөмкинлек бирә. Шул ук вакытта 16—18 яшьлек үсмерләр кайбер административ хокук бозулар өчен гомуми нигездәге җаваплылыкка да тартылалар (вак хулиганлык; хәрби комиссариатка чакырылганда сәбәпсез бармый калу; махсус хәрби таныклыкларны югалту һәм адрес үзгәртү турында вакытында хәбәр итмәү). 16 яше тулмаган, ә гаепле эш кылган үсмер белән ни эшләргә? Бу очракта аның эшен карау балигъ булмаганнар эше буенча комиссиягә тапшырыла. Мәгълүм ки, җәзасыз калдыру, гаеплеләргә карата тиешле чаралар күрмәү яңа хокук бозу, җинаять кылу куркынычын көчәйтә. Әмма мәҗбүр итү хокук тәртибен саклауның бердәнбер ысулы түгел. Ышандыруның мөмкинлекләре киңрәк. Гражданнарның иң зур күпчелеге юридик нормаларга ирекле төстә буйсына. Хокук бозу очрагында гына дәүләт мәҗбүр итү механизмыннан файдалана. Административ законнарда түбәндәге административ җәзалар каралган:

25 нче схема

Административ җаваплылыкка тарту процедурасы административ хокук бозу турындагы эшне башкару дип атала. Административ җәза закон бозу *булган көннән* ике айдан да соңга калмыйча, әгәр ул озакка сузылган характерда булса, *ачылган көненнән* ике айдан да соңга калмыйча бирелә.

Административ җәзаны башкаручы хакимиятнең законда турыдан-туры күрсәтелгән органнары бирергә хокуклы. Аларга административ комиссияләр һәм балигъ булмаганнар эше буенча комиссияләр; авыл, поселок, район, шәһәр, өлкә һәм край

хакимияте; милиция; төрле күзәтү-контроль органнары (янгын күзәтү, Дәүләт автомобиль инспекциясе органнары, таможня органнары, санитар һәм ветеринар надзор органнары һ. б.) керә. Законда каралган очракларда административ җәза бирү хокукы судьяларга бирелә.

Административ хокук нормалары, кем әйтмешли, безнең аяк-кулларыбызны бәйләп куймыймы соң? Биредә көйләү тәртибе файдаланыла, аны «...дан башка, һәммәсен дә» дигән сүзләр белән аңлатырга мөмкин, ягъни, турыдан-туры тыелган нәрсәләрдән башка, һәммәсен дә эшләргә була. Административ тыюлар дәүләт тарафыннан җәмгыять һәм дәүләт тәртибен, гражданнарның милкен, хокукларын һәм ирекләрен саклау өчен күпме кирәк булса, шул кадәр кертелә. Хәзерге чорда административ хокукның роле гаять зур. Көндәлек тормышта һәм хезмәт эшчәнлегендә кешеләр адым саен идарә итү белән очрашалар. Тормышның чынлыкта идарә итүдән читтә калган бер генә өлкәсе дә юк. Һәрбер кешенең тегеләйме, болаймы аның йогынтысын тоеп яшәвен һич арттырусыз әйтергә мөмкин.

Сораулар һәм биремнәр: 1. Административ хокук нинди мөнәсәбәтләрне җайга сала? 2. Идарә итү нәрсә ул? Мәгариф өлкәсендә ул ничек тормышка ашырыла? Укучыларның белем бирү учреждениеләрендәге хокукларын һәм бурычларын санап чыгыгыз. 3. Административ хокук бозу дип без нәрсәне аңлыйбыз? Нинди билгеләре булганда кылган эш хокук бозу дип исәпләнә? Хәрәкәтсезлек өчен юридик җаваплылыкка тартырга мөмкинме? Ни өчен хокук бозулар төрле төрләргә бүленә? Бу нәрсәдән тора? Хокук бозуның һәркайсы һәм һәрвакыт әхлак нормасын бозу булып исәпләнәме? 4. Гражданнар ничә яшьтән административ җаваплылыкка тартылырга мөмкин? Яшүсмерләрнең 16 яшь тулганчы һәм тулгач кылган гамәлләре өчен кулланыла торган чараларда аерма бармы? 5. Административ хокук бозган өчен җаваплылыкның котылгысызлыгы принцибын сез ничек аңлыйсыз? Ул гаделме? Милиция хезмәткәре хокук бозуны булдырмау өчен нинди мәҗбүр итү чаралары куллана ала? Административ гаеп эш кылган өчен законда нинди җәзалар каралган? 6. Административ җәза бирә ала торган органнарны атагыз. 7. Билгеле бер хокук бозулар өчен административ җаваплылык турында сөйләгез.

21. Гражданлык хокукы. Салымнар

Гражданлык законнары тарафыннан көйләнә торган мөнәсәбәтләр. Җинаятькә каршы көрәш хокукы белән, шөкер, кешеләрнең күбесе очрашмый. Әмма барысы да диярлек аның турында белә: җинаять, җәза, алиби... Гражданлык хокукының нәрсә икәнлеген исә күп кеше күз алдына да китерә алмый. Ә бит аның белән, гражданлык хокукы тарафыннан җайга салынучы гамәлләр аркасында, көн саен гына түгел,

кенэнэ унар мэртэбэ очрашырга туры килэ. Әйтик, яңа дәфтәр сатып алдыгыз, ди, димәк, сату-алу буенча килешү төзедегез; мәктәпкә трамвай белән бардыгыз — пассажирларны йөртү буенча килешү мөнәсәбәтенә кердегез; дустыгыздан магнитофон сатып алу өчен акча алып тордыгыз — бурыч килешүе төзедегез; дустыгызның туган көненә китап бүләк иттегез — бүләк итү килешүе төзедегез һ. б. Барлык бу гамәлләрне кылганда сез билгеле бер кагыйдәләргә буйсынырга тиешсез. Ул кагыйдәләр гражданлык хокукы тарафыннан билгеләнгән.

Гражданлык хокукы конкрет нинди мөнәсәбәтләрне көйли соң? Иң әүвәл, мөлкәт мөнәсәбәтләрен, шуңа бәйле рәвештә мөлкәткә бәйләнмәгән мөнәсәбәтләрне, шулай ук шәхси характердагы, мөлкәткә бәйләнмәгән кайбер башка мөнәсәбәтләрне.

Мөлкәт мөнәсәбәтләре матди байлыклар уңаеннан барлыкка килә. Аларга акча, кыйммәтле кәгазьләр, интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәләре — китаплар, картиналар, фильмнар һ. б. керә.

Мөлкәткә бәйләнмәгән шәхси мөнәсәбәтләр исемгә, фирма исеменә, товар тамгасына, намуска һәм кешелек дәрәҗәсенә, эштәге абруйга, күчеп китү һәм яшәү урынын сайлау хокукын тормышка ашыру, шулай ук гражданга яисә юридик затка тумыштан яки закон буенча бирелә торган башка хокукларны тормышка ашыру уңаеннан барлыкка килә.

26 нчы схема



Бу мөнәсәбәтләр матди байлыклар, әйберләр, кыйммәтле кәгазьләр, интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәләре, матди уңайлыклар тудыру процессы, авторлык һ. б. лар уңаеннан барлыкка килә	Бу мөнәсәбәтләр исемгә, фирма исеменә, товар тамгасына, намуска, кешелек дәрәҗәсенә, эштәге абруйга, ирекле төстә күчеп китү һәм яшәү урынын сайлауга һ. б. булган хокукны тормышка ашыру уңаеннан барлыкка килә

Гражданнарның хокукка ия булуы (правоспособность) һәм хокукый сәләтлелеге (дееспособность) төшенчәсе. Гражданның, шул исәптән гражданлык-хокукый мөнәсәбәтләрдә катнашучы буларак балигъ булмаганнарның да, хокукка ия булуы һәм хокукый сәләтлелеге аның төп сыйфатламасы булып тора.

Гражданның хокукка ия булуы ул туган мизгелдән башлана һәм аның үлеме белән туктала. Үз гамәлләрен аңлый һәм алар белән идарә итә аламы, юкмы икәнлегенә бәйсез рәвештә, барлык гражданнарның да хокукка ия булуы бердәй исәпләнә. Кайбер очракларда әле тумаган бала да хокукка ия була: гаиләгә торак мәйданы бирелгәндә йөкле хатынның туачак баласының да торакка хокукы исәпкә алына. Законда каралган тәртип буенча гына кеше хокуклылыктан мәхрүм ителә ала.

Гражданның хокукый сәләтлелеге — аның үз гамәлләре белән гражданлык хокукына ия булу һәм аны тормышка ашыру, үзенә гражданлык бурычлары алу һәм аларны үтәү сәләте ул.

27 нче схема

Гражданның хокукый сәләтлелеге төрләре

Тулы хокукый сәләтлелек
— балигъ булгач, ягъни 18 яшь тулгач барлыкка килә;
— балигъ булганчы никахка керүчеләр хокукый сәләтлелеккә ирешә

Чикләнгән хокукый сәләтлелек
— спиртлы эчемлекләр һәм наркотик матдәләр белән мавыгучы балигъ булган гражданнарга карата суд тарафыннан билгеләнә

Өлешчә хокукый сәләтлелеккә
— 14 тән 18 яшькәчә балигъ булмаганнар;
— 6 дан 14 яшькәчә балалар ия

Абсолют хокукый сәләтсезлек
(недееспособность)
— психик яктан сәламәтлекләре какшау аркасында үз гамәлләренә бәя бирә яисә алар белән идарә итә алмаучы балигъ булган гражданнарга карата билгеләнә

Хокукый сәләтлелек кеше 18 яшькә җиткәч тулы күләмдә башлана. Законда каралган очракларда, граждан 18 яше тулганчы никахка керсә, шул вакыттан башлап ул тулы хокукый сәләтлелеккә ия була. Балигъ булмаганнарны тулысынча хокукый сәләтле итеп тануны закон башка шартлар белән дә бәйли. Мәсәлән, балигъ булмаган, әмма уналты яше тулган яшүсмер, әгәр ул хезмәт килешүе, контракт буенча эшли яки ата-анасының (балалыкка алучының, попечителенең) ризалыгы белән кәсәбәчелеккә керешә икән, ул тулысынча хокукый сәләтле булып исәпләнә.

Гражданнарның тулы хокукый сәләтлелегеннән тыш, закон өлешчә һәм чикләнгән хокукый сәләтлелекне дә аерып күрсәтә.

14 яшькә җитмәгән балаларның хокукый сәләтлелеге була. Алар вак-төяк көнкүреш килешүләре төзи ала. Закон балага билгеле бер максат яки ирекле куллану өчен законлы вәкил яки өченче зат тарафыннан бирелгән әйберне үзе теләгәнчә файдаланырга рөхсәт итә. Башка килешүләрне кече яшьтәгеләр өчен ата-аналар, балалыкка алучылар яки опекун төзи. Алар кече яшьтәгеләрнең килешүләре һәм алар китергән зыян өчен тулысынча җавап бирәләр.

15 яшьтән 18 яшькәчә балигъ булмаган үсмерләр үзләренең хезмәт хаклары, стипендияләре, башка керемнәре белән мөстәкыйль эш итәргә, әдәбият, фән, сәнгать, уйлап табу яки башка эшчәнлекнең авторлык хокукларыннан файдаланырга, законга туры китереп, кредит учреждениеләренә вкладлар кертергә һәм алар белән эш итәргә, вак-төяк көнкүреш килешүләре төзергә (көнкүреш товарлары сатып алырга һ. б.) хокуклы. Башка килешүләрне алар ата-аналар, балалыкка алучылар, попечительләр ризалыгы белән башкарырга тиешләр.

Уналты яше тулган балигъ булмаган яшүсмерләр кооператив һәм иҗтимагый оешмаларның әгъзалары һәм оештыручылары була ала (әгәр бу аларның Уставларында һәм законнарында каралган булса).

14 яшьтән 18 яшькәчә булган яшүсмерләр мөлкәткә үзләре китергән зыян өчен җавап бирергә тиешләр. Әмма аларның мөлкәте яки хезмәт хаклары булмаса, зыянны ата-аналары яки аларны алыштыручылар каплый.

Җитәрлек нигез булганда, суд аерым кешеләрнең үтенечләре буенча балигъ булмаган яшүсмерләрнең үз хезмәт хакы, стипендиясе яисә башка кереме белән мөстәкыйль эш итүен чикли яки аннан мәхрүм итә ала. Моның нигезе булып үзенең акчасын әрәм-шәрәм итү, эчкечелек һәм башкалар исәпләнергә мөмкин.

Балигъ булган гражданнарның хокукый сәләтлелеге бары тик закон тарафыннан гына чикләнергә мөмкин. Мәсәлән, спиртлы эчемлекләр һәм наркотик матдәләр белән кирәгеннән артык мавыгып, гаиләләрендә авыр матди хәл китереп чыга-

ручы кешеләрнең хокукый сәләтлелеге суд тәртибендә чикләнә. Алар өстеннән попечительлек урнаштырыла.

Психик авыруы аркасында кылган гамәлләренең мәгънәсен аңлый һәм алар белән идарә итә алмый торган граждан суд тарафыннан хокукый сәләтлелеккә ия түгел дип табылырга мөмкин. Аның өстеннән опека урнаштырыла. Хокукый сәләтсез дип табылган граждан исеменнән килешүне опекун төзи.

Милек хокукының эчтәлеге. Гражданлык-хокукый көйләү предметы буларак, әйберләрнең төп сыйфатламасы — кемнеке дер булып исәпләнү, һәм бу — милеккә хокук дип атала. Милек хокукының эчтәлеге булып өч хокук суммасы исәпләнә: билгеле бер әйбергә ия булу, файдалану, аның белән эш итү хокукы.

28 нче схема

Милек хокукының эчтәлеге

Мөлкәткә ия булу	Мөлкәттән файдалану	Мөлкәт белән эш итү
Мөлкәткә фактик ия булу, ягъни аннан реаль файдалану, шулай ук аны үзендә калдыру, саклау, урынын алыштыру мөмкинлеге	Мөлкәттән ихтыяҗларны канәгатьләндерү өчен файдалану, керем алу	Мөлкәтнең юридик (бүләк итү, сату, залог һ. б.) һәм фактик (юкка чыгару, куллану һ. б.) язмышын билгеләү

Ия булу — әйберне биләү, кулда тотуны аңлата. Әйбергә аның хуҗасы (милекче), арендатор, саклаучы, комиссионер, подрядчы ия булырга мөмкин.

Файдалану — әйберне үз ихтыяҗларыңны канәгатьләндерү максатында куллану.

Эш итү — әйбернең юридик һәм фактик язмышын билгеләү. Әйбернең фактик язмышын билгеләү аннан алга таба файдалану яки аны юкка чыгару турындагы карарны аңлата. Әйбернең юридик язмышын билгеләү аны сату, бүләк итү, арендага бирү белән бәйле. Әйбер белән аның хуҗасы гына эш итә ала, әгәр хуҗа башка кешеләргә дә әлеге әйбергә булган хокукны биргән икән, алар да аңа ия булырга һәм аннан файдаланырга мөмкин.

Ә милек нинди була? Россия Федерациясендә хосусый, күмәк, дәүләт, муниципаль һәм җәмәгать оешмалары милке бар дип исәпләнә.

29 нчы схема

Россия Федерациясендә милек формалары

Дәүләт милке

— Россия Федерациясе хокукындагы милек (Федератив милек);
— Россия Федерациясе субъектлары: республикалар, крайлар, өлкәләр, федераль әһәмияткә ия булган шәһәрләр, автономияле өлкә, автономияле округлар хокукындагы милек (Россия Федерациясе субъектлары милке)

Хосусый милек

— физик затлар (граждан-нар) милке;
— юридик затлар, шул исәптән сәүдә һәм сәүдәнеке булмаган, иҗтимагый һәм дини оешмалар, хәйрия һәм башка фондлар милке

Муниципаль милек

— шәһәр һәм авыл җирләре, шулай ук башка муниципаль оешмалар хокукындагы милек

Башка формалар

— шәхси милек;
— чит ил дәүләтләре милке;
— милекнең башка формалары

Гамәлдәге закон буенча милеккә хокук:
— үзең өчен яңа әйбер җитештерү яки төзү;
— иске милектән файдаланып, керем, продукция алу;
— сату-алу, алыштыру, бүләк итү, үз файдаңа милекне аерып алу буенча башка килешүләр башкару;
— мирас итеп алу;
— хокуклы варис булу;
— торак, торак төзелеше, дача, гараж һ. б. кооперативларда әгъза булып тору һәм тиешле милек өчен пай түләү;
— табылдыклар;
— хәзинә табу;
— караучысыз хайваннарны тәрбияләү нәтиҗәсендә барлыкка килергә мөмкин.

Санап үтелгән һәр очракта милеккә хокук бары тик закон билгеләгән тәртиптә барлыкка килә һәм туктатыла.

Милеккә бер яисә берничә кеше хуҗа була ала. Закон, өлешне билгеләп һәм билгеләмичә, барлыкка килә торган уртак милек төшенчәсен һәм аның нигезен аныклый. Максатын үзгәртмичә яки закон көченнән тыш бүленә алмый торган милек ике яисә берничә кешенеке булып исәпләнә, уртак милек барлыкка килә.

Закон милек иясенең хокукларын яклау буенча төрле чаралар билгели: мәсәлән, ул милеккә законсыз ия булган хуҗа-

дан үзенең милкен таләп итәргә, милкеннән файдаланганда һәр төрле тоткарлыкларны бетерүне таләп итәргә хокуклы. Милеккә хокукны яклау гомуми, арбитраж һәм третейский судлар тарафыннан тормышка ашырыла.

Килешү (сделка) төшенчәсе. Кеше үзенең милеккә булган ихтыяҗларын килешүләр төзеп һәм йөкләмәләр алып канәгатьләндерә ала. Көндәлек тормышта бу төшенчә гадәттә начар мәгънәдә кулланыла. Ә гражданлык хокукында ул бөтенләй икенче мәгънә ала. *Килешү* — гражданлык хокукларын һәм бурычларын билгеләү, үзгәртү яки туктатуга юнәлдерелгән ирекле гамәл. Килешү сүзенә аңлатма биргәндә тагын бер нәрсәне белергә кирәк: кешенең теләге әйләнә-тирәдәгеләр өчен ачык аңлашылырга тиеш. Ул килешү нәтиҗәсендә үз ихтыяҗларын канәгатьләндерү максатын күздә тота. Килешү закон кысаларында тормышка ашырылырга тиеш, шуңа күрә ришвәтчелек, алдашу, куркыту, ирекле һәм максатчан гамәлләр булса да, килешү булып исәпләнмиләр.

Килешү телдән һәм язма формада булырга мөмкин. Ул «дәшмәү — ризалык билгесе» принцибы буенча да, һәр ике як өчен аңлаешлы гамәл формасында да (конклюдентлы) башкарылырга мөмкин. Мәсәлән, уен автоматына акча төшергәндә сез килешү төзисез — әлеге автоматта уйнау хокукын сатып аласыз. Килешүнең язма формасы якларның үзара хокуклары һәм бурычлары тәгъбир ителгән документлар төзүне күздә тота.

30 нчы схема

Килешү нигезендә гражданнар үз өсләренә йөкләмә алалар. Йөкләмә буенча бер кеше (бурычлы) башка кеше (кредитор) файдасына билгеле бер гамәл кылырга тиеш, ә кредитор бурычлы кешедән үз бурычларын үтәүне таләп итәргә хаклы. Мәсәлән, сату-алу килешүе буенча сатучы мөлкәтне сатып алучыныкы итәргә, ә сатып алучы мөлкәтне кабул итәргә һәм аның өчен кирәкле сумманы түләргә тиеш. Йөкләмә түбәндәге эшләрне башкаруга кайтып кала: әйберне бирергә, билгеле бер суммадагы акчаны түләргә һ. б.

Гражданлык хокукын бозу. Килешү буенча яклар үзләренең йөкләмәләрен гадәттә ирекле рәвештә һәм тиешле срокта

үтиләр. Әмма бурычлы кеше килешүне бозса, закон аны җавапка тарта. Закон тарафыннан каралган яки килешү буенча законга каршы килми торган йөкләмәләрне үтәмәү (бозу) гражданлык хокукын бозу дип атала.

Салым хокукы төшенчәсе. Салым дәүләт кеременең төп чыганагы булып тора. Ул — дәүләт бюджетына физик һәм юридик затлардан алына торган закон белән билгеләнгән мәҗбүри түләүләр.

Салым билгеләү һәм түләү уңаеннан барлыкка килә торган иҗтимагый мөнәсәбәтләр салым хокукы нормалары тарафыннан көйләнә. Закон түләүчеләр даирәсен; салым салу объектын (ягъни салым нәрсәгә салына, шуны — табышны, мөлкәтне, төрле эшчәнлек төрен һ. б.); салым салу берәмлеген (1 $м^2$ мәйдан, 1 га сөрүлек җире һ. б.); салым ставкасын (процент, ныклы суммада акча); ел дәвамында салым түләү срокларын; ташламаларны; салым түләү ысулларын һәм тәртибен билгели.

Федераль салымнар, федерация субъектлары салымнары, җирле салымнар һәм җыемнар була.

Базар мөнәсәбәтләре үсешенә бәйле рәвештә салым законнары да үзгәрде. Салымнарны хәзер күпсанлы эшмәкәрләр түли. Нык үскән илләрдә салым түләү бурычы түләүчеләрнең шул кадәр каннарына сеңгән ки, түләмәве фаш булу эшмәкәрнең булдыксызлыгы, намуссызлыгы дип кабул ителә, һәм шуның белән карьерасы да җимерелергә мөмкин. Кызганычка каршы, безнең эшмәкәрләр салым түләү бурычын андый дәрәҗәдә аңламыйлар әле. Салым кермәгәч, хезмәт хакын бюджеттан алучыларга түләүдә дә тоткарлыклар килеп чыга.

Салым хокукында салым салу өлкәсендәге законлылыкны тәэмин итүне контрольдә тоту мәсьәләләренә аерым урын бирелә. Россия Федерациясендә махсус дәүләт органнары — Дәүләт салым хезмәте, Федераль казначейлык һәм Салым полициясенең федераль органнары аша мәҗбүри салым түләтү функциясе тормышка ашырыла. Салым хокукын бозуның төреннән һәм характерыннан чыгып, административ, дисциплинар, гражданлык һәм җинаять җаваплылыгы каралган.

Сораулар һәм биремнәр: 1. Гражданлык хокукы нинди мөнәсәбәтләрне җайга сала? **2.** Хокукка ия булу нәрсә ул? Гражданнарның тулы, өлешчә һәм чикләнгән хокукый сәләтлелеге дип, без нәрсәне аңлыйбыз? Тулы хокукый сәләтлелеккә ничә яшьтә ия булалар? Балигъ булмаган яшүсмернең тулы хокукый сәләтлелеккә ия булу очракларын санагыз. **3.** Милек хокукының эчтәлеге булып нәрсә тора? Нинди дә булса мөлкәткә ия булу, файдалану һәм аның белән эш итүне ничек аңларга кирәк? Россия законнарында милекнең нинди формалары каралган? Мөлкәткә хокукка ничек ия булырга мөмкин һәм аны югалту нәрсә белән бәйләнгән? **4.** Килешү төшенчәсен аңлатыгыз. Килешүнең нинди билгеләре барлыгын санагыз һәм ачыклагыз. Килешү нинди формаларда башкарыла? Конклюдентлы килешү нәрсә ул? **5.** Йөкләмәләрдә

яклар ничек атала? Якларның йөкләмәләрне үтәмәве нинди нәтиҗәләргә китерә? Гражданлык хокукын бозу төшенчәсен аңлатыгыз. 6. Салымнар нәрсә ул? Алар дәүләткә ни өчен кирәк? Нинди салымнар була?

22. Торак хокукы

Торак законнарының чыганаклары. Татарстан Республикасында торак мөнәсәбәтләрен җайга салучы хокукый актлар булып Россия Федерациясенең Торак кодексы (1983 елның 24 июнендә расланган, 1984 елның 1 гыйнварында гамәлгә кертелгән), Татарстан Республикасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу һәм торак мәйданы белән тәэмин итү кагыйдәләре (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты һәм профсоюзларның Татарстан Республикасы Советының 1992 елның 24 гыйнвар карары белән расланган, 1992 елның 1 февралендә гамәлгә кертелгән) исәпләнә.

* * *

Торак законы — торакка мохтаҗ гражданнарның исәбен алу тәртибен, шулай ук торак мәйданын бүлү тәртибен һәм шартларын көйләүче хокук нормалары җыелмасы.

Торак төзелеше кызу темплар белән барса да, торак җитешми. Шуңа күрә торак алу өчен чират тәртибе кертелгән. Аның буенча учетка кемнәрнең куелуын карап үтик.

Торак бина алу учетына билгеле бер торак пунктта даими яшәүче (әгәр гамәлдәге закон тарафыннан башкасы каралмаган булса) һәм торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ булган гражданнар теркәлә. Торак бина гражданнарга чикләнмәгән срокка, кагыйдә буларак, бер гаиләгә аерым фатир итеп бирелә. Гаилә әгъзаларына ир белән хатын, аларның балалары һәм ата-аналары керә. Башка туганнар, хезмәткә яраксыз булып тәрбиядә торучылар, аерым очракларда башка кешеләр дә, әгәр алар торакка чиратта торучылар белән бергә яшиләр һәм алар белән бер хуҗалык алып баралар икән, гаилә әгъзалары булып исәпләнергә мөмкин.

Торак нормалары. Торак бина җитешмәү барлык мохтаҗ гражданнарны да торак мәйданы белән дөрес тәэмин итү, буш торак йортларны дөрес һәм тигез бүлү, шулай ук алардан рациональ файдалану өчен аерым бер нормаларны закон белән билгеләү зарурлыгын китереп чыгара. Торак мәйданына норма билгеләү гражданнарның торакка хокукларын гарантияләүне сизелерлек ныгыта. Нормалар төрлечә була һәм билгеле бер максатка юнәлдерелә.

Минималь учет нормасы — ул гаиләнең бер әгъзасын торак мәйданы белән минималь тәэмин итү дәрәҗәсе, аның ярдәмендә торакка мохтаҗлык критерие билгеләнә. Бу нормалар җитешмәсә, гражданнар үзләрен торак шартларын ях-

шыртырга мохтаҗ кешеләр буларак учетка бастыруларын таләп итә алалар. Бу критерий аеруча авыр торак шартларында яшәүче гаиләләрне ачыкларга һәм аларны беренче нәүбәттә торак белән тәэмин итәргә мөмкинлек бирә.

Татарстан Республикасында учет нормасы 7 квадрат метр исәпләнә. Торак төзелеше үсешенә, торак фонды артуга карап, учет нормасы да үсәчәк, үзләренең торак шартларын яхшырту мөмкинлеге алган кешеләр даирәсе дә киңәячәк.

Торак мәйдан белән уртача тәэмин итү нормасы (торак бирү нормасы) — бүлеп бирелә торган торак мәйданының минималь күләме; торак алганда гаиләнең һәр әгъзасына аннан да кимрәк күләмдәге торак бирелми. Татарстан Республикасында торак мәйданы белән уртача тәэмин ителеш нормасы 9 квадрат метрга тигез.

Максималь норма — торак алганда бер кешегә бирелә торган торак мәйданының иң зур күләме, ягъни санитария-гигиена таләпләре буенча нормаль тормыш эшчәнлеген тәэмин итеп була торган иң уңайлы торак урыны. Бүгенге көндә ул 12 квадрат метрга тигез.

Гражданнарны торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ дип тану дәүләт һәм җәмәгать фонды йортларында һәм торак-төзелеш кооперативларында яшәүчеләр өчен бер төрле.

Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ дип түбәндәге гражданнар исәпләнә:

а) даими яшәү өчен яраклы торак мәйданы гаиләнең бер әгъзасына 7 квадрат метрдан кимрәк булганда;

б) күләме нинди булуга карамастан, тиешле санитария һәм техник таләпләргә җавап бирми торган йортларда яшәүчеләр;

в) дәүләт һәм җәмәгать фонды йортларының бер бүлмәсендә яшәүче (ир белән хатынны исәпләмәгәндә) 9 яшьтән өлкән булган төрле җенес кешеләре;

г) эш урынына караган торак бинасында яшәүчеләр;

д) бер фатирда яшәүче берничә гаилә әгъзалары, әгәр берәр гаилә составында кайбер хроник авыруларның авыр формасыннан интегүче авырулар булса;

е) бер-берсе аша йөри торган бүлмәләрдә яшәүче, туганлык мөнәсәбәтендә тормаган бер яисә берничә гаилә;

ж) вакытлы яки сезонлы хезмәткәрләрдән, билгеле бер срокка хезмәт килешүе буенча эшләүчеләрдән, шулай ук уку белән бәйле рәвештә яшәүче гражданнардан тыш, тулай торакта яшәүчеләр;

з) башка торак мәйданы булмаганга, чит кеше фатирында яшәүчеләр.

Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу тәртибе. Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу һәм торак мәйдан белән тәэмин итү өчен мәҗбүри шарт булып аларның билгеле бер торак пунктта даими яшәве исәпләнә.

Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу, кагыйдә буларак, тору урыны буенча халык депутатлары җирле Советының башкару-оештыру органында эшләнә. Торак фонды булган һәм торак төзелеше алып барган яки торак төзелешендә өлешле катнашкан предприятиеләрдә, учреждениеләрдә, оешмаларда эшләүче гражданнарны исәпкә алу эш урыны буенча, аларның теләкләре белән шулай ук тору урыннары буенча да башкарыла.

Исәпкә алынган гражданнарга, аларны исәпкә алу вакытыннан чыгып, торак алу өчен чират билгеләнә.

Гражданнар, әгәр уңайлы торак йорт белән тәэмин ителсәләр; даими яшәү өчен башка урынга күчсәләр; чират исемлегенә нигезсез кертелгән булсалар; предприятие, учреждение һәм оешма белән хезмәт килешүен өзсәләр, торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар исәбеннән төшереләләр. Исәптән төшерү гражданнарны исәпкә алган орган карары белән башкарыла.

Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу тәртибен катгый үтәү торакка конституцион хокукны гаделлек белән гамәлгә ашыруның залогы булып тора.

Гражданнарны торак белән тәэмин итүнең чиратлылыгы. Торак проблемасы уңайлы, заманча фатирларны җитәрлек күләмдә булдыру юлы белән генә түгел, торак мәйданын җәмәгатьчелек күзәтүе астында дөрес итеп бүлү юлы белән дә хәл ителә. Чират бу гаять четерекле эштә бозуларга юл куймый торган таләпчән форма, оештыручы булып тора.

Беренче чиратта торак йортлар торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ булган сугыш инвалидларына һәм сугышта катнашучыларга, Совет һәм Россия Армиясе инвалидларына һәм һәлак булган яки хәбәрсез югалган сугышчы (партизан) гаиләләренә, илне саклаганда яки хәрби хезмәтнең башка вазифаларын үтәгәндә алган җәрәхәтләрдән, контузиядән, имгәнүләрдән, шулай ук фронт белән бәйләнешле авырудан үлгән хәрби хезмәткәрләрнең гаиләләренә, Россия Геройларына (шулай ук аларга тиңләштерелгән Советлар Союзы Геройларына, Дан ордены, Хезмәт Даны ордены, СССР Кораллы Көчләрендә хезмәт иткән өчен барлык өч дәрәҗәдәге Дан ордены белән бүләкләнүчеләргә; кайбер хроник авыруларның авыр формасыннан интегүчеләргә; 16 яшькә кадәрге СПИД белән авыручы балалары булган гражданнарга; 1 нче һәм 2 нче группа инвалидларга (гариплек законсыз гамәл кылу аркасында булган очраклардан тыш); дәүләт һәм җәмәгать бурычын үтәгәндә, кешене үлемнән коткару, милекне һәм хокук тәртибен саклау өчен гражданлык бурычын үтәгәндә, яисә производстводагы бәхетсезлек аркасында һәлак булган кешеләрнең гаиләләренә; Чернобыль Атом электр станциясендәге авария нәтиҗәсендә нурлану авыруына дучар булган, шулай ук авария аркасында инвалидлык алган кешеләргә; производствода озак еллар на-

муслы хезмәт иткән эшчеләргә; Герой-ана исеменә лаек булган аналарга, күп балалы гаиләләргә (ата-аналары белән яшәүче һәм үз гаиләләрен кормаган өч яисә аннан күбрәк бала булса); ялгыз аналарга; игезәк балалары туган гаиләләргә; гомуми белем, музыка, сәнгать мәктәпләре һәм профессиональ-техник уку йортлары укытучыларына һәм башка категория гражданнарга бирелә.

Чираттан тыш торак янгын яисә башка табигый бәла-каза аркасында тору урыны яшәү өчен яраксыз хәлгә килгән һәм яңадан торгызу мөмкин булмаган гражданнарга, ятим балаларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган (шулай ук опека астында яшәгән) балаларга, балалар учреждениеләрендә тәрбияләнгәннән соң яисә урта профессиональ-техник училище, югары һәм урта махсус уку йорты тәмамлаганнан соң, яисә Кораллы Көчләрдә хезмәт срогы үтәгәннән соң бирелә; аспирантура, клиник ординатура, югары, урта махсус, профессиональ-техник һ. б. уку йортларын тәмамлаганнан соң эшкә билгеләнү тәртибендә башка урынга җибәрелгән кешеләргә һәм аларның гаилә әгъзаларына предприятие, учреждение, оешма тарафыннан бирелә.

Эш урынында исәптә торган гражданнарның торак алу чираты хезмәт дисциплинасын явыз ният белән бозган, эчкечелек, хулиганлык белән шөгыльләнгән, чит кеше милкен урлаган һ. б. очракларда соңрак срокка күчерелергә мөмкин.

Торак белән тәэмин итү тәртибе. Гражданнарга яшәү өчен бирелә торган торак бина уңайлы, санитария һәм техник таләпләргә җавап бирә торган булырга тиеш. Гражданнарга торак мәйдан, куелган норма буенча, бер кешегә 9 кв. метрдан да ким булмаган күләмдә бирелә.

Гражданнарның торак мәйданын билгеле бер районда, йортта, катта бирүне таләп итүләре канәгатьләндерелми. Торак бина гражданнарның сәламәтлеген һ. б. игътибарга лаек нәрсәләрне исәпкә алып бирелә.

Торак бина бирелгәндә бер бүлмәгә, ир белән хатынны исәпләмәгәндә, тугыз яшьтән өлкән булган төрле җенес кешеләрен кертү рөхсәт ителми.

Торак алганда гражданнар, яңа торакка ордер алганнан соң, озакка сузмыйча, элек торган торак мәйданын бушатырга, аны төзек санитар-техник хәлдә тапшырырга тиешләр. Бинаны төзек хәлгә китерү, башкарылмаган чираттагы ремонт эшләре өчен аннан элек файдаланган граждан түли.

Торак бирелү турындагы карар нигезендә гражданга ордер бирелә, һәм ул торак мәйданга күчү өчен бердәнбер нигез булып тора. Ордер алган граждан ун көн эчендә ордерга кертелгән барлык гаилә әгъзалары белән бергә үзенә бирелгән торак бинага күченеп бетәргә тиеш.

Торакны хосусыйлаштыру. Торакны хосусыйлаштыру безнең республикада Татарстан Республикасының «Татарстан

Республикасында торак фондын хосусыйлаштыру турында»гы законы, Татарстан Республикасында Дәүләт торак фондын хосусыйлаштыру тәртибе һәм шартлары турында Татарстан Республикасында дәүләт милке белән идарә итү буенча Дәүләт Комитеты тарафыннан расланган положение, шулай ук Татарстан Республикасында торак фондын хосусыйлаштыру тәртибе турында шулар нигезендә эшләнгән инструкция буенча тормышка ашырыла.

Дәүләт (коммуналь) торак фонды йортларында урнашкан торакларны хосусыйлаштырырга мөмкин. Тузган торак йортлардагы, тулай тораклардагы, махсуслаштырылган йортлардагы, ябык хәрби шәһәрчекләрдәге, хезмәткәрләр өчен билгеләнгән йортлардагы торак биналар хосусыйлаштырылмый.

Торак биналарны анда даими теркәлгән барлык гражданнар, шул исәптән, үзләре анда яшәмәсәләр дә, торак йортка хокуклары булган гражданнар хосусыйлаштыра ала.

Балигъ булмаганнарның торакка хокуклары. Баланың торакка хокукы ул туганчы ук закон тарафыннан саклана. Мәсәлән, гаиләгә торак бина бирелгән вакытта аның күләме гаиләдә йөкле хатын булуын исәпкә алып билгеләнә. Балаларның торакка хокукларын саклау йөзеннән «Герой-ана» исеме бирелгән хатын-кызларга, күп балалы аналарга, гарип балаларны тәрбияләүче гаиләләргә, ялгыз аналарга, игезәк балалары туган гаиләләргә торак бирү буенча ташламалар каралган.

Түләүсез торак алу хокукына гражданнар мөстәкыйль рәвештә бары тик унсигез яшьләре тулгач, ә никахка кергән балигъ булмаганнар никахлары теркәлү моментыннан ирешәләр. Алар аны сатып ала, арендага ала, төзи ала. Шулай итеп, һәрбер очракта да торак алу хокукы гражданнарның тулы хокукый сәләтлелеген күздә тота.

Гаилә фатир алган вакытта торак мәйданының балигъ булмаганнар өлешен аларның ата-аналары яисә аларны алыштыручылар ала. Торак бинаны файдалануга алучы булып гаиләнең өлкән әгъзаларының берсе исәпләнә, ләкин балигъ булмаганнар торактан алар белән бертигез хокукта файдалана.

Ата-аналарын югалткан, тулы хокукый сәләтлелек статусына ия булмаган 15 яшьтән 18 яшькә кадәрге үсмерләр торак бинаны попечительнең ризалыгы белән генә файдалануга ала алалар. Унбиш яше тулмаган үсмерләр мондый хокукка ия түгел.

Фатирны хосусыйлаштырган очракта йорт хуҗасы гаиләсенең балигъ булмаган әгъзалары фатирдан файдалану хокукын югалтмыйлар һәм торак бинага булган хокукларын теләсә кемнең, шул исәптән йорт хуҗасының да бозуын туктатуны таләп итә алалар. Йорт хуҗасы гаиләсенең балигъ булмаган әгъзалары яшәгән торак бинаны алу (сату, бүләк итү) опека һәм попечительлек вазифасын башкаручы орган ризалыгы белән генә рөхсәт ителә.

Балалар учреждениеләренә, туганнары яисә опекуннары янына урнашулары сәбәпле даими яшәү урыннарында булмаган балаларда торактан файдалану хокукы саклана. Бу торак аренда килешүе буенча алар балалар учреждениеләрендә яшәүләрен, техникумнарда һәм вузларда укуларын, илнең Кораллы Көчләрендә хезмәт итүләрен тәгәлләгәнче яки балигъ булу яшенә җиткәнче башка кешеләргә бирелергә мөмкин.

Балигъ булмаганнарның торакка хокукы закон тарафыннан башка юллар белән дә саклана. Мәсәлән, ата-ана хокукыннан мәхрүм ителгән кешеләр, әгәр аларның балалары белән бергә яшәүләре мөмкин түгел дип табылса, башка торак мәйданы бирелмичә, әлеге фатирдан чыгарылырга мөмкин.

Сораулар һәм биремнәр: 1. Торак алу өчен чират ни өчен кирәк? Торак законнарында нинди нормалар бар? 2. Гражданны торакка мохтаҗ дип санауның нигезләре нинди? Андый гражданнарны исәпкә алу тәртибе нинди? 3. Торак бина нинди тәртиптә бирелә? Нәрсә ул ордер? 4. Торак ничек хосусыйлаштырыла? 5. Кайсы очракларда балигъ булмаганнар торак алу өчен мөстәкыйль хокукка ия булалар? Балигъ булмаганнарның торакка хокуклары ничек саклана?

23. Җир хокукы

Җир хокукының чыганаклары. Җир мөнәсәбәтләре Россия Федерациясенең Җир кодексы, РФ Президентының 1993 елның 24 декабрендә чыккан «РФнең Җир турындагы законнарын РФ Конституциясенә туры китерү турында» Указы белән көйләнә (ул Җир кодексының 127 статьясыннан 63 ен юкка чыгара). Җиргә милек хокукы Россия Федерациясенең Граждание кодексы белән көйләнә. Татарстан Республикасында үз Җир кодексы проекты эшләнгән.

Җир — хокук көйләве объекты. «Җир» сүзе нәрсәне аңлата? Аның мәгънәсе күп төрле. Киң мәгънәдә без аны планета буларак, бар булган нәрсәләре белән бергә кабул итәбез. Тар мәгънәдә ул өстәге туфрак катламын аңлата. Безнең өчен җирнең менә шушы соңгы мәгънәсе әһәмиятле, нәкъ менә ул җир мөнәсәбәтләре объекты булып тора. Җир хокукы — хокукның җирдән рациональ файдалануны һәм аны саклауны, җир мөнәсәбәтләрен, җирдә хуҗалык алып баруның төрле формаларын үстерүне, туфракның уңдырышлылыгын арттыруны, табигый мохитне саклау һәм яхшыртуны, гражданнарның, предприятиеләрнең һәм учреждениеләрнең хокукларын саклауны тәэмин итүче тармагы.

Җир табигатьнең башка компонентлары арасында төп урынны били, ул аның территориясендә яшәүче халыкларның тормышы һәм эшчәнлеге нигезен тәшкил итә. Җир — катлаулы биологик организм. Җирнең билгеле бер өлеше авыл хуҗалыгы, җиләк-җимеш, урман культураларын үстерү өчен

җитештерү чарасы булырга мөмкин. Җирнең өске өлешендә кыргый үсемлекләр үсә. Хайваннар дөньясы да бай. Сулыкларда су фаунасы яши. Җир астында файдалы казылмалар, җир асты сулары һ. б. бар. Җир — административ-территориаль берләшмәләр, торак пунктлар, предприятиеләр һәм производство чаралары урнашкан урын. Кыскача әйткәндә, кеше тормышы өчен җирнең әһәмияте гаять зур. Дәүләтне махсус кагыйдәләр һәм тыюларның тоташ бер системасын кертергә мәҗбүр итүче җир мөнәсәбәтләренең үзенчәлеге шуның белән билгеләнә. Дәүләт яки җәмгыять ихтыяҗлары таләп итә икән, җир участогы теләсә кайсы файдаланучыдан мәҗбүри тартып алынырга яки теләсә кайсы милекчедән мәҗбүри сатып алынырга мөмкин. Дәүләтнең җирдән аның начараюына китерә торган ысуллар белән файдаланучы кешеләр эшчәнлегенә катнашырга хакы бар.

Җир чиксез түгел, ул пространствода чикләнгән объект булып тора. Россиянең Җир мәйданы 17 млн. квадрат километр тәшкил итә. Беренче карашка бу күп шикелле тоела, ләкин аннан акылсыз файдалансак, без аның байлыгын — уңдырышлылыгын югалтырга мөмкин. Җирдән рациональ файдаланырга кирәк. Закон аннан бары тик максатчан файдалануны таләп итә. Мәсәлән, авыл хуҗалыгы культураларын үстерү өчен билгеләнгән җирдә биналар, корылмалар төзергә ярамый. Дәүләт җирдән файдаланучыга участокны тартып алуга кадәр барып җитә торган санкцияләр кулланырга хокуклы.

Махсус җир үлчәү кораллары булган белгечләр генә җир участокларын файдалануга бүлеп бирә ала, һәм җир төзү эшләре вәкаләтле оешмалар тарафыннан гына башкарыла.

Җирләр бер төрле генә түгел, бу исә төрле җир мөнәсәбәтләрен китереп чыгара. Аларны хәл итү өчен җир хокукында җирләрнең хокукый режим төшенчәсе билгеләнә, һәм бу җир хокукының асылын тәшкил итә.

Җирләрнең хокукый режимы. Барлык җир фонды законда иң әүвәл җир категорияләре буенча бүленә, аның критерие булып җирнең нинди максатта файдаланылуы хезмәт итә: авыл хуҗалыгы җирләре, торак пунктларның җирләре, махсус билгеләнгән җирләр (промышленность, транспорт өчен һ. б.). Хокукый режим җирләрнең билгеле бер категорияләрен дәүләт дәрәҗәсендә җайга салу үзенчәлекләрен үз эченә ала.

Җирдән максатчан файдалануны бозу — Җир законнарын тупас бозу ул. Моның нәтиҗәсендә җиргә милек хокукы, аннан файдалану, арендага алу хокукы тулысынча яисә өлешчә туктатылырга мөмкин.

Җир участокларын максатчан файдаланудан чыгып (аларны җирнең теге яки бу категориясенә кертүдән яки теге яисә бу төр авыл хуҗалыгы җире дип билгеләүдән чыгып), җирләрне җирнең тиешле хокукый мөнәсәбәтләре субъектларына

бирү мөмкинлеге дә билгеләнә. Мәсәлән, крестьян (фермер) хуҗалыгы өчен җирләр 18 яшькә җиткән, авыл хуҗалыгы эшендә тәҗрибәсе булган яки махсус хәзерлек үткән кешеләргә бирелергә мөмкин.

Җирдән максатчан файдалану җирне үзенең хокукы һәм хокукый сәләтлелеге буенча әлеге максатны үти алмый торган субъектка бирүгә юл куймый. Мәсәлән, тыюлык җирләр чуен кою максатын күздә тоткан һәм башка устав бурычлары булмаган промышленность предприятиесенә бирелә алмый.

Хокуклылыкның махсус даирәсе җир участогының үзенчәлекләре; җирдә эшләүче субъектның хокукый статусы; регионнардагы шартлар белән билгеләнә. Мәсәлән, елгалар һәм сулыкларның су саклау зоналарында; табигатьне саклау урыннарында; тыюлыкларда; табигый паркларда; табигать һәйкәлләре зоналарында һәм башка шундый урыннарда җирдән файдалануның махсус режимы урнаштырыла. Әйтик, теге яки бу регионда гадәттән тыш экологик ситуация зонасы РФ Президенты Указы белән (вәкаләтле органнарның соравы буенча) игълан ителә, һәм бу зонада җирдән файдалануның билгеле бер чикләүләре кертелергә мөмкин.

Җир турындагы законнарны бозган өчен җаваплылык. Хокукның иң мөһим һәм төп вазифасы — җир хокукы мөнәсәбәтләре субъектларын җаваплылык йөкли торган билгеле бер тәртип кысаларында тоту. Җирләрнең режимын хокукый тәэмин итү механизмын билгеле бер җаваплылык чаралары билгели, алар хокук бозучы өчен җәза яки күңелсез нәтиҗә булырга мөмкин. РФ Җир кодексының 126 статьясы буенча, предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар һәм гражданнар җир законнары бозылу аркасында килгән зыянны тулысынча капларга тиешләр.

Җир — илнең төп байлыгы. Аны үзең өчен генә түгел, киләсе буыннар өчен дә саклау, рациональ файдалану, шулай ук гражданнарның, предприятиеләрнең, учреждениеләрнең һәм оешмаларның хокукларын саклау, җирдә хуҗалык итүнең төрле формаларын үстерү, туфракның уңдырышлылыгын арттыру, табигый мохитне саклау һәм яхшырту өчен тиешле шартлар тудыру — җир хокукының бурычы.

Сораулар һәм биремнәр: 1. Хокукый көйләү объекты буларак җирнең нинди сыйфатлары бар? **2.** Җир хокукы предметына нинди иҗтимагый мөнәсәбәтләр керә? **3.** Җирдән файдалануның «хокукый режим» төшенчәсе нәрсәдән тора һәм аның состав элементлары нинди?

24. Табигатьне саклау

Табигатьтәге һәммә нәрсә күзгә күренми торган экологик бәйләнешләрдән тора. Табигать объектларының теләсә кайсына тәэсир итү һичшиксез башка объектта, хәтта объектларда

чагылачак. Кеше эшчәнлеге турыдан-туры яисә читләтеп әйләнә-тирә мохиткә йогынты ясый. Һәм, әгәр бу эшчәнлек уйланып бетмәсә, йогынты зарарлы булачак. Мәсәлән, сулыклар янындагы урманнарны кисү аларның саегуына китерә; сазлыкларны киптерү (тулаем алганда, әһәмиятле эшчәнлек) күршедәге җирләрнең туфрактагы дым режимын боза һәм туфрак фаунасының кайбер төрләренең һәлак булуына китерә. Кыскасы, табигый бәйләнешләр белән бәйле һәрбер гамәл алар өчен зарарсыз булырга тиеш.

Күпчелек илләр, шул исәптән Россия дә, катлаулы экологик халәттә яши. Россиядәге 50 дән артык шәһәр гражданнарның тормышы һәм сәламәтлеге өчен куркыныч дәрәҗәдә пычрак; агып төшә торган файдаланылган суларның 80 проценты диярлек чистартылмый; Россия территориясендәге елгалар фенол һәм нефть продуктлары белән пычранган; ярты гасыр эчендә авыл хуҗалыгы әйләнешеннән миллион гектардан артык сөрүлек җирләр төшеп калды. Мондый халәт экологик кризис чигенә җиткәнне күрсәтә. Экокризис, аерым бер ситуация буларак, безне чолгап алган яшәү мохитен саклау проблемаларын махсус норматив-хокукый көйләү ихтыяҗын китереп чыгара. Бу проблемаларны экология өйрәнә.

Экология — ул тере организмнарның әйләнә-тирә мохит белән үзара мөнәсәбәтләре турындагы фән. Баштарак экология биологларның өйрәнү предметы иде, әмма бу терминның мәгънәсе акрынлап киңәйде, һәм бүген ул иң әүвәл җәмгыять һәм әйләнә-тирә мохитнең үзара мөнәсәбәтенең социаль аспектларын үз эченә ала. Шуңа күрә әйләнә-тирә мохиткә кире йогынты ясый торган иҗтимагый мөнәсәбәтләрне көйләүче хокук экологик хокук дип атала.

Экологик хокук — Россия хокукының гражданнар һәм оешмалар арасында хәзерге һәм киләчәк буыннар мәнфәгатьләрендә әйләнә-тирә табигый мохитне имин тоту максатында табигый объектларны саклау, яхшырту, кабат торгызу һәм нәтиҗәле файдалану буенча дәүләтнең турыдан-туры катнашуы белән барлыкка килә торган иҗтимагый мөнәсәбәтләрне көйләүгә юнәлдерелгән комплекслы мөстәкыйль тармагы. Сүз кешенең яшәү мохитен төзүче һәм аның тормышы һәм сәламәтлеге өчен тиешле шартлар белән тәэмин итүче объектлар турында бара.

«Экологик хокук» төшенчәсе нинди закон актларын үз эченә ала? Хәзергә ул башка тармаклардагы кебек бер бөтен нәрсә түгел әле. Экологик хокук нормалары хокукның күп кенә чыганакларында, шул исәптән законнарның төрле тармакларына караучы чыганакларда бар.

Иң беренче чиратта бу — РФ Конституциясе. Ул экологик көйләүнең төп принципларын беркетте. Һәркем уңайлы мохиткә, аның торышы турындагы дөрес мәгълүматка һәм үзенең сәламәтлегенә яисә милкенә экологик хокук бозу аркасында

ясалган зыянның каплатылуына хокуклы (42 статья), һәм һәркем табигатьне һәм әйләнә-тирә мохитне сакларга, табигый байлыкларга сак мөнәсәбәттә булырга бурычлы (58 статья). Табигый объектлар билгеле бер территориядә яшәүче халыкның тормышы һәм эшчәнлегенең нигезе буларак файдаланыла һәм саклана (9 статья).

Табигать өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне экологик-хокукый көйләүгә махсус юнәлдерелгән төп норматив-хокукый акт 1991 елның 19 декабрендә чыккан «Әйләнә-тирә табигый мохитне саклау турында» РФ Законы. Аның 94 статьясы бар һәм, аерым объектларны аерып күрсәтмичә, табигатьне саклауның барлык мөнәсәбәтләрен көйләүче комплекслы норматив акт булып тора. Закон — төрле норматив-хокукый актлардагы экологик-хокукый нормаларны беренче тапкыр комплекслы берләштерергә омтылу.

Законның төп идеясе — экологик һәм икътисади мәнфәгатьләрне фәнгә нигезләп берләштерү, һәм ул нормаларның өч төркеме ярдәмендә тормышка ашырыла:

— әйләнә-тирә табигый мохитнең сыйфат нормативларын беркетүче;

— хуҗалык һәм башка эшчәнлеккә экологик таләпләрне беркетүче;

— бу таләпләрне үтәү механизмын билгеләүче.

Башка хокукый актлар арасыннан түбәндәгеләрне аерып күрсәтергә мөмкин.

Россия Федерациясенең Җир кодексы. Кодекста экологик характердагы берничә норматив-хокукый күрсәтмә бар: җир участокларында экологик иминлекне хокукый тәэмин итү; экологик чиста продукция эшләп чыгару бурычы; туфракта зарарлы химик, бактериаль, радиоактив матдәләрнең югары концентрациясен булдырмау.

Россия Федерациясенең Җир асты байлыклары турында законы җир асты байлыкларыннан файдалануның әйләнә-тирә мохиткә кире йогынты тудыручы мөнәсәбәтләрен экологик-хокукый көйләү системасын билгели. Мәсәлән, файдалы казылмалар чыгару чикләрен билгеләгәндә, казылмалардан файдалану белән бәйле эшләрнең тәэсир итү зоналары исәпкә алынырга тиеш. Җир асты казылмаларының аерым участокларыннан файдалану әйләнә-тирә табигый мохитне саклауны тәэмин итү максатында чикләнергә яки тыелырга мөмкин. Җир асты корылмаларын тулысынча яисә өлешчә бетергәндә казылма байлыклар чыгару урыннары һәм бораулау скважиналары халыкның тормышы һәм сәламәтлеге иминлеген, әйләнә-тирә табигый мохитне саклауны тәэмин итәрлек халәткә китерелергә тиеш.

Россия Федерациясенең Урман кодексы түбәндәге чараларны үз эченә ала: урманнарны саклау һәм яклау; биологик төрлелекне саклау; урманнарның теге яки бу төрләрен төр-

кемнәргә һәм категорияләргә аларның табигатьне саклау, экологик һәм социаль функцияләреннән һәм урнашуларыннан чыгып бүлү; урман хуҗалыгы белән урманнарның саклану төркемнәренә һәм категорияләренә бәйле рәвештә идарә итү тәртибен кертү; урман фондыннан файдалануның башка табигый объектларның торышына кире йогынтысын булдырмау яки чикләү бурычларын билгеләү һ. б.

Аңлаешлырак булсын өчен, бер мисал карап үтик. Урман хуҗалыгы буенча чаралар кыргый җәнлекләр яши торган уңайлы мохитне саклау шартларында тормышка ашырыла. Шул ук вакытта урманнан файдаланучыларның мәнфәгатьләре, хуҗалык итү мөстәкыйльлекләре сакланган хәлдә (закон, матди җаваплылык белән куркытып, оешмалар эшчәнлегенә тыкшынуны тыя), җәнлекләр яши торган мохитне саклау мәнфәгатьләре белән гармоник ярашырга тиеш.

Россия Федерациясенең Су кодексында түбәндәге экологик-хокукый нормалар бар: әйләнә-тирә табигый мохитне һәм халыкның сәламәтлеген саклауны тәэмин итү максатында аерым су объектларыннан һәм аларның аерым өлешләреннән файдалануны тыю яки чикләү мөмкинлеге; су объектларының саегуын булдырмау максатында судан файдалануны чикләү; судан файдаланучыларның су һәм су тирәсе флорасы һәм фаунасының начараюын булдырмау бурычы; судан файдалануны лицензияләү һәм су бассейнында экологик һәм санитар шартлар начараю очрагында лицензия шартларын кабат карау мөмкинлеге; гражданнарның һәм юридик затларның йомык сулыклардан түләүле файдалануын һәм ул сулыкларга хосусый милек хокукын билгеләү; судан файдалану хокукына ия булу өчен кайбер килешүләр төзергә рөхсәт итү һ. б.

Хайваннар дөньясы турындагы Федераль Закон табигый мохиттә яшәүче җәнлек төрләрен саклауны күздә тота: хайваннар дөньясының яшәү мохитен, үрчү һәм күчеп йөрү шартларын саклау; хайваннарның тормыш эшчәнлегенең кирәкле үзлекләреннән файдалану мөмкинлеге (закон тарафыннан башкасы каралмаса, аларны табигый мохиттән аермыйча гына файдалану); табигый мохит балансын бозарга мөмкин булганга, хайваннарны яңа климатка күнектерү һәм яңа токым алу өчен рөхсәтсез икенче урыннарга күчерүне тыю һ. б.

Россия Федерациясенең Атмосфера һавасын саклау турындагы законы пычратучы матдәләрнең рөхсәт ителә торган чиген һәм аларның атмосферага физик йогынты ясау дәрәҗәсе нормаларын карауны; атмосферага пычратучы матдәләр чыгаруның рөхсәт ителә торган тәртибен билгеләүне; аз тавышлы технология кертү, юллар һәм аралашу чаралары конструкцияләрен яхшырту исәбенә производстводагы һәм башка шаушуны киметүне; тавыш чыганагы булып торган корылмаларны һәм җиһазларны торак пунктлардан ерак урыннарга урнаштыруны һ. б. күздә тота.

Махсус законнардан тыш, Россиянең гамәлдәге законнары экологик-хокукый нормалар кергән гомуми норматив актларны да үз эченә ала. Әйтик, «Инвестицион эшчәнлек турында»гы һәм «Чит ил инвестицияләре турында»гы законнарда экологик куркыныч тудыручы объектларны инвестицияләүне тыю билгеләнгән h. б.

Кешенең теләсә нинди эшчәнлеге чынлыкта әйләнә-тирә табигый мохиткә йогынты ясаганга күрә, барлык иҗтимагый мөнәсәбәтләрне хокукый көйләү мөмкин кадәр экологияләштерелгән булырга тиеш. Әйтик, әйләнә-тирә мохиткә зарар салырга мөмкин булган теге яки бу объектлар төзелеше алдан экологик тикшерү үткәрелгәннән соң гына проектланырга тиеш; нәрсәне дә булса техник яктан хәл иткәндә, әгәр аны тормышка ашыру экологик яктан куркыныч икән, автор уйлап табучы сыйфатында теркәлә алмый; экологик пычрак продукция бирә һәм экологик кире нәтиҗәләргә китерә торган җитештерү чаралары һәм товарлар промышленностька һәм гражданлык әйләнешенә кертелә алмый.

Экологик кризис — бөтендөнья афәте, аннан дәүләт бернинди «кытай стеналары» ярдәмендә дә котыла алмый, шуңа күрә экологик-хокукый көйләүдә **халыкара-хокукый нормалар өстенлеге** нигез итеп алына.

Экологик хокукны бозган өчен җаваплылык — билгеле бер затның экологик хокукны бозган өчен закон буенча шәхси яки матди характердагы җәза алырга тиешлеге. Бу хокук бозу экологик хата яки экологик җинаять булырга мөмкин. Хата эш өчен урындагы кешеләр яисә гражданнар дисциплинар, административ яисә гражданлык-хокукый җаваплылыкка, җинаять кылган өчен җинаять җаваплылыгына, ә предприятие, учреждение, оешмалар административ һәм гражданлык-хокукый җаваплылыкка тартылырга мөмкин.

Дисциплинар җаваплылыкка хезмәткәрләр хезмәт вазифаларын башкару процессында кылган экологик хокук бозулары өчен тартылырга мөмкин. Биредә аның эш вазифалары даирәсенә керә торган экологик кагыйдәләрне бозган өчен генә кулланылганлыгын истә тотарга кирәк. Экологик хокук бозган өчен дисциплинар җаваплылыкка тарту хокук бозучы эшли торган предприятие яки ул әгъза булып тора торган кооператив администрациясе тарафыннан кулланыла.

Экологик хокук бозулар өчен административ җаваплылык «Әйләнә-тирә табигый мохитне саклау турында»гы РФ Законының 84 статьясында беркетелгән. Гаепле кешеләр штрафка тартыла.

Экологик җинаять кылуда гаепләнүче урындагы кешеләр һәм гражданнар җинаять җаваплылыгына тартыла. Мондый җинаятьләр күп төрле һәм алар РФ Җинаять кодексының 26 бүлегендә каралган. Җинаять җаваплылыгы, мәсәлән, эш башкарганда әйләнә-тирә мохитне саклау кагыйдәләрен бозган

өчен, экологик куркыныч матдәләр һәм калдыклар белән эш итү кагыйдәләрен бозган, суны, атмосфераны, диңгез мохитен пычраткан, җирне бозган, файдалы казылмаларны саклау һәм файдалану кагыйдәләрен үтәмәгән, законсыз төстә су җәнлекләрен һәм үсемлекләрен үзләштергән, балык запасларын саклау кагыйдәләрен бозган, рөхсәтсез ау белән шөгыльләнгән, урманнарны бетергән, зыян салган һ. б. җинаятьләр кылган өчен кулланыла.

Гражданлык-хокукый җаваплылык та бар. «Әйләнә-тирә табигый мохитне саклау турында»гы РФ Законында әйләнә-тирә табигый мохиткә китерелгән зыянны каплау бурычы һәм тәртибе (88 статья), әйләнә-тирә табигый мохиткә начар йогынты ясау аркасында гражданнарның сәламәтлекләренә китерелгән зыянны каплау (89 статья), гражданнарның милкенә китерелгән зыянны каплау (90 статья) турында әйтелә. Предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар һәм гражданнар судка яисә арбитраж судына кешеләрнең сәламәтлегенә һәм милкенә, халык хуҗалыгына һәм әйләнә-тирә табигый мохиткә зыян китерүче экологик зарарлы эшчәнлекне туктату турында дәгъва белдерергә хокуклы (91 статья).

Табигатьне саклау мәсьәләсен хәл итүдә хокук саклау органнары мөһим роль уйный. Мәсәлән, Россиядә табигатьне саклау прокуратуралары төзелгән һәм эшли. Аларның кайберләре билгеле бер территориядә эшли, мәсәлән, Татарстанның табигатьне саклау прокуратурасы бөтен республикада экологик законнарның үтәлешен күзәтә. Икенче берләре билгеле бер экологик объектта законнарның нәтиҗәлерәк үтәлешен тикшерү өчен төзелгән. Әйтик, Тверь шәһәрендәге экологик прокуратура Идел елгасында табигатьне саклау законнарының үтәлешен күзәтә, шуның белән бу бөек елганы аңа төзәтелмәслек зарар китерә торган хокук бозулардан саклый. Бу прокуратураның бер бүлекчәсе безнең республикада да эшли, чөнки Идел аның бөтен территориясе аша үтә. Бу бүлекчә Казан экологик прокуратурасы дип атала. Һәр ике прокуратура үзара бәйләнештә эши.

Эчке эшләр органнары экологик хокук бозуларны кисәтү һәм булдырмау өчен күп эш башкара.

Махсус дәүләт органнары табигатьне саклау кагыйдәләренең үтәлешен тикшерә. Мәсәлән, Дәүләт урман саклау органнары урманнарны саклый, урманнарда янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләренең үтәлешен тикшерә. Шулай ук су ресурсларын, балыкны саклау органнары һ. б. бар. Табигый байлыкларга зыян китергән кешеләргә бу органнар штраф салу, законсыз балык тоту яисә ау белән шөгыльләнү коралларын конфискацияләү, аучы билетыннан мәхрүм итү һ. б. кебек административ җәза бирәләр.

Безнең илдә табигатьне саклау ирекле җәмгыяте әгъзаларының зур армиясе бар. Укучылар бу җәмгыятькә 16 яшьтән

керә ала. Күп кенә укучылар «яшел» һәм «зәңгәр» патрульләр составында тора.

Илебезнең табигый байлыклары күп һәм төрле. Табигатьне саклау һәм аның байлыкларыннан чаманы белеп файдалану — дәүләтнең гаять мөһим бурычы.

Сораулар һәм биремнәр: **1.** Сез әйләнә-тирә табигый мохиткә ничек карыйсыз? Табигать эчендә йөргәндә нинди хисләр кичерәсез? Бу һәр очракта да табигать өчен зарарсыз үтәме? Табигатьне ни өчен аңа карата хөрмәт, сакчыл мөнәсәбәт тәрбияләү белән генә түгел, закон көче белән дә сакларга кирәк? **2.** Экологик хокук нәрсәләрне үз эченә ала? **3.** Кеше белән табигать арасындагы мөнәсәбәтләрне хокукый көйләүче норматив-хокукый актларны атагыз. **4.** Россиядә экологик кризисның асылы нидән гыйбарәт һәм аннан чыгу юллары бармы? **5.** Закон кыргый үсүче чәчәкләрнең, җимешләрнең билгеле бер төрләрен җыюда чикләү урнаштыра, шулай ук балыкны кармак белән тотуның билгеле бер нормаларын билгели. Ни өчен мондый чикләүләр кабул ителгән? **6.** Әгәр җир хосусый милек булып исәпләнсә, бу җирнең саклануына, аның туфрак катламының торышына йогынты ясар идеме? **7.** Экологик хокук бозуларны кисәтү, булдырмау йөзеннән хокук саклау органнары нинди эшләр башкара?

25. Никах, гаилә һәм закон

Гаилә хокукы чыганаклары. Россия Федерациясе Конституциясе буенча гаилә законнары Россия Федерациясе һәм Россия Федерациясе субъекты булган Татарстан Республикасының уртак карамагында исәпләнә.

Гаилә законнары Россия Федерациясенең Дәүләт Думасы тарафыннан 1995 елның 8 декабрендә кабул ителгән Гаилә кодексыннан һәм шуңа туры китереп кабул ителгән башка федераль законнар, шулай ук Россия Федерациясе субъектлары законнарыннан тора. Татарстан Республикасы Законнары гаилә мөнәсәбәтләрен, беренчедән, кодекс буенча Россия Федерациясе субъектларына караган һәм, икенчедән, кодекс тарафыннан турыдан-туры көйләнми торган мәсьәләләр буенча җайга сала.

* * *

Күпчелек кеше өчен иң җылы һәм уңайлы урын — йорт, гаилә. Нык гаилә — җәмгыятьнең һәм дәүләтнең нигезе. Гаиләдә балалар тәрбияләнә. Француз әдибе Сент-Экзюпери: «Тумышым белән мин балачактан», — дип юкка гына язмаган. Әгәр өең чит, салкын, анда шәфкатьлелек һәм татулык юк икән, бу инде — фаҗига.

Гаиләдәге мөнәсәбәтләр күптөрле һәм катлаулы. Алар әхлак нормаларына, гореф-гадәтләргә, күп гасырлык традицияләргә

нигезләнгән. Бер генә закон да гаилә җылысын, бер-береңтурында кайгыртучанлыкны тудыра яисә мәҗбүр итә алмый. Гаилә хокукында хокук һәм әхлакның үзара мөнәсәбәте бер җирдә булмаганча ачык чагыла. Закон — сак, күп кенә мөнәсәбәтләргә ул гомумән кысылмый, анда әхлак нормалары бар. Бу мөнәсәбәтләрнең бик әһәмиятлеләре генә закон тарафыннан көйләнә.

Гаилә хокукы — никахка керү шартларын һәм тәртибен билгеләүче, никахны өзүче һәм аны үз көчендә түгел дип танучы, гаилә әгъзалары, башка туганнар һ. б. кешеләр арасындагы мөлкәткә бәйле һәм мөлкәткә бәйләнмәгән шәхси мөнәсәбәтләрне җайга салучы, шулай ук ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм булган балаларны гаиләгә урнаштыру формаларын һәм тәртибен билгеләүче хокукый нормалар җыелмасы.

Никахка керү. Нәрсә ул никах? Никах — ике шәхеснең союзы, әмма ул зур иҗтимагый әһәмияткә ия. Гаилә хокукы буенча никах — ир белән хатынның үзара мәхәббәтләренә һәм ихтирамнарына нигезләнгән гаилә төзү максатында ЗАГС органнарында беркетелгән һәм үзара хокуклар һәм бурычлар барлыкка китерә торган ирекле союз ул. Никах ир белән хатынның якын мөнәсәбәтләрен юридик яктан беркетә.

Никахның нигезендә никахка керүчеләрнең шәхси хисләре ята: үзара мәхәббәт һәм хөрмәт.

Яшь буынның мәнфәгатьләрен һәм сәламәтлеген, никахның асылын һәм максатын саклау нигезендә җәмгыятьтә никахка керүнең билгеле бер тәртибе һәм шартлары билгеләнгән.

Никах гражданлык хәле актларын теркәү буенча махсус дәүләт органнарында (ЗАГС) теркәлә. Ни өчен мондый кагыйдә кертелгән? Мәсьәлә шунда ки, дини йолалар, милли гореф-гадәтләр буенча теркәлгән никахның юридик көче юк. Никахның дәүләт тарафыннан теркәлүе әлеге вакыйганы юридик фактка әйләндерә. Ир белән хатынның хокуклары һәм бурычлары никахларын дәүләт теркәвеннән соң башлана.

Никахны теркәү гариза бирелеп бер ай үткәннән соң башкарыла. Бу вакыт яшьләргә әлеге мөһим адымнарын тагын бер кат үлчәү өчен, уртак авырлыкларны җиңүгә әзерме, тормыш юлдашларын дөрес сайлаганнармы икәнлеген ачыклау өчен бирелә.

Никахны теркәү өйләнешүчеләрнең үзләре катнашында тантаналы шартларда башкарыла. Аларның үтенече буенча никах тыйнаграк шартларда да теркәлергә мөмкин. Ир белән хатынга никахлашу турында таныклык бирелә. Яңа өйләнешүчеләрнең паспортларында тиешле тамгалар салына.

Закон никахка керү мөмкинлеге бирә торган кайбер шартларны билгели. Алар берничә.

Никах ирекле союз булып исәпләнә. Ризалык бирү алдауга, куркытуга, читләр басымына нигезләнергә тиеш түгел. Бу хәл гаиләдә тиешле рухи-психологик шартлар тудырырга

ярдәм итә. Элек ата-ананың фатихасы кирәк булган. Закон хәзер моны таләп итмәсә дә, бу — яшьләр тормышта шундый җаваплы адым ясаганда ата-ана фикере белән исәпләшмәскә тиеш дигән сүз түгел. Өлкәннәр тәҗрибәсеннән күп кенә файдалы киңәшләр алырга мөмкин.

Иң мөһим шарт — никахка керүчеләрнең билгеле бер яшькә җитүе. Никахка унсигез яшьтә керергә мөмкин, һәм бу рәсми төстә балигъ булу яшенә туры килә. Россия законнары буенча ул ирләр һәм хатын-кызлар өчен бертөрле. Бу яшьтә егетләр һәм кызлар физик һәм психологик яктан җитлегә, мөстәкыйль хезмәт юлына аяк баса һәм гаиләләрен матди яктан тәэмин итәргә сәләтле була. Социаль җитлегү — ныклы никахның төп шарты. Игътибарга лаек сәбәпләр булганда, җирле үзидарә органнары, яшьләрнең үтенечләре буенча, аларга уналты яшьтән никахка керергә рөхсәт итәргә мөмкин.

Закон никахка керергә рөхсәт ителми торган шартларны да билгели. Әгәр кияү белән кәләш бүтән теркәлгән никахта торса, яңа никах теркәлми. Безнең илдә моногамия принцибы кабул ителгән — кеше бер вакытта бер генә никахта тора ала. Шулай да Россия территориясендә күп хатынлылыкны рөхсәт итә торган диннәр дә бар (ислам ирләргә дүрт хатынга өйләнергә рөхсәт итә). Шулай ук якын туганнар арасында өскә таба да, аска таба да (мәсәлән, ата-ана һәм балалар арасында, әби, бабай, оныклар арасында, бертуганнар арасында, уртак атадан яисә уртак анадан туганнар арасында) никахка юл куелмый. Бу тыю биологик (нәселдән килә торган патологиянең зарарлы йогынтысы булмасын өчен) һәм әхлакый (өлкәннәрнең кечеләрен психик яктан мәҗбүр итүләре мөмкин) сәбәпләр белән аңлатыла. Никах уллыкка алучы белән уллыкка алынучы арасында да була алмый. Физик яктан алар туганнар булып исәпләнмиләр, ләкин юридик яктан туганнарга тиңләштерелгәнгә, аларның хокукый мөнәсәбәтләре ата-аналар һәм балалар арасындагы мөнәсәбәтләр кебек төзелә.

Психик авыру яки акылга зәгыйфь булу сәбәпле суд тарафыннан хокукый сәләтсез дип табылган кешеләр дә никахка керә алмый. Алар үз мәнфәгатьләрен яклап мөстәкыйль эш йөртә алмыйлар һәм, димәк, никахка ризалык та бирә алмыйлар.

Никахка керү һәм гаилә төзү мөнәсәбәтләрендә социаль, раса, милли, тел яки дини яктан чыгып гражданнарның хокукын чикләүнең теләсә нинди формасы тыела.

Ир белән хатынның бер-берсенә карата хокуклары һәм бурычлары бары тик никахлары дәүләт органнарында теркәлгәннән соң гына барлыкка килә. Аларның шәхси һәм мөлкәткә бәйле хокуклары һәм бурычлары була.

Шәхси хокуклар һәм бурычларның нигезендә матди, мөлкәткә бәйле мөнәсәбәтләр юк. Кайчак: «Ул — гаилә башлыгы», — диләр. Шул ук вакытта бу тәгъбирнең юридик

мәгънәгә ия түгеллеген башларына да китермиләр. Россия законнарында гаилә башлыгы дигән төшенчә юк. Закон гаиләдә ир белән хатынның тигезлеген игълан итә. Тормыш итү һәм балалар тәрбияләү мәсьәләләрен ир белән хатын килешү нигезендә бергәләп хәл итә. Әмма тормышта һәр гаиләнең дә карарлар кабул итүдә үз традицияләре, абруйлы әйдәүчеләре була (әби, бабай, ир, хатын).

Никахка кергәндә ир белән хатын икесенең берсенең фамилиясен сайлап ала, һәм ул уртак фамилия булып китә, яисә һәркем үзенең элеккеге фамилиясен калдыра. Үз фамилиянңә иреңнең яисә хатыныңның фамилиясен өстәп язу да рөхсәт ителә. Никахны өзгән очракта ир белән хатын уртак фамилияне сакларга яки никахка кадәрге фамилиясен кире торгызырга хокуклы.

Ир белән хатынның һәркайсы шөгылен, һөнәрен һәм тору урынын ирекле рәвештә сайлый ала.

Мөлкәт хокукларының нигезендә икътисади эчтәлек ята.

Билгеле, ир белән хатынның мөлкәт мөнәсәбәтләре иң әүвәл һәр гаиләнең традицияләре, эчке гаилә тәртибе йогынтысы астында формалаша. Ире хатынына хезмәт хакын кайтарып бирәме, һәм хатыны аны гаилә кирәк-яракларына тотамы яисә киресенчәме — бу закон белән көйләнми һәм көйләнә дә алмый. Закон бары тик мөлкәт мөнәсәбәтләренең төп кагыйдәләрен генә билгели.

Ир белән хатынның мөлкәт мөнәсәбәтләре беренче чиратта никахлашканнан соң табылган һәм уртак файдаланылган мал-мөлкәткә кагыла. Аңа аларның һәркайсының хезмәт һәм кәсәбәчелек эшчәнлегеннән алынган керемнәр, аларның пенсияләре, акчалата алынган ярдәмнәре һ. б. керә. Гомуми керем хисабына алынган күчмә һәм күчемсез әйберләр (йорт, дача, автомобиль, телевизор, савыт-саба, җиһаз), кыйммәтле кәгазьләр, пайлар, банктагы кертемнәр, кредит учреждениеләренә яисә башка коммерция оешмаларына кертелгән капиталдагы өлешләр дә ир белән хатынның уртак мөлкәте булып исәпләнә. Аларның кайсы исеменә алынганлыгы әһәмиятле түгел. Никахлашканнан соң йортта хуҗалык эшләрен алып барган, балалар караган һәм башка нигезле сәбәпләр аркасында мөстәкыйль керемгә ия булмаган ирнең яисә хатынның да уртак мөлкәткә хокукы бар.

Уртак мөлкәткә хуҗа булу, файдалану һәм аның белән эш итү ир белән хатынның үзара килешүе нигезендә тормышка ашырыла.

Никахка кадәр булган, шулай ук никахта торганда ир яисә хатынның берсенә бүләк итеп бирелгән яки мираска калган мөлкәт аның милке булып санала. Гомуми керем хисабына алынган шәхси файдалану әйберләре (кием-салым, аяк киемнәре, китаплар һ. б.) аңардан файдаланган ирнеке яисә хатынныкы дип исәпләнә. Зиннәтле әйберләр (алтын-көмеш һ. б.) уртак милек булып исәпләнә.

Яңа гаилә кодексы ир белән хатын мөлкәтенең шартнамә тәртибен дә билгели. Никах шартнамәсе никахта яшәгәндә дә, аерылышкан очракта да ир белән хатынның милеккә хокукларын һәм бурычларын билгеләүче килешүне таный. Ул язма формада никахка кадәр дә, никахта яшәгәндә дә төзелергә мөмкин һәм нотариаль таныкланырга тиеш. Никах контракты ир белән хатынның үзара килешүе буенча теләсә кайсы вакытта үзгәрергә яисә юкка чыгарылырга мөмкин.

Никахның өзелүе. Никахның билгеле бер срогы юк, ул нигездә гомерлек итеп төзелә. Халыкның көмеш, алтын һәм бриллиант туйларны тантаналы төстә билгеләп үтә торган гореф-гадәте озакка сузылган ныклы никахның әхлакый кыйммәте турында сөйли. Мондый очракларда никах ир яки хатынның үлеме белән өзелә.

Кызганыч ки, төрле сәбәпләр аркасында, ир һәм хатын алга таба уртак тормышларының мөмкин түгеллеген аңлагач, күп кенә никахлар таркала. Рус композиторы А. Г. Рубинштейн (1829—1894): «Бәхетсез никахның таркалуы миңа никах бәйләнешләренең өзелгесезлегенә караганда әхлаклырак тоела, чөнки аерылышу ялганга чик куя», — дигән. Аерылышу социаль, психологик, әхлакый, матди сәбәпләр аркасында килеп чыга. Статистика күрсәтүенчә, аерылышуларның күпчелеге ир яисә хатынның эчкечелеге аркасында була. Эчкечелек — гаиләнең иң хәтәр дошманы, шуның аркасында җәнҗаллар, ызгышлар килеп чыга. Башка сәбәпләр дә бар: ашыгып никахлашу, гаилә мөнәсәбәтләрендәге хыянәт — иреңә яисә хатыныңа карата тугрылыксызлык, гаиләдә үз вазифаларыңа җавапсыз карау, үзара юл куешмау, икенченең фикере белән исәпләшергә теләмәү, гаиләнең башка әгъзалары мәнфәгатьләренә битарафлык. Һәр гаиләдәге низагның үз сәбәпләре бар. Лев Толстой юкка гына: «...һәрбер гаилә үзенчә бәхетсез», — димәгән.

Никах ир белән хатынның берсенең яисә икесенең дә гаризалары буенча аерылышу юлы белән өзелә. Бу гариза судка бирелә, һәм суд, ир белән хатынның дәрестән дә уртак тормышны дәвам итә алмауларына ышанса, аерылышу турында карар чыгара. Ир яки хатын сәбәпсез судка килмәсә, яисә аларның балалары һәм бер-беренә карата милек дәгъвалары булмаса, никахны өзүне ЗАГС башкара.

Закон тарафыннан куелган шартлар бозылган, шулай ук ялган никах төзелгән, ягъни ир белән хатын яисә аларның берсе гаилә корырга ниятләмәгән очракта никах суд аша гамәлдән чыгарыла.

Гаилә. Гаилә союзы — үзенчәлекле, кабатланмас һәм катлаулы иҗтимагый бәйләнеш. Гаиләне никахта торган, кан кардәшлеге белән яки башка нигездә үзара бәйләнгән, бер-берсенә карата хокукларга һәм бурычларга ия булган затлар тәшкил итә. Гаилә гадәттә ир белән хатыннан һәм аларның

балаларыннан тора, ләкин гаилә составына башка затлар — әбиләр, бабайлар, апалар, абыйлар, уллыкка алынучылар һ. б. керергә мөмкин. Шуңа күрә гаилә законнары ир белән хатын арасындагы мөнәсәбәтләрне генә түгел, ата-аналар һәм балалар арасындагы мөнәсәбәтләрне, аларның үзара хокукларын һәм бурычларын да көйли.

Ата-аналарның һәм балаларның хокуклары һәм бурычлары. Бала туу белән гаиләдә яңа хокукый мөнәсәбәтләр — ата-ана һәм бала арасындагы мөнәсәбәтләр барлыкка килә. Бу хокукларның һәм бурычларның нигезе булып баланың шушы ата-анадан тууы санала. Ата-ана законлы никахта торса, баланың кемнеке булуы никах турындагы таныклык белән раслана. Баланың анасы белән никахта тормаган кешенең ата булуы, беренчедән, ЗАГС органына ата-ананың икесенең гаризасы буенча, икенчедән, атаның яки ананың гаризасы буенча суд карары белән ачыклана. Биредә суд баланың кемнән туганлыгын раслаучы барлык дәлилләрне дә игътибарга ала. Әмма суд баланың атасы кем булуын ачыклый һәм раслый алмаска да мөмкин. Бу очракта баланың атасы фамилиясе анасы фамилиясе буенча, атасының исеме ананың күрсәтмәсе буенча язып куела. Ана судның бала атасын ачыклавын теләмәгән очракта да шулай ук эшләнә.

Бала хокуклары күп һәм төрле.

Һәр бала гаиләдә яшәргә, тәрбияләнергә, үзенең ата-анасын белергә, алар белән бергә яшәргә һәм аларның үзе турында кайгыртуларына (аның мәнфәгатьләренә каршы килә торган сәбәпләр булмаса) хокуклы. Бала ата-анасы тарафыннан тәрбияләнергә, төрле яклы үсеш алырга, кешелек дәрәҗәсенең хөрмәт ителүенә хокуклы. Бала ата-анасының икесе белән дә, әбисе, бабасы, абыйлары, сеңелләре һ. б. туганнары белән дә аралашырга хокуклы; ата-анасы аерым яшәгәндә, аларның икесе белән дә аралашырга хокуклы.

Бала ата-анасының законсыз гамәлләреннән үзенең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен якларга хокуклы; гаиләдә үз мәнфәгатьләренә кагылышлы теләсә нинди мәсьәләне хәл иткәндә үз фикерен белдерергә, шулай ук теләсә кайсы суд яисә административ тикшерү барышында сүз алырга хокуклы; аның мәнфәгатьләренә каршы килә торган булмаса, ун яшькә җиткән баланың фикерен исәпкә алу мәҗбүри; бала исемгә, атасының исеменә, фамилиягә хокуклы.

Ата-ана балаларына карата тигез хокукка ия, һәм аларга тигез бурыч йөкләнә (ата-ана хокуклары). Ата-ана балаларын тәрбияләүдә һәм үстерүдә җаваплы. Алар балаларының сәламәтлеге, физик, психик, рухи һәм әхлакый үсеше өчен җаваплы. Ата-ана балаларының төп гомуми белем алуларын тәэмин итәргә тиеш. Ата-ана хокуклары балалары балигъ булганнан соң туктала.

Әгәр ата-аналар үз вазифаларын үтәүдән баш тарталар икән, закон аларны ата-ана хокукыннан суд тәртибендә мәхрүм

итү мөмкинлеген карый. Ата-ана хокукыннан мәхрүм итү — җәза бирүнең иң соңгы чарасы, ул балага карата ата-ананың барлык хокукларын туктатуны үз эченә ала. Баланы башка ата-анага бирү мөмкинлеге булмаса, яисә әти-әнисенең икесе дә ата-ана хокукыннан мәхрүм ителсә, бала попечениегә алу өчен опека һәм попечительлек органына тапшырыла. Ата-ана (яки аның берсе) үз-үзен тотышын, яшәү рәвешен һәм бала тәрбияләүгә мөнәсәбәтен үзгәртсә, ата-ана хокукы кире кайтарыла.

Баланы ата-анасында яки аларның берсендә калдыру бала өчен куркыныч булса (психик яки хроник авыру, яшәү шартларының авырлыгы), суд баланы ата-ана хокукыннан мәхрүм итмичә генә алардан ала. Бу ата-ананың хокукын чикләү дип атала.

Россия Федерациясендә һәм Татарстан Республикасында ата-анасыз калган балалар игътибар үзәгенә алына. Алар нинди дә булса гаиләгә тәрбиягә бирелергә (уллыкка, кызлыкка, опекага, попечительлеккә) яки, әгәр андый мөмкинлек булмаса, ятим балалар яисә ата-анасы тәрбиясен югалткан балалар учреждениеләренә җибәрелергә тиеш. Баланы урнаштырганда аның милләте, билгеле бер дингә яки культурага каравы, ана теле, тәрбия һәм белем бирүдә дәвамчанлыкны тәэмин итү мөмкинлеге исәпкә алына.

Уллыкка алынган балалар мөлкәткә бәйсез шәхси хокуклар һәм мөлкәткә бәйле хокуклар һәм бурычлар буенча кандәшләргә тиңләнәләр. Баланы уллыкка алу закон тарафыннан сер булып саклана. Химаягә (опекага) алу ундүрт яше тулмаган балаларга карата билгеләнә. Попечительлек ундүрттән унсигез яшькә кадәр булган балаларга карата билгеләнә. Тәрбиягә бала алган гаилә баланы тәрбиягә бирү турындагы шартнамә нигезендә төзелә.

Шулай итеп, ата-аналар үз балаларын тәрбияләргә хокуклы һәм бурычлы, ә балалар шундый тәрбиягә хокуклы гына түгел, ата-аналарының таләпләрен намус белән үтәргә дә бурычлы.

Сораулар һәм биремнәр: 1. Гаиләнең җәмгыятьтәге роле нинди? Гаилә һәм никах шәхси эш кенәме? Никах-гаилә мөнәсәбәтләрен закон белән көйләү ни өчен зарур? Укыган китапларыгыз, караган кинофильмнарыгыздан гаилә тормышына кагылышлы нинди дә булса катлаулы эпизодны исегезгә төшерегез, аны әхлак һәм гаилә хокукы күзлегеннән чыгып аңлатыгыз. Яисә Рембрандтның «Юлдан язган улның кайтуы» картинасы буенча хикәя төзегез. **2.** Нәрсә ул никах? Никахлашуның тәртибе һәм шартлары нинди? Никахны дәүләт органнарында теркәүнең гражданнар һәм җәмгыять өчен зарурлыгы һәм хокукый мәгънәсе нәрсәдә? Гражданлык никахы, дини никах, хокукый никах — аларның аермасы нәрсәдә? Никах икътисади нияткә нигезләнә аламы? Ни өчен закон гариза бирү һәм никахны теркәү арасында билгеле бер срок таләп итә? Туганнары димләвенә бирелеп, кыз яратмаган кешесе белән никах-

ка керде, ди. Биредә никахка керү шарты бозылдымы? Мондый никах нык булыр дип уйлыйсызмы? 3. Ир белән хатынның хокуклары һәм бурычлары турында сөйләгез. Гаилә мөнәсәбәтләрендә ирләрнең һәм хатын-кызларның тигез хокуклылыгы принцибы нәрсәне белдерә? Бу принципның гаиләдәге конкрет чагылышын сез нәрсәдә күрәсез? Сезнең гаиләдә кем лидер, ни өчен алай уйлыйсыз? Уртак милкәттән файдаланганда ир белән хатынның тигезлеге нәрсәдә чагыла? Никах килешүе нәрсә ул? Ул ир белән хатынның хокукларын һәм хокукый сәләтлелекләрен чикли аламы? 4. Аерылышуларның сәбәпләре нинди? Никахны өзү тәртибе нинди? 5. Ир белән хатын кайчаннан башлап юридик мәгънәдә үз балаларының әти-әнисе булып исәпләнә? Ата-аналарның нинди хокуклары һәм бурычлары бар? Ни өчен бала тәрбияләү ата-аналарның төп вазифасы булып тора? Нинди очракларда ата-ана үзләренең баланы тәрбияләү хокукларыннан мәхрүм ителә? Бу гамәлнең нәтиҗәләре нинди? Ата-ана хокукларын чикләү алардан мәхрүм итүдән ни белән аерыла? 6. Балаларның нинди хокуклары бар? Балаларның ата-ана алдында бурычлары бармы? Ир туганнарның һәм кыз туганнарның, әбиләрнең һәм бабайларның, гаиләнең башка әгъзаларының үзара хокуклары һәм бурычлары бармы? Гаилә әгъзалары матди ярдәмнән башка тагын нәрсәгә мохтаҗлык сизәләр? Сезнеңчә, гаиләнең өлкән әгъзаларына карата әдәпле мөнәсәбәт нәрсәдә чагыла? 7. Гаилә нәрсә ул? Гаилә өчен бергә яшәү генә түгел, рухи якынлык хисе, карашлар һәм гадәтләр бердәмлеге, үз балаларын үзләре тәрбияләү дә әһәмиятлеме? Гаиләдә татулык һәм иминлек ничек барлыкка килә? Гаилә алдындагы җаваплылыкны сез ничек аңлыйсыз? Киләчәктә гаиләләр нинди булырга тиеш? «Әбиләрем һәм бабайларым турында» дигән темага инша языгыз. Өлкәннәр ярдәмендә гаиләгезнең нәсел агачын төзегез. 8. Гаилә кодексы төзесәгез, аңа тагын нәрсә өстәр идегез? Балалар ата-аналарын нәрсәгә өйрәтә алалар?

26. Җинаять — иң куркынычлы хокук бозу

Җинаятькә каршы көрәш хокукларының чыганаклары. 1996 елның 24 маенда Дәүләт Думасы тарафыннан кабул ителгән, 1996 елның 5 июнендә Федерация Советы тарафыннан хупланган һәм 1997 елның 1 гыйнварыннан гамәлгә кертелгән Россия Федерациясе Җинаять кодексы (РФ ҖК) төп чыганак булып исәпләнә. Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы арасындагы вәкаләтләрне бүлешү турындагы шартнамә буенча җинаять законы мәсьәләләре тулысынча Россия карамагына кертелгән.

* * *

Җинаятькә каршы көрәш хокукы — Россия Федерациясе дәүләт хакимиятенең югары органы тарафыннан куела торган хокук нормалары җыелмасы, анда нинди иҗтимагый куркыныч гамәлләрнең нинди шартларда җинаять дип исәплә-

нүе һәм җинаять кылган кешеләргә нинди җәза бирелергә мөмкин булуы күрсәтелә.

Җинаятькә каршы көрәш хокукы җәмгыятьнең һәм дәүләтнең шәхес, җәмгыять һәм дәүләт мәнфәгатьләре өчен бик куркыныч гамәлләргә — җинаятькә — җавап йөзеннән барлыкка килгән. Һәм бу мәгънәдә җинаятькә каршы көрәш хокукы, гомумән хокук кебек үк, мәдәният һәм культура күренеше булып тора. Игътибар итегез әле: «үтермә», «урлама» кебек тыюларның тамыры борынгы заманнардан ук килә бит. Җинаятькә каршы көрәш хокукы үзенчәлекле чаралар ярдәмендә шәхесне, җәмгыятьне, дәүләтне җинаятьчел гамәлләрдән саклау өчен барлыкка килгән. Ул нинди чаралар соң? Иң әүвәл — тыелган гамәлне кылган өчен җинаятькә каршы көрәш хокукы буенча җәза көтелү һәм аны куллану. Саклау бурычы — җинаятькә каршы көрәш хокукының төп тарихи бурычы, өстәвенә ул дәүләтнең сәяси төзелешенә һәм аның икътисади үзенчәлекләренә бәйсез рәвештә тормышка ашырыла.

РФ Җинаять кодексы Гомуми һәм Махсус бүлекләрдән тора.

31 нче схема

Россия Федерациясенең Җинаять кодексы

Гомуми бүлек	Махсус бүлек
Җинаять законы	Шәхескә каршы җинаятьләр
Җинаять	Икътисад өлкәсендәге җинаятьләр
Җәза	Иҗтимагый иминлеккә һәм җәмәгать тәртибенә каршы җинаятьләр
Җинаять җаваплылыгы һәм җәзадан азат итү	Дәүләт хакимиятенә каршы җинаятьләр
Балигъ булмаганнарның җинаять җаваплылыгы	Хәрби хезмәткә каршы җинаятьләр
Медицина характерындагы мәҗбүр итү чаралары	Кешелек дөньясының тынычлыгына һәм иминлегенә каршы җинаятьләр

Гомуми бүлек җинаять җаваплылыгының бурычларын, принципларын һәм нигезләрен билгеләүче нормаларны, җинаятькә каршы көрәш законының гамәлдә булуын, җинаять һәм җәза төшенчәләрен, җәза билгеләү һәм аннан азат итү тәртибен берләштерә. Җинаять кодексының махсус бүлеге җинаять кылуның аерым очракларының исемлеген һәм тасвирламасын бирә, һәр җинаять өчен нинди җәза бирелүен күрсәтә.

Җинаять нәрсә ул? Җинаять кылуда гаепләнүче кеше генә җинаять җаваплылыгына һәм җәзасына тартыла. Кеше бары тик суд хөкеме һәм закон буенча гына җинаять кылуда гаепле дип таныла һәм җинаять җәзасына тартыла.

Димәк, нәрсә ул җинаять? Менә таныш укучым белән булган бер сөйләшү:

— Закон бозган теләсә нинди гамәл җинаять була.

— Яхшы. Алайса, синеңчә, трамвайда билетсыз бару да җинаять буламы? Билетсыз йөрүче законны боза бит. Ә дәрескә соңга калу? Тиеш булмаган урыннан урамны аркылы чыгу?

— Юк! Мин караклык, кеше үтерү турында гына әйтергә телим.

— Әйтик, дачада янгын чыккач, сез, хуҗасыннан сорамый гына, су ташыр өчен аның арбасын алып тордыгыз, ди. Яисә, сезгә һөҗүм иткән талаучыга суккан идегез, ул җан тәслим кылды, ди. Бу җинаятьме?

— Әйтүе кыен. Бер яктан, җинаять тә кебек. Икенче яктан...

Әйе, җинаятьнең нәрсә икәнлеген белми торып, һәр төрле тикшеренүләр һәм судның файдасы юк.

Җинаять — җәза бирелү куркынычы астында закон тарафыннан тыела торган иҗтимагый куркыныч гамәл (хәрәкәт яки хәрәкәтсезлек). Башкача әйткәндә, ул җәмгыять, гражданнар, дәүләт өчен гаять куркыныч хокук бозу, аның өчен җаваплылык җинаятькә каршы көрәш законында карала. Россия Федерациясенең Җинаять кодексы җинаять булып исәпләнә торган хокук бозуларның тулы исемлеген үз эченә алган. Җинаять җаваплылыгын башка берниндн закон да билгели алмый. Димәк, Россия территориясендә, Татарстан Республикасын да кертеп, җаваплылыгы РФ ҖКда каралган хокук бозу гына җинаять дип исәпләнә.

Җинаять составы нинди була соң? Бу 32 нче схемадан ачык күренә.

Әгәр шушы моментларның берсе генә булса да юк икән, димәк, җинаять җаваплылыгы да юк дигән сүз. Моны җентекләбрәк карап үтик.

34 нче схема

Җинаять составы —
кылынган эшне конкрет бер җинаять буларак характерлаучы сыйфатларның закон билгеләгән җыелмасы

Җинаять җаваплылыгының зарури нигезе

Җинаять объекты — җинаять зыян сала торган иҗтимагый мөнәсәбәт

Җинаять субъекты — билгеле бер яшькә җиткән, җинаять кылган һәм җинаять җәзасына тартылырга тиешле акылга сау физик зат

Объектив як — иҗтимагый куркыныч зыян салуның тышкы ягы (хәрәкәт яки хәрәкәтсезлек)

Субъектив як — кешенең үзе кылган иҗтимагый куркыныч эшкә психик мөнәсәбәте

Җинаять объекты — җинаять юнәлтелгән иҗтимагый мөнәсәбәтләр. Җинаятьнең иң мөһим билгесе — аның иҗтимагый куркынычлылыгы. Җинаятькә каршы көрәш законы тарафыннан саклана торган объектларга зыян сала яки салу мөмкинлеге тудыра торган эш иҗтимагый куркыныч дип исәпләнә. Иҗтимагый куркынычлылык җинаятьнең асылын һәм аның башка хокук бозулардан аерылуын аңлау өчен дә әһәмиятле.

Җинаятьнең объектив ягы — җинаятьчел хәрәкәтнең яки хәрәкәтсезлекнең үзен, аның нәтиҗәләрен, кылынган эш һәм нәтиҗә арасындагы элемтәне, җинаять кылуның ысулын, чараларын, шартын, вакытын һәм урынын характерлаучы тышкы сыйфатлары.

РФ ҖКның 14 статьясы буенча формаль яктан җинаятькә каршы көрәш законында карала торган нинди дә булса хәрәкәт яки хәрәкәтсезлек сыйфатлары күренгән, ләкин әллә ни әһәмиятле булмавы аркасында иҗтимагый куркыныч дип исәпләнмәгән, ягъни шәхескә, җәмгыятькә һәм дәүләткә зыян китермәгән эш җинаять дип исәпләнми.

Атаклы рус адвокаты Федор Никифорович Плевако, моннан йөз еллар чамасы элек әйбер урлауда гаепләнүче бер карчыкны яклап Мәскәү судында чыгыш ясаганда, кылынган эшнең кечкенә булуыннан бик оста файдалана. Карчык калай чәйнек урлаган була. Плеваконың көчле адвокат булуын белгән прокурор мөмкин булганча карчыкны яклап алдан үзе әйтергә була. «Карчык ярлы, бик нык мохтаҗлыкта яши, урланган әйбере дә бәләкәй. Аңа карата нәфрәтләнергә түгел, аны кызганырга кирәк. Әмма милек кагылгысыз бит! Безнең бөтен җәмгыять милеккә карап тора. Әгәр аны һәркем төрле яклап йолыккалый башласа, ил һәлак булачак. Шулай ди дә прокурор, адвокат ни әйтер икән дип, урынына барып утыра. Менә Плевако күтәрелә: «Үз гомерендә Россиягә күп бәлаләр күрергә, күп сынаулар узарга туры килде. Бөтенесенә түзде, бөтен нәрсәне җиңде, ул сынауларда ныгый гына барды. Әмма хәзер, хәзер... Бу карчык 30 тиенлек иске чәйнек урлаган. Менә моны Россия, билгеле, күтәрә алмаячак, ул моннан бөтенләй һәлак булачак». Һәм карчыкны җинаять составы булмау сәбәпле аклыйлар.

Җинаять кодексының һәр статьясы аны конкрет очракта файдаланганда теге яки бу затның хәрәкәтендә иҗтимагый куркыныч гамәл сыйфатларын, яисә, киресенчә, җинаять составының булмавын билгеләргә мөмкин булырлык итеп тәгъбирләнә.

Җинаять кодексының күпчелек статьялары билгеле бер гамәлләрне тыю формасында тәгъбир ителә. Закон билгеле бер гамәлләрне (үтерү, талау, урлау, хулиганлык һ. б.) җинаять дип игълан итә һәм аны кылуны тыя. Әмма тормышта кешедән, киресенчә, актив хәрәкәт таләп итә торган хәлләр дә була. Мондый очракта хәрәкәтсезлек тә шулай ук җинаять дип исәпләнергә мөмкин. Әйтик, берәү, автомобиле белән кешене бәрдергәч, аны шифаханәгә алып китми, һәм бәлагә таручы медицина ярдәме вакытында күрсәтелмәү аркасында үлә. Яисә врач авыруга тиешле ярдәмне күрсәтми. Бу очракларда җинаять хәрәкәтсезлек аркасында кылына.

Җинаять субъекты — җинаять законында каралган һәм законда күрсәтелгән сыйфатлар белән характерлана торган иҗтимагый куркыныч гамәл кылган физик зат.

Җинаятьне кеше генә кылырга мөмкин. Хайваннар, табигать көчләре, җансыз предметлар китергән зыян — җинаять түгел. Бу положение хокукта тиз генә кабул ителмәгән. Тарихтан мисал китерик.

Париж. 1457 ел. Шәһәр судында биш яшьлек малайны үтерү эше карала. Дәгъвачы — малайның әтисе. Хөкем карары каты: җинаятьче асып үтерелергә тиеш. Монда искитәрлек нәрсә юк бит, диярсез, ләкин... Хөкем ителүчеләр эскәмиясендә — гади йорт дуңгызы. Ул урамда йөргәндә ачык ишектән әлеге кешеләрнең өенә кергән һәм йоклап яткан бичара баланы кимергән. Алга таба вакыйга җинаять сюжеты кануннары буенча дәвам итә: «үтерүче» кулга алына һәм төрмәгә ябыла, башка тоткыннар белән бер камерага утыртыла.

Ә менә монысы бүгенге көн мисалы.

Хуҗасы эткә борынчык киертмәгән була, һәм ул үтеп баручыны тешли. Тән җәрәхәте өчен кем җавап бирергә тиеш? Билгеле, эт хуҗасы. Ул үзенең этенең куркынычсызлыгын тәэмин итмәгәнлеге, саклык чаралары күрмәгәнлеге өчен җавап бирә.

Әйтеп үтелгәнчә, җинаять җаваплылыгына тартылган кеше акылга сау булырга тиеш. Иҗтимагый куркыныч гамәл кылган вакытында кеше үз-үзен белештерми торган халәттә булса, ягъни акылга хроник зәгыйфь, акыл эшчәнлеге вакытлыча бозылган, җиңел акыллы яисә башка авыруы булуы аркасында үз хәрәкәтләре белән идарә итә алмаса, җинаять җаваплылыгына тартылмый. Андый кешегә суд билгеләмәсе буенча медицина характерындагы мәҗбүр итү чаралары кулланыла. Акылга сау вакытында җинаять кылып, хөкем карары чыгарганчы ни эшләгәнен белештермәслек һәм хәрәкәтләре белән идарә итә алмаслык дәрәҗәдә психик авыруга дучар булса да, кеше җәзага тартылмый. Мондый кешегә хөкем карары буенча медицина характерындагы мәҗбүр итү чаралары кулланылырга мөмкин, ә сәламәтләнү белән ул җәзага тартылырга тиеш.

Җинаять кылучының ничә яшьтә булуы мөһимме соң? Әлбәттә. Әле Петр I үк кечкенә балага караклык өчен бирелә торган җәза кечерәйтелә яисә бөтенләй бирелми, чөнки әтиәнисенең сыек чыбыгы аны вакытында акылга утырта ала дигән карар чыгарган. Закон җинаять җаваплылыгына тартыла торган яшьне төрле илдә төрлечә билгели: кайбер илләрдә ул — 7 яшьтән, кайберләрендә — 16 яшьтән.

Россия законы җинаять җаваплылыгына тартылырга тиешле ике яшь чиген билгели. Күпчелек җинаять өчен җаваплылык 16 яшьтән башлана. РФ ҖКның 20 статьясы буенча җинаять кылганчы 16 яше тулган затлар җәзага тартылырга тиеш. Ундүрт яшьтән уналты яшькә кадәрге затлар үтергән өчен, сәламәтлеккә аңлы рәвештә уртача авырлыктагы зыян салган, кеше урлаган, көчләгән, сексуаль характердагы көч куллану хәрәкәтләре ясаган, урлаган, талаган, янап алган, урлау максатыннан тыш хаксыз рәвештә автомобильгә яисә башка транспорт чарасына ия булган, авырайта торган хәлләрдә милекне аңлы рәвештә юкка чыгарган яки зыян салган, террорлык, авырайта торган хәлләрдә хулиганлык, вәхшилек кылган, утлы корал, сугыш кирәк-яраклары, шартлаткыч матдәләр һәм шартлату җайланмаларын урлаган яки янап алган, наркотик матдәләр урлаган яки янап алган, транспорт чараларын яки аралашу юлларын яраксыз хәлгә китергән өчен җинаять җаваплылыгына тартылалар. Бу — тулы исемлек, ягъни ундүрт яшьтән бары тик законда каралган шушы җинаятьләр өчен генә җинаять җаваплылыгына тартылалар.

Законда күрсәтелгән яшькә җитмәгән кешеләр иҗтимагый куркыныч гамәлләр кылган өчен җинаять җаваплылыгына тартыла алмыйлар.

Җинаять законы кырыс. Аның таләпләрен бозган һәркем, шул исәптән балигъ булмаганнар да, җавап бирергә тиеш. Шул ук вакытта ул балигъ булмаганнарга карата гуманлы да.

Җинаятьнең субъектив ягы — кешенең кылган гамәленә, аның нәтиҗәләренә психик мөнәсәбәте, башкача әйткәндә, бу — гаеп. Хәрәкәт итү яки хәрәкәтсезлек — болар һәрвакытта да кешенең акылы һәм ихтыяры күзәтүе астындагы үз-үзен тотышы.

Гаеп явыз ният белән яисә саксызлык аркасында эшләнергә мөмкин.

33 нче схема



Әгәр җинаять кылган кеше үзенең хәрәкәтенең яки хәрәкәтсезлегенең иҗтимагый куркыныч характерын аңлаган, аның иҗтимагый куркыныч нәтиҗәләрен алдан күргән һәм аларны теләгән яки аңлы рәвештә юл куйган икән, җинаять **явыз ният белән** кылынган дип исәпләнә.

Ирек Хәбибуллин Володя Ивановны дискотекада үзен тупас тоткан өчен дип кыйнап ташлады. Нәтиҗәдә Володя тән җәрәхәтләре

алды һәм, өч атна буе авырып, дәресләргә йөри алмады. Володяны кыйнаган вакытта Ирек закон тарафыннан тыелган гамәл кылуын белеп торды, Володяның сәламәтлегенә һәм кешелек дәрәҗәсенә зыян салырга теләде һәм моны алдан күрде. Тикшерүче Хәбибуллинны турыдан-туры явыз ният белән хәрәкәт иткәнлеге өчен җинаять җаваплылыгына тартуны сорады.

Әгәр җинаять кылган кеше үзенең хәрәкәтенең яисә хәрәкәтсезлегенең иҗтимагый куркыныч нәтиҗәләргә китерү мөмкинлеген алдан күргән, ләкин, җиңел уйлап, аларны булдырмый калуына исәп тоткан булса, яисә, күрергә тиеш булса да, мондый нәтиҗәләргә юлыгу мөмкинлеген алдан күрмәсә, җинаять саксызлык аркасында кылынган дип исәпләнә.

Гамәлдәге Җинаять кодексындагы статьяларның якынча биштән бер өлеше саксызлык аркасында кылынган җинаять өчен җаваплылыкны күздә тота. Саксызлык аркасында гадәттә юл йөрү һәм транспорт белән идарә итү кагыйдәләрен бозу, эшкә салкын карау, хезмәтне саклау кагыйдәләрен бозу, законсыз утлы корал саклау кебек һәм шуңа охшаш башка җинаятьләр кылына.

Уналты яшьләре яңа тулган Юра һәм Леонид урманда учак ягалар. Җәй көне була бу. Аланлыктан киткәндә Юра учакны сүндермәкче була. Леонид чыбык-чабыкның инде янып беткәнлеген һәм учакның үзеннән-үзе сүнәчәген әйтә. Алар китеп бераз вакыт үткәннән соң, җил чыга, пыскып яткан учак «терелеп» китә. Урманда янгын чыга. Малайлар сүндерелмәгән учактан янгын чыгар дип уйламыйлар, янгын чыгуын һич тә теләмиләр. Әмма алар инде моны алдан күрерлек һәм күрергә тиешле яшьтә булалар. Юрий һәм Леонидның гаепләре саксызлыкта күренә.

Кешенең җинаять кылуына билгеле бер сәбәп була. Һәм ул билгеле бер максатка юнәлдерелә. Теләсә нинди гамәлгә дөрес бәя куйганда, сәбәпне һәм максатны исәпкә алмыйча мөмкин түгел. Сәбәп һәм максат — гаеп белән беррәттән җинаятьнең субъектив ягын тәшкил итүче психик күренеш.

34 нче схема

Сәбәп	Максат
Кешенең җинаять кылу ниятен уята һәм аны кылганда җитәкчелек итә торган билгеле бер ихтыяҗларга һәм мәнфәгатьләргә нигезләнгән эчке теләкләре, ул гаепне авырайта һәм җиңеләйтә торган шарт булырга мөмкин (комсызлык, кызгану һ. б.)	Киләчәк нәтиҗәнең алдан уйланган үрнәге, җинаять кылганда кеше шуңа ирешергә омтыла

Явыз ният белән кылынган җинаять саксызлык аркасында килеп чыккан җинаятькә караганда куркынычрак. Явыз ният белән кылынган җинаятьләр саксызлык аркасында булганнары белән чагыштырганда җиде-сигез тапкыр ешрак очрый. Алар өчен санкцияләрнең төрлелеге дә шушы хакта сөйли. Мәсәлән, кеше үтергән өчен унбиш елга кадәр, ә авырайтылган шартларда эшләнсә — егерме елга кадәр иректән мәхрүм итү яки үлем җәзасы каралган; саксызлык аркасында үтергән өчен, өч елга кадәр иректән мәхрүм итү каралган. Саксызлык аркасында кылынган җинаятьләрне дә тиешенчә бәяләргә кирәк. Кагыйдә буларак, саксызлык җинаятьләре өстән уйлау, җилбәзәклек, гамьсезлек, куркынычлылык чыганагы булган предметлар (техника, ут, корал, шартлаткыч матдәләр һ. б.) белән саксыз эш итү аркасында килеп чыга.

Җинаять кылуда **катнашу** төшенчәсен карыйк. Җинаять җаваплылыгына аны кылучылар гына түгел, катнашучылар да тартылырга мөмкин. Катнашу тагын да куркынычрак җинаять гамәле булып исәпләнә, һәм шуңа күрә аның өчен закон буенча шактый кырыс җәза бирелә, ул практикада бик еш очрый — белә торып кылынган җинаятьләрнең кырык проценты катнашу нигезендә кылына. Балигъ булмаганнар арасында бу тагын да ешрак: дүрт җинаятьнең өчесе катнашу нигезендә кылына. Төркем белән кылынган һәр җинаять түгел, ә бары тик белә торып һәм бергәләп алдан әзерләнеп кылынган җинаять кенә катнашу дип атала.

Катнашучыларның һәммәсе дә бер үк төрле җавап бирми. *Оештыручы, котыртучы, башкаручы, булышучы* төрлечә җавап тота.

Башкаручы — үзе турыдан-туры җинаятьне кылучы кеше.

Оештыручы — җинаятьне оештырган (мәсәлән, план төзи, алдан ук катнашучыларның ролен билгели) яки аңа җитәкчелек иткән (башкаручыларга ничек хәрәкәт итәргә, җинаять эзен ничек яшерергә икәнлеген күрсәтә) кеше.

Котыртучы — башка катнашучыларны җинаять кылырга этәрүче кеше (мәсәлән, янау, үгетләү, вәгъдә бирү ярдәмендә).

Булышучы — җинаять кылырга ярдәм итүче кеше (вату өчен корал бирә, каравылчының игътибарын читкә юнәлтә, алдан ук җинаятьчене, коралларны, җинаять эзләрен, җинаять юлы белән табылган предметларны яшерергә вәгъдә бирә).

Билгеле, нинди дә булса җинаятьне кылганда санап үтелгәннәрнең барысы да катнашмаска да мөмкин. Арада иң куркынычы — оештыручы. Еш кына ул элек хөкем ителгән кеше була. Җинаятьнең максатына ирешү өчен алар яшүсмерләрне яисә хәтта кече яшьтәгеләрне тарталар, алары исә үзләренең гамәлләрен чын-чынлап аңлап җиткермиләр һәм үгетләүләргә тиз күнәләр.

Закон аерым очракларда җинаятьчене яшергән яки җинаять булачагын белеп тә бу турыда хәбәр итмәгән кешегә дә

җаваплылык йөкли. Хәбәр итмәү җинаятьчегә гадел хөкемнән качу мөмкинлеге бирүе белән хәтәр.

Сораулар һәм биремнәр: 1. Җинаятькә каршы көрәш законы нәрсә ул, ул нәрсәне саклый? Бу закон законсыз мәнфәгатьләрне яклыймы? 2. Җинаятьнең административ (дисциплинар, гражданлык-хокукый) гаептән аермасы турында кечкенә генә иншa әзерләгез. 3. Җинаятьтә катнашучыларның һәммәсе дә бертөрле җавап бирәме? Катнашучыларның җаваплылыгы ни өчен тигез була алмый? 4. Җинаять җәмгыятьтән үч алу сыйфатында була аламы?

27. Җинаять җаваплылыгына юл калдырмый торган шартлар

Җинаятькә каршы көрәш хокукында шундый шартлар бар: тышкы яктан кайсыдыр гамәлләр җинаятькә охшый, әмма иҗтимагый куркыныч булып исәпләнми, җинаять дип аталмый. Бу — саклану чарасы, соң чик зарурлык, җинаятьчене тоту, боерыкны үтәү, профессиональ тәвәккәллек, зыян күрүченең ризалыгы, профессиональ вазифаларны үтәү.

Закон гражданнарга җинаятьче һөҗүме вакытында үз-үзенне тоту вариантларын сайларга мөмкинлек бирә: качарга, җинаятьченең боерыгын үтәргә, актив төстә сакланырга. Моны аерым мисалда карап үтик:

Өч дус — Миша, Семен һәм Толя — паркта йөриләр икән. Көтмәгәндә куаклар артыннан таза гәүдәле ике егет килеп чыга да, пәке белән янап, малайлардан акча таләп итә. Миша шунда ук йөгерергә тотына, ә Семен акча чыгарып бирә, Толя исә, талаучыларның пәкесен тартып алып, берсенең йөзенә суга. Ул бокс секциясенә йөргән була, соңыннан аның әлеге егеткә тән җәрәхәтләре ясаганлыгы ачыклана. Милициядә аның бу гамәленең саклану чарасы булуын әйтәләр.

Күрүебезчә, әлеге хәлгә юлыгучыларның һәркайсы үз ысулын сайлаган. Акча бирүчене дә, качып котылучыны да гаепләп булмый, әмма, иҗтимагый күзлектән чыгып караганда, Толяның үз-үзен тотышы иң мактаулысы — ул актив төстә сакланган һәм җиңгән.

Җинаятькә каршы көрәш махсус дәүләт органнарына — милициягә, прокуратурага, судка йөкләнгән. Әмма бу органнарның эшчәнлеге гражданнар җинаятьчеләргә үзләре кискен каршылык күрсәткәндә генә уңышлы булырга мөмкин. Закон һәр гражданның үз хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен, башка кешенең, җәмгыятьнең, дәүләтнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен иҗтимагый куркыныч янаудан тиешле саклану юлы белән яклау мөмкинлеген дә беркетә. Җинаятьчел гамәлләр белән көрәш — гражданның хокукы, шул ук вакытта аларны булдырмый калу һәр гражданның иҗтимагый бурычы да. Закон җинаятьчеләр белән актив көрәш алып баручылар сагында тора.

Саклану кайсы очракларда дөрес, законлы, ягъни зарури дип исәпләнә? Бу хокукый күренешнең исеме дә шуннан — **зарури саклану.** Әгәр зарури саклану чигеннән узылмаса, сакланучының яисә башка кешеләрнең шәхесләрен һәм хокукларын, җәмгыять яки дәүләт мәнфәгатьләрен иҗтимагый куркыныч янаудан җинаятьчегә зыян салу юлы белән саклау законлы дип исәпләнә.

Зарури саклану җинаять җаваплылыгыннан азат итә. Югарыда китерелгән мисалда тикшерүче Толяның зарури саклану халәтендә эш итүен һәм аның җинаять җаваплылыгыннан азат ителүен билгеләгән.

Иҗтимагый куркыныч янауның характерына һәм дәрәҗәсенә туры килми торган, белә торып кылынган гамәлләр зарури саклану чиген арттыру дип исәпләнә. Һөҗүм итү һәм саклануны киеренкелекләре буенча чагыштырганда, ташка каршы таш, таякка каршы таяк, пычакка каршы пычак булырга тиеш дип, абсолют тигезлекне таләп итәргә ярамый. Һөҗүм ителгән кешенең нык дулкынланган халәттә булуын, хәлне дөрес бәяли алмаска, саклану чаралары кулланганда хата җибәрергә мөмкин икәнлеген исәпкә алырга кирәк.

Зарури саклану чиген арттырган өчен җинаять җаваплылыгы каралган, чөнки мондый гамәлләр иҗтимагый куркыныч дип исәпләнә. Әмма закон аларны җаваплылыкны йомшарта торган шартларга кертә. Ни өчен? Чөнки әлеге гамәлләр иҗтимагый куркыныч һөҗүмгә каршылык күрсәтергә, кемнеңдер гомерен, сәламәтлеген, милекне һ. б. объектларны җинаятьчел кул сузудан сакларга теләү аркасында кылына. Закон сакланучы ягында, ләкин ул башбаштаклыкка юл куймый. Зарури саклануның төп идеясе түбәндәгечә: гражданнарга җинаятьчел янаулардан саклану хокукы бирергә, ләкин аны башбаштаклыкка, үч алуга әйләндермәскә.

Актив саклану еш кына җинаятьчене «айнытып» җибәрә, башлаган җинаятен дәвам итәргә комачаулый. Әгәр инде корбаны җинаятьченең барлык таләпләрен карусыз үти икән, ул аны соңыннан да дәшмәячәк һәм беркая да мөрәҗәгать итмәячәк дип исәпли. Кыскасы, һөҗүмгә дучар булганда пассивлыкны үз-үзеңне тотуның иң дөрес юлы дип атап булмый.

Җинаять кылган кешене тотканда аңа зыян салу шулай ук җинаятьчел гамәл дип исәпләнми. Җинаять кодексында бу положение түбәндәгечә аңлатыла: әгәр җинаять кылган кешене башка чаралар белән тотарга мөмкин булмаса һәм моның өчен зарури чаралар арттырып кулланылмаса, хакимият органнарына алып килү һәм яңа җинаятьләр кылу мөмкинлеген булдырмау өчен, тоткан вакытта зыян салу җинаять дип исәпләнми. Җинаятьчене тоткан вакытта аның кылган җинаятенең иҗтимагый куркынычлылык дәрәҗәсенә туры килми торган кирәгеннән артык чаралар куллану һәм шуның нәтиҗәсендә аңа зыян китерү җинаятьчене тоту өчен кирәкле

чараларны арттырып җибәрү дип атала. Бу очракта җинаятьчегә белә торып зыян китерелсә генә аны тоткарлаучы кеше җаваплылыкка тартыла.

Чиктән тыш зарурлык — шәхескә һәм аның хокукларына, җәмгыятьнең һәм дәүләтнең закон тарафыннан саклана торган мәнфәгатьләренә турыдан-туры янаган куркынычны бетерү өчен (әгәр башка ысуллар булмаса) кулланылган һәм зарурлык чикләрен узып китмәгән чара. Аның өчен җинаять җаваплылыгы каралмаган.

Чиктән тыш зарурлыкка «Белорусский вокзал» кинофильмындагы бер эпизодны мисал итеп китерергә мөмкин.

Газүткәргечтәге ватыкны төзәткәндә, газга агуланып, яшь эшче аңын җуя. Фильм геройлары аны люктан тартып чыгаралар һәм тиз генә шифаханәгә озатмакчы булалар. Беренче очраган автомобильне туктаталар да шофердан үзләренә булышуын үтенәләр. Шофер каршы килә. Шуннан соң геройларның берсе аңа йодрыгы белән тондыра да, бүтәннәре, автомобильгә утырып, эшчене шифаханәгә илтәләр. Автомашина хуҗасының гаризасы буенча, аларны тотып, милициягә алып киләләр. Әмма хәлне аңлаганнан соң, шунда ук азат итәләр.

Ни өчен закон чиктән тыш зарурлык хәлендә кылынган гамәлләрне, милеккә, шәхескә зыян китерсәләр дә, җинаятьчел дип исәпләми? Чиктән тыш зарурлык хәлендә кылынган гамәлләр мәҗбүри, килеп туган хәлләрдә бердәнбер мөмкин чара булып тора, алар инде кылынган зыяннан да куркынычрак зыянны булдырмый калу нияте белән эшләнә.

Зарури саклану һәм чиктән тыш зарурлык арасындагы охшашлыклар һәм аермаларны чагыштырыгыз.

35 нче схема

Зарури саклану	Чиктән тыш зарурлык
Куркыныч чыганагы	
һәрвакыт җинаятьчел хәрәкәт	табигать көчләре, табигый бәла-каза, бәхетсезлек очрагы һ. б.
Кемгә зыян килә	
һәрвакыт һөҗүм итүчегә	өченче затларга, матди әйберләргә
Зыянның күләме	
һөҗүм итүче ясаган зыяннан күрәләтә зур булмасын	булдырмый калган зыяннан кечерәк булсын

Нигезле тәвәккәллек. Иҗтимагый файдалы максатка ирешү өчен нигезле тәвәккәллек вакытында закон тарафыннан саклана торган мәнфәгатьләргә зыян салу җинаять дип исәпләнми. Әгәр күрсәтелгән максатка тәвәккәллек белән бәйләнмәгән хәрәкәтләр (хәрәкәтсезлек) ярдәмендә ирешеп булмаса һәм тәвәккәлләгән кеше закон тарафыннан саклана торган мәнфәгатьләргә зыян китермәс өчен җитәрлек чаралар кулланса, тәвәккәллек нигезле дип исәпләнә. Әгәр күп кешенең гомеренә куркыныч янау, экологик һәлакәт яки иҗтимагый бәла-каза алдан ук күренеп торса, тәвәккәллек нигезле дип табылмый.

Боерыкны яисә күрсәтмәне үтәү. Үзе өчен мәҗбүри булган боерыкны яки күрсәтмәне үтәү вакытында закон тарафыннан саклана торган мәнфәгатьләргә зыян салу җинаять дип исәпләнми. Мондый зыян өчен законсыз боерык яисә күрсәтмә биргән кеше җинаять җаваплылыгына тартыла. Законсыз икәнлеге алдан ук күренеп торган боерыкны яисә күрсәтмәне үтәмәгән кеше җинаять җаваплылыгыннан азат ителә.

Сораулар һәм биремнәр: 1. Безнең мисалда Миша һәм Семен дөрес эшләгәннәрме? Толя җинаять, ягъни хокукый җаваплылыктан азат ителә. Ул әхлакый яктан җавап бирергә тиешме? Әгәр нинди дә булса үтеп баручы, малайларны яклап, җинаятьчеләрнең берсенә шундый ук тән җәрәхәте салса, нәрсә үзгәрер иде? Алар урынында сез булсагыз, ни эшләр идегез? Тормышыгызда моңа охшаш хәлләр булганы юкмы? 2. Ни өчен җинаятьчел һөҗүмнән саклану «зарури» булырга тиеш? Нинди очракларда һөҗүм итүчегә зыян салу аклана? Әгәр җинаять корбаны актив каршылык күрсәтмәсә, җинаятьченең җаваплылыгы кимиме? 3. Тагын нинди очракларда җинаять җаваплылыгы булмый?

28. Җинаять җәзасы төшенчәсе һәм аның максатлары

Җинаять кылган өчен кешегә җинаять җаваплылыгы — җәза бирелә.

Ф. М. Достоевскийның «Җинаять һәм җәза» романы герое Родион Раскольников җәмгыять кагыйдәләренә каршы бунт күтәрә. Әмма ул да кан түккән өчен җәза бирелергә тиешлеге белән килешә. Гөнаһ йолусыз булмаган кебек, җинаять тә җәзасыз булмый.

Җәза бирүнең гомуми башлангычлары нинди? Җинаять кылуда гаепләнгән кешегә, Җинаять кодексының гомуми бүлеге положениеләрен исәпкә алып, аның тиешле статьясында каралган чикләрдә гадел җәза билгеләнә. Статьяның санкциясе җиңелрәк җәза катыракка таба бара торган итеп корылган (мәсәлән, башта — штраф, аннары — иректән мәхрүм итү). Кылынган җинаять өчен каралган иң каты җәза бары тик

куелган максатларга ирешүне йомшаграк җәза тәэмин итә алмаган очракта гына кулланыла. Җәза билгеләнгәндә җинаятьнең иҗтимагый куркынычлылыгы, характеры һәм дәрәҗәсе, шул исәптән җәзаны җиңеләйтә һәм авырайта торган шартлар, шулай ук билгеләнгән җәзаның хөкем ителүченең төзәтелүенә һәм гаилә тормышы шартларына йогынтысы исәпкә алына.

36 нчы схема

Закон җинаять җәзасының төрләрен билгели. Алар төп (ягъни мөстәкыйль кулланылучы), өстәмә (ягъни төп төргә өстәмә буларак кулланылучы), төп һәм өстәмә (ягъни суд тарафыннан мөстәкыйль яки җәзаның төп төрләренә өстәмә бу-

ларак файдаланылучы) булырга мөмкин. Үлем җәзасы гадәттән тыш һәм шул ук вакытта һәрвакыт бары тик төп җәза чарасы булып исәпләнә. Бу түбәндәге схемадан яхшы күренә.

37 нче схема

Бик борынгы заманнарда ук әле кешеләр җәза куллануның гаделлеге һәм дөреслеге турында уйланганнар.

Борынгылар гадел хөкем алиһәсен хатын-кыз кыяфәтендә сурәтләгәннәр. Кемне хөкем итүен күрмәсен һәм шул рәвешчә объектив булып калсын өчен, аның күзләре бәйләнгән булган. Бер кулында — җәза кылычы, икенчесендә — үлчәү. Үлчәүнең бер тәлинкәсенә, шартлы рәвештә, җаваплылыкны җиңеләйтә, икенчесенә авырайта торган шартлар салынган.

Җиңеләйтүче шартларга түбәндәгеләр керә:

а) очраклы хәлләр аркасында беренче тапкыр зур булмаган җинаять кылу;

б) гаепләнүченең балигъ булмавы;

в) йөклелек;

г) гаепләнүченең кече яшьтәге балалары булу;

д) җинаятьнең авыр тормыш шартлары яисә кызгану аркасында килеп чыгуы;

е) җинаятьнең физик яисә психик мәҗбүр итү нәтиҗәсендә яки матди, хезмәт яисә башка бәйлелек аркасында кылынган булуы;

ж) җинаятьнең зарури саклану хокукы бозылганда, җинаять кылган кешене тотканда, тәвәккәллеккә нигезләнгән чиктән тыш зарурлык шартларында, боерык яисә күрсәтмәне үтәгәндә кылынуы;

з) зыян күрүченең үз-үзен тотышы җинаятькә сәбәп булырлык хаксыз һәм әхлаксыз булуы;

и) гаепне тану, җинаятьне ачуда, җинаятьтә катнашучы башка кешеләрне фаш итүдә һәм җинаять нәтиҗәсендә югалган милекне эзләүдә актив катнашу (Владимир Дальның мәгълүм сүзлегендә тәүбә итү турында түбәндәгеләр әйтелә: «Тәүбә итүдән башка кичерү юк», «Тәүбә дә итте, кире кайтарып кына булмый»). Бу әйтемнәр җинаять кылганнан соң эчкерсез тәүбәнең мәгънәсен бик төгәл ачып бирә;

к) җинаять кылынганнан соң ук зыян күрүчегә медицина һәм башка ярдәм күрсәтү; җинаять нәтиҗәсендә китерелгән мөлкәти һәм әхлакый зыянны үз теләге белән каплау, зыян күрүчегә карата ясалган зыянны төзәтүгә юнәлтелгән башка гамәлләр.

Бу исемлекне тулы дип әйтеп булмый, һәм суд, конкрет эшкә, хөкем ителүченең шәхесенә карап, башка нәрсәләрне дә хәлне җиңеләйтүче дип таный ала. Җәза билгеләгәндә Җинаять кодексы тарафыннан каралмаган шартлар да җиңеләйтүче сыйфатында исәпкә алынырга мөмкин.

Авырайта торган хәлләргә түбәндәгеләр керә:

а) берничә мәртәбә кабатланган җинаять;

б) авыр нәтиҗәләргә китерә торган җинаять;

в) җинаятьне төркем белән, алдан сүз берләшкән төркем белән, оешкан төркем яки җинаятьчел оешма белән кылу;

г) җинаять кылганда аеруча актив роль уйнау;

д) җинаять кылуга катлаулы психик авырудан интегүче яки исерек хәлдәге, шулай ук җинаять җаваплылыгы яшенә җитмәгән кешеләрне тарту;

е) милли, раса, дини нәфрәт яки дошманлык аркасында, башкаларның хаклы гамәлләренә үч итеп, шулай ук башка җинаятьне яшерү яки аны җиңеләйтү максатында җинаять кылу;

ж) хезмәт эшчәнлеген тормышка ашырган яки җәмәгать бурычын үтәгән кешегә яисә аның якыннарына карата җинаять кылу;

з) йөкле хатыннарга, шулай ук кече яшьтәге балаларга, башка яклаучысыз һәм көчсез кешеләргә яисә гаепләнүчегә бәйле булган кешегә карата җинаять кылу;

и) зыян күрүчегә карата аеруча кансызлык, садизм, мәсхәрәләү, газаплау юлы белән җинаять кылу;

к) корал, сугыш кирәк-яраклары, шартлаткыч матдәләр, шартлату яки шуңа охшаш җайланмалар, махсус эшләнгән техник чаралар, агулы һәм радиоактив матдәләр, дару һ. б. химик-фармакологик препаратлар, шулай ук физик яисә психик мәҗбүр итүләр кулланып җинаять кылу;

л) гадәттән тыш хәл, табигый яки башка иҗтимагый бәла-каза, шулай ук массакүләм тәртипсезлек шартларында җинаять кылу;

м) хезмәт хәле яки килешү нигезендә гаепләнүчегә карата күрсәтелгән ышанычтан файдаланып җинаять кылу;

н) хакимият вәкиленең форма киеменнән яки документларыннан файдаланып җинаять кылу.

Әгәр авырайта торган хәлләр кодекстагы махсус бүлекнең махсус статьясы тарафыннан җинаять билгесе сыйфатында карала икән, ул җәза билгеләнгәндә кабат исәпкә алынырга тиеш түгел.

Балигъ булмаганнарга, җинаять кылганда үз-үзен белештермәгәннәргә яисә җинаять кылганнан соң акылы зәгыйфьләнгән кешеләргә карата җәза билгеләү өчен билгеле бер кагыйдәләр кертелгән.

Җинаятькә каршы көрәш законы дәүләтебезнең гуманлылыгы һәм балигъ булмаганнарны иң әүвәл тәрбияви характердагы чаралар белән төзәтергә омтылуы хакында сөйләүче тулы бер чаралар системасын күздә тота. Унсигез яшькә кадәрге кеше зур иҗтимагый куркынычлылык тудырмый торган җинаять кылса, суд аны җинаять җәзасы кулланмыйча гына төзәтергә мөмкин дип тапса, аңа карата тәрбияви характердагы мәҗбүр итү чаралары кулланырга мөмкин. Балигъ булмаган кеше аңа тәрбияви характердагы мәҗбүр итү чарасы куллану турындагы мәсьәләне карау өчен балигъ булмаганнар эшләре буенча комиссиягә җибәрү нигезендә җинаять җаваплылыгыннан азат ителергә мөмкин.

Җинаять эшенең суд тарафыннан каралуы, суд хөкеме һәм җәза билгеләнү һәрвакыт хөкем ителүченең үзе өчен генә түгел, башкалар өчен дә хокукый һәм әхлакый нәтиҗәләргә китерә. Хөкем ителүченең гаиләсе, туганнары, иптәшләре тирән борчылулар кичерә.

Сораулар һәм биремнәр: 1. Җәза чараларын кабат карап чыгыгыз. Аларның кайсылары иң көчле булып тоела? **2.** Агрессив җинаятьләрнең үсүе белән бәйле рәвештә, җәза төрләрен һәм аны билгеләү процессын камилләштерү буенча нинди тәкъдимнәр кертер идегез? **3.** Төзәлмәслек җинаятьчеләр буламы? **4.** Ни өчен үлем җәзасын гадәттән тыш җәза чарасы дип атыйлар? **5.** Тарих дәреслекләреннән файдаланып, «Җәза

әлек һәм хәзер» дигән темага инша языгыз. 6. Колонияне кайвакыт «җинаять фәннәре университеты» дип атыйлар. Мондый чагыштыру дөреслеккә туры киләме? 7. «Автомобильдән саклан!» кинофильмында Юрий Деточкин үзенең уенча жуликларныкы булган автомобильләрне куып алып китә. Аларны сатудан килгән акчаны балалар йортларына күчерә. Җинаять кодексыннан чыгып карaганда, Деточкинның әлеге гамәлен ничек бәяләргә? Аның гамәлләрендә җинаять составы бармы? Деточкинның үз-үзен тотышында җаваплылыкны җиңеләйтә торган нинди шартлар бар?

29. Җинаятьнең кайбер төрләре өчен җинаять җаваплылыгы

Яшүсмерләр тарафыннан иң еш кылына торган җинаятьләрне карап үтик. Статистика буенча бу — урлау, тән җәрәхәте салу, хулиганлык һәм үтерү.

Шәхескә каршы җинаять. Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы Конституцияләре гражданнарның иң мөһим хокукларын һәм ирекләрен, шул исәптән шәхеснең кагылгысызлыгын да беркетәләр. Аларны тормышка ашыру икътисади, сәяси һәм юридик яктан гарантияләнә. Җинаять законы җәмгыятебездәге иң әһәмиятле кыйммәтләрне — гомерне, сәламәтлекне, ирекне, кешелек дәрәҗәсен — җинаятьчел кул сузулардан саклый.

Ни өчен шәхескә каршы җинаятьләр кылына соң? Моның төп сәбәбе тәрбиясезлектә, культура дәрәҗәсенең түбән булуында. Үлем еш кына яшүсмерләрнең шуклыгы, өстән уйлавы, өлкәннәрдән рөхсәтсез алынган утлы коралдан дөрес файдалана белмәүләре нәтиҗәсендә килеп чыга.

Шәхескә каршы эшләнгән иң авыр җинаять — үтерү. Безнең закон һәр кеше гомерен бер төрле саклый.

Колбиләүчелек җәмгыятендә кол әйбер булып исәпләнгән, аны үтергән өчен берниндн дә җәза бирелмәгән. Кол үзенең хуҗасын үтерсә, гаепләне генә түгел, бу хуҗаның барлык колларын да җәзалаганнар. Киев Русеның феодаль хокук җыентыгы «Русская правда»да бай кешене үтергән өчен 80 гривна, ирекле кеше өчен — 40, холоп өчен 5 гривна түләнергә тиеш дип күрсәтелгән.

Үтерү — башка кешене аңлы рәвештә үлемгә дучар итү. Закон авырайта торган хәлләрдәге үтерүне аерым билгели (ике яки аннан да күбрәк кешене үтерү; кешене яки аның якыннарын хезмәт эшчәнлеген тормышка ашыру яки җәмәгать бурычын үтәү белән бәйле рәвештә үтерү; яклаучысыз икәнлеге билгеле булган кешене, шулай ук кешене урлаганда яисә заложник итеп алганда үтерү; йөкле икәнлеге билгеле булган

хатын-кызны үтерү; аерата рәхимсезлек белән үтерү; гомумкуркыныч ысул белән үтерү; төркем белән, алдан килешенгән төркем белән яисә оешкан төркем белән үтерү; файда алу максатыннан яисә ялланып, шулай ук талап, янап, бандитлык кылып үтерү; хулиганлык аркасында үтерү; башка җинаятьне яшерү яки аны җиңеләйтү максаты белән, шулай ук көчләү һәм сексуаль характердагы көч куллану белән бәйле рәвештә үтерү; милли, раса, дини нәфрәт яки дошманлык яисә канлы үч аркасында үтерү; бәлагә таручының әгъзаларыннан һәм тукымаларыннан файдалану максатыннан үтерү; берничә тапкыр үтерү). Мондый җинаять өчен сигез елдан егерме елга кадәр иректән мәхрүм итү яки үлем җәзасы яисә иректән гомерлеккә мәхрүм итү каралган.

Закон тарафыннан кешене янаулар, рәхимсез мөгамәлә яки кешелек дәрәҗәсен даими рәвештә кимсетеп тору юлы белән үз-үзен үтерүгә яисә үз-үзен үтермәкче булуга кадәр китереп җиткергән өчен дә җаваплылык каралган.

Җинаятькә каршы көрәш законы кешенең сәламәтлеген дә җинаятьчел янаулардан саклый. Гомере өчен куркыныч булырлык дәрәҗәдә кеше сәламәтлегенә аңлы рәвештә авыр зыян салган өчен дә җинаять җаваплылыгы каралган.

Газаплау, даими рәвештә кыйнау яки башкача көч куллану хәрәкәтләре ясау белән физик һәм психик газаплануга дучар иткән өчен шулай ук җәза бирелә.

Шикләнү өчен нигез булган очракта, үтерү яки сәламәтлеккә авыр зыян салу белән янаган өчен дә җәза бирелә.

Трансплантацияләү (күчереп кую) өчен кешене органнарын яки тукымаларын бирергә мәҗбүр иткән; үзендә венерик авыру булганлыгын белә торып, аны башка кешегә йоктырган; белә торып башка кешене ВИЧ инфекциясе йоктыру куркынычы астына куйган; закон яисә махсус кагыйдә буенча ярдәм итәргә тиеш булып та, авыруга сәбәпсез ярдәм итмәгән һәм шуның аркасында аның сәламәтлегенә уртача авырлыктагы зыян салган; кече яшьтә, карт, авыру яки көчсез булганлыклары аркасында үз-үзләрен саклый алудан мәхрүм булган кешеләргә, мөмкин булып та яки тиеш булып та, ярдәм итмәгән яки үзе аларны куркыныч хәлгә куйган өчен закон тарафыннан җинаять җаваплылыгы каралган.

Милеккә каршы җинаять. Милеккә хокук гражданлык хокуклары системасында аерым урын алып тора. Ул икътисади мөнәсәбәтләрне көйләүче һәм гражданнарның шәхси иминлеген күрсәтүче булып тора. РФ Конституциясенең 8 статьясында Россия Федерациясендә милекнең хосусый, дәүләт, муниципаль һәм башка формалары бертигез танылa һәм яклана икәнлеге турындагы положение беркетелгән. Җинаятькә каршы көрәш законнарында чит милекне урлаган өчен җаваплылыкның нинди булуы милеккә нинди юл белән кул сузуга бәйле.

Урлауның берничә төрле формасы бар:

урлашу — чит милекне яшертен рәвештә урлау;

талау — чит милекне ачыктан-ачык урлау;

юлбасарлык — чит милекне урлау максатында кешенең гомеренә яки сәламәтлегенә куркыныч тудырырлык көч куллану яки шундый көч куллану юлы белән янап һөҗүм итү;

алдашу — алдау яки ышанычтан явызларча файдалану юлы белән чит милеккә ия булу;

ышанып тапшырылган милекне үзләштерү яки туздыру;

куркытып тартып алу — чит милекне яки милеккә хокукны бирүне яисә мөлкәти характердагы башка гамәлләр кылуны таләп итү.

Җәмәгать куркынычсызлыгына каршы җинаятьләргә Җинаять кодексында махсус бүлек багышланган. Иң куркыныч җинаять — террорлык, ягъни иҗтимагый иминлекне бозу, халыкны куркыту яки хакимият органнары карар кабул иткәндә аларга басым ясау максатында шартлату, яндыру, мөлкәткә зур зыян салу яки кеше тормышына куркыныч тудыра торган башка иҗтимагый куркыныч гамәлләр кылу.

Терроризм актын хәзерләүдә катнашучы кеше, әгәр хакимият органнарын үз вакытында кисәтүе яки башка чаралар белән аны булдырмый калуда булышса һәм әгәр аның кылган гамәлләрендә башка җинаять составы булмаса, закон тарафыннан җинаять җаваплылыгыннан азат ителә.

Бу бүлектәге җинаятьләргә шулай ук заложниклар алу, террорлык акты турында белә торып ялган хәбәр җиткерү, законсыз кораллы төркем оештыру яки анда катнашу, бандитлык, җинаятьчел берләшмә оештыру, хулиганлык, вандаллык, законсыз төстә коралга, сугыш кирәк-яракларына, шартлаткыч матдәләргә, шартлату җайланмаларына ия булу, аларны тапшыру, сату, саклау, ташу, йөртү, законсыз корал ясау, утлы корал саклау, корал, сугыш кирәк-яраклары, шартлаткыч матдәләр һәм шартлату җайланмалары урлау яисә талап алу, юлбасарлык итү керә.

Сораулар һәм биремнәр: 1. Урлауның, үтерүнең иҗтимагый куркынычсызлыгы нидә? 2. Яңа Җинаять кодексында кайсысы өстенрәк: дәүләт мәнфәгатьләреме — шәхси мәнфәгатьләр, хокук саклау органнары эшенең уңайлылыгы, җәмгыять мәнфәгатьләре, гомумкешелек мәнфәгатьләреме?

30. Җинаятьләр ни өчен кылына?

Бу гадәти дәрес түгел. Сез законнар чыгаручы ролендә кересез. Ни өченме? Хокук бозуларны булдырмау, җинаятьләрне кисәтү, җинаять кылган өчен җәза бирү буенча шактый күп закон кабул ителгән һәм гамәлгә кертелгән. Әмма әллә законнар уйланып җитмәгән, әллә нәтиҗәле файдаланылмый — җина-

ятьчелек сакланып кала бирә. Кыскача әйткәндә, закон чыгаручыларга ярдәм кирәк.

Әлеге параграфтагы материалны игътибар белән укыгыз, ул сезгә закон проектын төзергә ярдәм итәр. Аны ничек эшләргә? Моның өчен закон текстында түбәндәге состав өлешләр булырга тиешлеген истә тотарга кирәк:

1. Преамбула — кереш бүлек. Анда әлеге законның зарурлыгы, аның максатлары аңлатыла.

2. Закон положениеләрен үз эченә алган төп бүлек. Ул аерым статьялардан тора. Алар зур күләмле һәм күп булырга тиеш түгел. Әмма аларны яхшылап уйларга, үтәлергә тиешле положениеләрне дөрес тәгъбирләргә кирәк. Җинаятьчелекнең сәбәпләре нәрсәдә? Аны бетерергә мөмкинме? Моның өчен дәүләт, җәмгыять, һәрберебез нәрсә эшләргә тиеш? Бу өлкәдә сез нинди дә булса конкрет эш күрсәтергә әзерме?

3. Бу бүлектә әлеге законны бозган өчен җаваплылык дәрәҗәсе тәгъбирләнә.

Әзерләнгән документ кыска, әмма саллы булырга тиеш. Үз проектыгызны җитди итеп, дәлилләр белән якларга тырышыгыз.

Сез дәрестә фикер алышу барышына җитәкчелек итү өчен закон чыгаручы палатаның спикерын (җитәкчесен) һәм закон проектының соңгы вариантын төзү өчен редакция комиссиясен сайлыйсыз. Аннары һәркайсыгыз өч минут эчендә өлкәннәр һәм яшүсмерләр тарафыннан кылына торган җинаятьләрнең нигезле сәбәпләрен әйтеп бирергә тиеш. Җәмгыятьнең яшүсмерләр җинаятенә ни өчен аерым игътибар бирергә тиешлеге хакында уйланыгыз. Төрле караштагы авторларны ахырга кадәр тыңлап бетерегез. Сораулар бирергә, нәрсәне дә булса ачыкларга хакыгыз бар.

Закон проекты турында фикер алышканда параграф ахырында бирелгән сораулардан файдаланыгыз. Алар сезгә закон чыгару эшендә тиешле юнәлеш сайларга ярдәм итәр.

Редакцияләү комиссиясе җавапларны, системага салып, язып барырга тиеш. Соңыннан хокук бозуларга профилактика ясау турында закон проектын төзергә тырышыгыз. Киләсе дәрестә редакцияләү комиссиясе сезгә проектны игълан итәр, һәм сез аңа бергәләп бәя куярга тырышыгыз.

Әйдәгез, эшкә тотыныйк!

* * *

Һәр социаль күренеш кебек үк, җинаятьнең дә үз сәбәпләре һәм закончалыклары бар. Аларны махсус юридик фән өйрәнә. Җинаятьнең сәбәпләрен һәм шартларын өйрәнүче, аны булдырмау белән шөгыльләнүче фән **криминология** дип атала (латинчадан: criminus — җинаять, logos — тәгълимат).

Элек җинаятьчелекнең сәбәпләре турындагы сорауга бер төрле генә җавап биргәннәр: җинаять кеше аңында сакланып калган искелек калдыклары, капиталистик Көнбатыш йогынтысы аркасында кылына. Хәзер мондый гадиләштереп аңлату ышандыра алмый, чөнки бу проблема шактый катлаулы.

Җәмгыятьтә җинаятьчелекнең сәбәпләре һәм шартлары бик күп төрле хәлләрнең тулы җыелмасыннан барлыкка килә. Хокук бозуларның сәбәпләре — җәмгыять тормышындагы җитешсезлекләрдә һәм кешенең үзенең камил булмавында. Хокук бозуларга китерә торган сәбәпләр арасында иң әүвәл икътисади, сәяси, социаль, әхлакый сәбәпләрне атарга кирәк. Алар һәртөрле явыз ният, урлау, коррупция, ришвәтчелек, кеше гомеренә һәм сәламәтлегенә төрлечә янау һ. б. лар өчен туендыручы мохит булып тора.

Җинаятьләрнең объектив сәбәпләре бар. Җинаятьчелек — җәмгыятьнең сәламәт булмавы билгесе. Җәмгыять кимчелекле икән, анда бәхетсезләр, яшәүләренең мәгънәсен күрмәүчеләр күп була. Балигъ булмаганнарның җинаятьчелеген беренче чиратта тышкы социаль мохитнең йогынтысы, шулай ук яшүсмернең тормыштагы төрле уңышсызлыкларга реакциясен билгеле торган шәхси үзенчәлекләре белән аңлатырга була.

Икътисади сәбәпләр. Җинаятьчелекнең сәбәпләре булып иң әүвәл тулаем җәмгыятьнең икътисади халәте, шулай ук һәр аерым җинаятьченең матди хәле исәпләнә. Кешеләрне җинаятькә, мәсәлән, эшсезлек, эш хакының түбән булуы, бәяләрнең үсүе һ. б. кебек социаль күренешләр этәрә. Барлык бу иҗтимагый проблемаларны дәүләт хәл итәргә тиеш.

Сәяси сәбәпләр. Демократик үзгәртеп коруларны һәммә нәрсә рөхсәт ителгән дип ялгыш аңлау, байлык культы, комсызлык, иҗтимагый мораль һәм әхлак нормаларын санга сукмау, хокукый нигилизм шулай ук җинаятьчелек сәбәпләренең берсе булып исәпләнә.

Россия белән СНГ илләре арасындагы чикнең ачык булуы да җинаятьчелек артуга күпмедер дәрәҗәдә ярдәм итә; «гастролерлар» дип йөртелә торган җинаятьчеләр корал, сугыш кирәк-яраклары, наркотиклар алып керәләр, сәнгать әсәрләре, дефицит чимал, киң куллану товарлары кебек милли байлыкларны алып чыгалар.

Социаль сәбәпләр. Күпчелек очракта хокук бозучылар рәтенә коллектив белән начар мөнәсәбәттә булып, мәктәп мохитендә үз урыннарын таба алмаган укучылар эләгә. Классташлары арасында ихтирам казана алмыйча аерылып калган яшүсмер класстан һәм мәктәптән читтәге компанияләргә тартыла, урам төркемнәренә кушыла башлый. Урам төркеме яшүсмер өчен аралашу һәм бергәләп эш итү ихтыяҗын канәгатьләндерү ысулы һәм формасы булып тора. Мондый төркемнәр гайре табигый мәнфәгатьләр һәм иҗтимагый куркыныч максатлар җирлегендә барлыкка килә, еш кына нормаль

коллективка каршы куела, яшүсмергә кире йогынты ясаучы һәм шактый дәрәҗәдә аның үз-үзен тотышын билгеләүче микромохит тәшкил итә.

Тәҗрибәсез яшьләр күңелен бигрәк тә комсызлык, акылны җуяр дәрәҗәдә күп акча, мал, зиннәтле тормыш артыннан куу кебек массакүләм тормыш мисаллары агулый. Галимнәр исәпләп чыгарганнар: әгәр җәмгыять байлар һәм ярлылар керемендә 20:1 чагыштырмасындагы аермага юл куя икән (цивилизацияле илләрдә бу чагыштырма 6:1), шунда ук заманның урлау, талау юлы белән бу аерманы аз булса да киметә торган «робин гуд»лары пәйда була.

Кызганычка каршы, төрле хокук бозулар һәм аларны тудыручы сәбәпләр белән беренче чиратта көрәшергә тиешле хокук саклау органнары үз бурычларын тиешенчә үти алмыйлар. Хөкем ителүчеләр җәза срокларын үти торган учреждениеләр системасы да үзенә тиешлесен эшләп җиткерми — алардан еш кына начар гадәтләрне ныграк үзләштергән яшүсмерләр чыга.

Язучы Л. Габышевның «Одлян, или Воздух свободы» дигән повесте бар. Балалар колониясе турындагы бу әсәр үзенең документаль дөреслеге белән тетрәндерә. Автор балигъ булмаганнар өчен төзәтү учреждениеләре шартларында шәхеснең юк ителүе турында яза. Кешеләр колониядә иң кыйммәтле нәрсәләрен югалталар — алар кеше булудан туктыйлар.

Одлян повесть героен юлдан яздыра һәм әхлакый гарипләндерә. Яшүсмер җәмгыять өчен генә түгел, үзе өчен дә юкка чыга (бусы — иң куркынычы). Ул Одлян атмосферасында иркен сулыш ала һәм... бу һаваны ирекле дип таба. Күз алдыбызда яшүсмер харап була. Повесть өйрәтә дә, кисәтә дә. Бу әсәрне һичшиксез укырга тырышыгыз.

Соңгы елларда көчләү һәм секс культына, эчкечелек, наркомания һәм фахишәлеккә дан җырлаган кайбер массакүләм информация чаралары да билгеле бер дәрәҗәдә кире роль уйный.

Әхлакый сәбәпләр. Нәрсә генә булса да, иң мөһиме — кеше намуссыз, комсыз, ачулы, үчле, көнче, рухи яктан мөстәкыйль түгел икән, җинаятькә барырга мөмкин. Бу — җинаятьләрнең субъектив сәбәпләре. Без үзебезнең кәефебез: таләпләребез, бер-беребезгә, гаиләбезгә, балаларыбызга, җәмәгать вазифаларына, законнарга, киләчәгебезгә мөнәсәбәтебез белән җәмгыятьнең характерын, андагы әхлакый климатны билгелибез. Әгәр начар фикерле, пычрак ниятле кешеләр күп була икән, җәмгыять криминаллаша, ягъни җинаятьчел төсмер өстенлек ала.

Сүз дә юк, биредә шәхеснең гомуми белем дәрәҗәсе, гомуми һәм хокукый культурасы, шулай ук гаиләдәге һәм әйләнәтирәдәге микромохит тә билгеле бер роль уйный. Шәхси тормыш һәм тәрбиянең үзенчәлекле шартлары кайчакта караш-

лар һәм гадәтләр формалашу барышына тискәре йогынты ясый. Әгәр бу шартларда җәмгыятькә каршы карашлар һәм гадәтләр урнаша башлый икән, аерым шәхесләр билгеле бер очракларда закон тарафыннан тыелган гамәлләр кыла башлыйлар.

Тышкы мохитнең кире факторлары һәм шәхеснең үзара тәэсир итешүе — балигъ булмаганнарның җинаять кылу сәбәбе шул. Күп кенә тикшеренүләр хокук бозучы яшүсмерләрнең танып-белү һәм иҗтимагый мәнфәгатьләре дәрәҗәсе түбән булуны раслый. Мондый яшүсмерләрнең күпчелегендә ялкаулык, башбаштаклык, җавапсызлык, кемнедер сукырларча кабатларга омтылу, агрессивлык һ. б. шундый кире сыйфатлар өстенлек итә.

Җинаять кылган кешеләрне тикшерү түбәндәге закончалыкларны ачыкларга мөмкинлек бирде:

1. Җинаять кылган яшүсмернең хокукый аңы, кагыйдә буларак, гамәлдәге иҗтимагый хокукый аң белән туры килми, хокукый нормаларга каршы килә.

2. Мондый яшүсмер үзе бозган иҗтимагый мөнәсәбәтләрне яклый торган конкрет хокукый норманы яисә нормалар төркемен кире кага.

3. Кайбер очракларда яшүсмер үзе бозган (һәм шуның өчен хөкем ителгән) хокукый норманың дөреслеген һәм гаделлеген таный, ләкин үзенә карата чыгарылган хөкем карарын гадел түгел дип исәпли (гадәттә — артык каты дип).

Күпсанлы һәм күпьеллык күзәтүләр, әгәр гаиләдә балалар урлаша икән, моңа гаилә гаепле икәнлеген бик ачык күрсәтә. Гаиләдәге сәламәт булмаган рухи шартлар, ата-аналардагы комсызлык, саранлык, кешеләргә карата битарафлык, башкалар мәнфәгате белән исәпләшергә теләмәү яшүсмерләрдә безнең чынбарлык турында ялган күзаллау формалаштыра, аларда җәмгыятькә каршы гадәтләр барлыкка килүенә этәрә.

Кешене, дөрестән дә, мохит формалаштыра. Әмма барлык гамәлләрне, шул исәптән җинаятьләрне дә, кеше үзе кыла. Мохитнең бернинди үзенчәлекләре дә җинаятьне аклый алмый. Ахыр чиктә кеше үзе кылган җинаять өчен үзе гаепле була. Шуңа күрә закон җәмгыятьне дә, гаиләне дә, мәктәпне дә түгел, ә нәкъ менә кешенең үзен хөкем итә. Хокукны, аның хәрефләрен генә түгел, рухын да начар белгән, законны хөрмәт итмәгән, гамәлләрен әхлак һәм хокук нормалары белән үлчәргә өйрәнмәгән кеше җинаятьне ансатрак кыла.

Кайбер яшь хокук бозучылар, суд эскәмиясенә эләгеп, бар гаепләрен: «Мине начар тәрбияләделәр, шуңа күрә шундый булдым», — дип, башкалар өстенә аударырга тырышалар. Үз гаепләре, кылган гамәлләре өчен шәхси җаваплылыкны аңлаулары турында бер сүз дә әйтмиләр. Яшүсмерләргә эчке яктан да, тышкы яктан да кире йогынты көчле, гаиләдәге тормыш шартлары түзеп тормаслык булырга мөмкин. Әмма ахыр чиктә үзен ничек тотарга кирәклеген яшүсмер үзе сайлый.

Беркемнең дә кылган гамәлләре өчен үз өстеннән җаваплылыкны төшерергә хакы юк.

Беренче карашка парадоксаль булып тоелган тагын бер сәбәп бар, бу — зыян күрүченең үз-үзен тотышы, күбесенчә, аның җавапсызлыгы. Гүя корбан җинаятьчене җинаять кылырга үзе этәрә. Мәсәлән, бер кыз, әллә ни таныш булмаган кешеләр чакыруына күнеп, алар белән ял итәргә барырга ризалык бирде һәм яңа «дуслары»ның һөҗүменә дучар булды, ди. Бу, билгеле, законсыз гамәлләрне акламый, зыян күрүченең үз-үзен тотышы никадәр генә җавапсыз булса да, җинаятьче барыбер закон каршында җавап бирергә тиеш.

Җинаятьчелек, билгеле, мәңгелек түгел. Төзәтеп булмаслык җинаятьчеләр дә юк. Изгелек, мәрхәмәтлелек теләсә нинди җанны сәламәтләндерергә сәләтле. Һәр кеше үзенең яшәешенең югары мәгънәсенә ия булырга, үзенең кирәклеген тоярга сәләтле.

Бертуган Вайнерларның «Эра милосердия» дигән романындагы карт акыл иясе әхлаклылык һәм хокук турында болай ди: «Минем тирәнтен ышануымча, безнең илдә җинаятьчелекне җәза органнары түгел, ә тормышыбызның табигый агышы, икътисади үсеше тулысынча җиңә алачак. Ә иң мөһиме — җәмгыятебезнең әхлагы, халкыбызның шәфкатьлелеге һәм кешелеклелеге... Шәфкатьлелек үзара мөнәсәбәтләрнең без һәрвакыт омтыла торган формасы...»

Әйе, шәфкатьлелек һәрвакытта да, һәр чорда да зарур. Килер бер көн, бүген без урта гасырдагы вәхшиләрчә җәзалаулар турында китаплардан гына укып белгән кебек, кешеләр җинаятьчелек турында тарих китапларыннан гына укып белерләр.

Җинаятьчелекне бетерүдә әйләнә-тирәдәгеләрнең гаепле кешегә битараф булмавы, аны вакытында туктата белүләре дә зур роль уйный. В. Гюгоның «Отверженные» романы герое Жан Вальжанны искә төшерегез.

Элеккеге каторжан Жан Вальжан бөтен дөньяга ачулы була. Юк кына гаебе өчен аны озак срокка каторгага сөрәләр. Ул беркемгә дә ышанмый һәм, үзенә шундый начарлык эшләгән җәмгыятькә үч итеп, әллә нинди җинаятьләр кылырга да әзер була. Каторгадан кайтканда аны Мириель атлы рухани төн кунарга кертә. Иртән иртүк Вальжан, хуҗаның көмеш савыт-сабасын эләктереп, әлеге кунакчыл йорттан качып китә. Аны тоталар. Урлаганын раслатыр өчен, рухани янына алып киләләр. Ә Мириель ни эшли? «Мин бу приборларны сезгә бүләк иттем, — ди ул каторжанга полицейскийлар алдында. — Сез әле тагын шәмдәлләрне онытып калдыргансыз». Һәм кыйммәтле әйберләрне җинаятьчегә суза. Жан Вальжан өчен болар барысы да ниндидер гаҗәеп шифалы төш кебек була. Ул соң чиккә җитеп дулкынланган хәлдә китеп бара. Һәм аның җаны әлеге руханиның шәфкатьле һәм акыллы гамәленнән соң савыгып киткәндәй була. Җинаятьче юкка чыга, намуслы, игелекле, көчле һәм фидакарь кеше кабат туа.

Әйләнә-тирәдәгеләрнең җиңел генә законга каршы баруына карап кына законга сыймый торган гамәлләр кылырга ярамый. Лев Толстой: «Иң зур бәхетсезлекләргә илтүче иң гадәти әгъва — «бөтенесе шулай эшли» дигән сүз», — дип, бик дөрес әйткән.

Сораулар һәм биремнәр: 1. Җинаятьчелек котылгысызмы? Закон көче белән генә җинаятьчелекне киметеп буламы? **2.** Җинаятьләрнең объектив сәбәпләре нинди? Ә субъектив сәбәпләре? «Закон булмаса, җинаятьче дә булмас иде» дигән рус әйтеме хаклымы? **3.** Өч малай «Җинаятькә каршы көрәш законы ни өчен кирәк?» дигән темага фикер алышалар.

Юра: Моның нәрсәсе аңлашылмый? Кешеләр урлашмасын, таламасын, башка җинаятьләр кылмасын өчен кирәк.

Вася (скептикларча): Әйе, шулай. Әмма үтерәләр дә, урлыйлар да, башка җинаятьләр дә эшлиләр. Җинаять законыннан беркем дә курыкмый.

Игорь (ышанычлы итеп): Бөтенесенә җинаять законы үзе гаепле. Тикшерүчеләр, судьялар җинаятьчеләр белән артык йомшак маташалар. Гадирәк кирәк: урласа — кулын кис, үтерсә — бөтен халык алдында үзен асып куй. Менә шуннан соң караклар да, үтерүчеләр дә булмас. Бернинди җинаять законы да кирәк булмаячак.

Бәхәсләшүчеләрнең кайсысы хаклы? Ни өчен сез аларның берсе генә хаклы дип уйлыйсыз, бәлки, һәрберсендә дә бераз дөреслек бардыр? **4.** «Энәдән башлаган кеше сыер урлауга кадәр барып җитә» дигән Корея мәкалендә, сезнеңчә, җинаятьчелекнең субъектив сәбәпләре ничек чагыла?

Рөстәм Х. карак-рецидивист була. Өченче срогын тутырып колониядән чыккач, тагын эләгә. Әмма суд аны, җитәрлек дәлилләр булмау сәбәпле, гаепсез дип таба. Суд залыннан чыккач, Рөстәм моннан соң беркайчан да кеше мөлкәтенә кагылмаска ант итә. Шуннан соң намуслы кешегә әйләнә. Рөстәмнең аңындагы һәм үз-үзен тотышындагы үзгәрешнең сәбәбен сез ничек аңлатыр идегез? Уйлануларыгызда Жан-Жак Руссоның «Син явызлыкның сәбәбен эзлисең. Ул бары тик синең үзеңдә» дигән сүзләрен файдаланыгыз. **5.** Түбәндәге җинаять сәбәпләренең кайсы объектив, кайсы субъектив икәнлеген билгеләгез:

— гаиләнең хәерчелеге;
— кешенең белем дәрәҗәсе түбән булу;
— телевизор экраннарындагы порнография һәм көчләү күренешләре;
— дәүләтнең мәгарифкә җитәрлек акча бирмәве;
— кешенең ачулы булуы;
— фәнни һәм фәнни-популяр китаплар чыгаруның кимүе;
— супермен булу теләге;
— модалы һәм матур киенергә омтылу.

6. Нинди характер сыйфатлары кешене җинаятькә этәрергә мөмкин: кызып китүчәнлек, үчлелек, кыюлык, үсүзлелек, дуслык тойгысына ия булу, юл куючанлык, мәкерлелек, буйсынмаучанлык, тиз ышанучанлык, кискенлек? Француз язучысы һәм философы Ф. Вольтер (1694—1778) «Көчсезләр генә җинаятькә бара, көчлеләргә һәм бәхетлеләргә ул кирәк түгел» дию белән хаклымы?

«Тәүбә иткән гөнаһ иясе» кем ул? Ул мәрхәмәткә лаекмы?

31. Хезмәт һәм закон

Хезмәт хокукы чыганаклары. Хезмәткә хокук кеше һәм гражданның төп хокукларыннан берсе булып исәпләнә. Хезмәт хокукы хезмәт мөнәсәбәтләрен көйләү өчен барлыкка килгән иде. Безнең илдә хезмәт хокукы турындагы законнарның төп документы булып 1971 елның 9 декабрендә кабул ителгән Хезмәт турындагы законнар Кодексы (КЗоТ) тора. Ул, үз уставлары белән көйләнә торган колхоз һәм кооператив әгъзалары хезмәтен исәпкә алмаганда, барлык хезмәткәрләрнең хезмәт мөнәсәбәтләрен көйли. Хезмәт хокукы чыганакларына шулай ук РФ Президенты Указларын, ТР Президенты Указларын, РФ һәм ТР хөкүмәтләре карарларын һәм кайбер башка актларны кертергә мөмкин.

* * *

Җитештерү кимү, эшсезлек, тормыш дәрәҗәсе түбәнәю шартларында яшь кешегә тормышта үз урынын табу кыен. Менә ни өчен балигъ булмаганнарның хезмәткә хокукын яклау турындагы мәсьәлә бүген аеруча мөһим. Һәм шуңа күрә дә аларның хокуклар турында белүе гаять әһәмиятле. Балалар хезмәте проблемасы күп илләрдә кискен төс алды. Дөньяда 10 яшьтән 14 яшькәчә булган 80 миллионлап бала эшли, һәм аларның хезмәте авыр, эш көне озын, бу исә балаларның нормаль үсешенә комачаулый. Безнең илдә хосусый предприятиеләр, гаилә фирмалары, фермер хуҗалыклары торгызылу белән бәйле рәвештә мондый куркыныч шулай ук арта барачак.

Яшьләр хезмәте һәркайда файдаланыла. Бүгенге көндә төрле сәбәпләр аркасында балигъ булмаганнар нигездә икътисадның хосусый секторында эшли. Нәкъ менә шуңа күрә дә, яшь буенча эксплуатацияләү һәм дискриминацияләү булмасын өчен, хезмәт законнары кагыйдәләре милекнең барлык формасы өчен дә мәҗбүри икәнлеген белү зарур. Закон буенча эшкә яллану һәм азат ителү, хезмәт, ял шартлары һ. б. җитештерүнең дәүләт, кооператив, җәмәгать һәм хосусый секторларында сакланырга тиеш.

Хезмәт хокукының күбесенчә балигъ булмаганнарга кагыла торган кайбер төшенчәләренә генә тукталып үтик.

Иң әүвәл **хезмәт шартнамәсен** (яки контракт) карыйк. Бу — хезмәт иясе һәм предприятие, учреждение администрациясе, ягъни эш бирүче арасында хезмәткәрнең әлеге предприятиегә билгеле бер хезмәт вазифасын яки билгеле бер төрдәге эшне башкару өчен кабул ителүе турындагы килешү.

Гражданнар 16 яшьтән эшкә яллана, хезмәт шартнамәләре төзи алалар. Профсоюз органы рөхсәте белән, 15 яше тул-

ган үсмерләр дә эшкә кабул ителергә мөмкин. Аерым очракларда, укудан тыш вакытларда, 14 яшьлек балалар да җиңел хезмәткә тартыла алалар. Моның өчен ата-ананың берсенең яисә аларны алыштыручының ризалыгы кирәк, һәм бу хезмәт яшүсмернең сәламәтлегенә зарар китермәскә һәм уку процессына комачауламаска тиеш.

16 яшькә җиткән балигъ булмаган яшүсмер, әгәр ул хезмәт шартнамәсе яки контракты буенча эшли икән, тулысынча хокукый сәләтле булып исәпләнергә мөмкин. Хезмәткә кабул ителгән балигъ булмаганнар хезмәт хокукы мөнәсәбәтләрендә балигъ булганнарга тигезләшәләр, ә хезмәтне саклау өлкәсендә, эш вакыты, чираттагы ялга чыгу һәм башка мәсьәләләрдә законда каралган өстенлекләрдән файдаланалар.

18 яшькә җитмәгән барлык кешеләр бары тик медицина тикшеренүеннән соң гына эшкә кабул ителәләр. Моннан башка эш бирүченең алар белән хезмәт шартнамәсе төзергә хокукы юк.

Хезмәт шартнамәсе бары тик язма формада гына төзелә. Яшүсмер оешма җитәкчесе, предприятие хуҗасы яки хосусый эш бирүче исеменә гариза яза, анда эш төрен, срокны һ. б. ны күрсәтә. Эш бирүче, үз чиратында, эшкә алу турында күрсәтмә яки боерык бирә, анда хезмәт шартларын күрсәтә һәм аның белән яшүсмерне таныштыра. Әгәр язмача хезмәт шартнамәсе булмаган килеш кеше чынлыкта эш бирүче ризалыгы белән эшли башлаган икән, ул очракта хезмәт шартнамәсе эшли башлаган көннән исәпләнә.

Балигъ булмаганнарны эшкә алганда сынау срогы билгеләргә, укып бетергәннән соң ике ел дәвамында профессиясенә һәм квалификациясенә туры килми торган башка эшкә күчерергә ярамый.

Хезмәт шартнамәсе билгеле бер срокка яисә чикләнмәгән срокка төзелергә мөмкин.

Билгеле бер срокка төзелгән хезмәт шартнамәсенең вакыты беткәч, ул я озынайтыла, я туктатыла, һәм хезмәткәр эшеннән азат ителә. Шартнамәнең иң зур срогы — 5 ел.

Чикләнмәгән срокка төзелгән хезмәт шартнамәсенең вакыты билгеләнми. Шартнамә хезмәткәр тарафыннан теләсә кайсы вакытта өзелергә мөмкин, ләкин бу турыда администрацияне ул кимендә ике атна алдан кисәтергә тиеш.

Администрация дә, законда турыдан-туры күрсәтелгән сәбәпләр белән генә, чикләнмәгән сроктагы хезмәт шартнамәсен өзәргә мөмкин. Андый сәбәпләрнең берничәсен санап үтик: хезмәткәрләрнең саны яки штаты кыскартылу, эш урынына туры килмәү, хезмәт дисциплинасын даими (ел дәвамында бер мәртәбәдән артык) бозу, прогул, ягъни эш көне дәвамында өч сәгатьтән артык эштә булмау. Кайбер очракларда, мәсәлән, штатларны кыскартканда, профсоюз комитетының эштән азат итү өчен алдан ризалыгы таләп ителә. КЗоТта хезмәт шарт-

намәсен өзүнең барлык нигезләре һәм аларның юридик нәтиҗәләре күрсәтелгән. Бу мәсьәләләргә КЗоТның 29—37 статьялары багышланган.

18 яше тулмаган хезмәткәрләр өчен кыскартылган эш вакыты каралган: 16—18 яшьтәгеләр өчен ул атнага 36 сәгатьтән (көнгә 6 сәгать), 15—16 яшьтәгеләр, шулай ук 14—15 яшьлек укучылар (каникул чорында эшләүчеләр) өчен атнага 24 сәгатьтән (көнгә 4 сәгать) артмаска тиеш.

Әгәр укучылар каникулда түгел, ә дәрестән соң эшлиләр икән, эш вакыты икенче төрле билгеләнә: 16—18 яшьтәгеләр өчен атнага 18 сәгать (көнгә 3 сәгать), 14—16 яшьтәгеләр өчен атнага 12 сәгать (көнгә 2 сәгать).

18 яшьләре тулмаган хезмәткәрләр төнге эшкә, эш сәгатеннән тыш һәм ял көннәрендә эшкә (шул исәптән төнге һәм ял көннәрендәге дежур торуларга) тартылырга тиеш түгел.

Балигъ булмаганнарга чираттагы еллык ял җәй көне бер айга бирелергә тиеш. Ялның вакытын яшүсмернең үз теләге белән генә үзгәртергә мөмкин.

Унсигез яше тулмаган хезмәткәрне авыр эшләргә һәм җир асты эшләренә, зарарлы хезмәткә, шулай ук вахта ысулындагы эшкә, берьюлы ике эшкә, спиртлы эчемлекләр җитештерү, саклау һәм сату белән бәйле эшкә тарту тыела. Балигъ булмаганнар белән тулы матди җавапылык турында язма шартнамәләр төзү тыела.

Эш бирүче мәсьәләне балигъ булмаганнар эшләре буенча район (шәһәр) комиссиясе белән килештереп кенә, үз инициативасы белән яшүсмерне эштән азат итә ала.

Әгәр балигъ булмаган яшүсмер белән эш бирүче арасында, мәсәлән, хезмәт хакын, премияне дөрес исәпләмәү, җәйге ял озынлыгын дөрес билгеләмәү һ. б. турында бәхәс чыкса, ни эшләргә? Бәхәсләрне хәл итү өчен предприятиедә хезмәт бәхәсләре буенча комиссия була. Ул күпчелек хезмәт бәхәсләрен хәл итүдә беренче инстанция булып тора. Әгәр яшүсмер комиссия карары белән канәгать түгел икән, ул судка мөрәҗәгать итә ала, суд исә аның администрациягә булган дәгъвасын тикшерә. Комиссияне читләтеп үтеп, хезмәткәр законсыз эштән чыгарулары турындагы шикаять белән турыдан-туры судка мөрәҗәгать итә ала.

Сораулар һәм биремнәр: 1. КЗоТ кагыйдәләре барлык җирдә дә кулланыламы? 2. Эш бирүче балигъ булмаганнарны эшкә алганда нинди шартларны үтәргә тиеш? 3. 18 яше тулмаган хезмәткәр өчен эш вакытының озынлыгы күпме? 4. Балигъ булмаганнар өчен эшләү нормасы, эш вакытының озынлыгы һәм хезмәткә түләү нәрсәгә бәйле булырга тиеш? 5. Балигъ булмаганнарның хезмәтеннән нинди эшләрдә файдалану тыела?

32. Үз хокукларыңны ничек якларга

Кешенең хокуклары һәм ирекләрен яклау белән турыдан-туры шөгыльләнүче органнар арасында суд аерым урын алып тора. Чынлыкта гражданнарның төп хокукларын һәм ирекләрен саклау һәр кешегә эшне суд тарафыннан гадел һәм ачык тикшерү мөмкинлеге бирүдән башка була алмый. Теләсә кайсы органның һәм урындагы кешенең теләсә нинди гамәлләре өстеннән Россия Федерациясенең «Гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен бозучы гамәлләр һәм карарларга шикаять белдерү турында»гы Законы буенча судка шикаять бирергә мөмкин. Судка унсигез яше тулган яки шушы яшькә җиткәнче хокукый сәләткә ия булган барлык гражданнар да мөрәҗәгать итә ала. Балигъ булмаганнарның хокукларын яклау мәсьәләләре буенча аларның әти-әниләре, уллыкка алучылар, опекуннар, попечительләр мөрәҗәгать итә. Гражданның теләге буенча судка шикаять аның яшәү урыны, яисә урындагы кеше, дәүләт хезмәткәре, орган яки берләшмә урыны буенча бирелә.

Судка мөрәҗәгать иткәндә закон куйган кагыйдәне үтәргә, билгеле бер форма буенча гариза язарга кирәк. Гаризада шулай ук кулланылырга тиешле законга сылтама һәм яклау ысулы турындагы үтенеч булырга тиеш.

Закон үтәлешен тикшерүче прокуратураның эшчәнлеге шәхеснең хокукларын һәм ирекләрен яклауның әһәмиятле гаранты булып хезмәт итә. Прокуратурага һәркем мөрәҗәгать итә ала. Граждан прокурорга еш кына хакимият һәм дәүләт идарәсе органнары вәкилләренең, предприятие, учреждение, оешма администрациясенең закон бозуы аркасында мөрәҗәгать итә. Шул ук вакытта, әгәр ул суд белән үз хокукларын яклау максатында бәйләнешкә керсә, прокуратурада башка кешеләрнең хокукларын, дәүләт мәнфәгатьләрен кысу турында, шулай ук, кемгә каршы юнәлтелгән булуына карамыйча, кылынган җинаять турында хәбәр итәргә мөмкин.

«Россия Федерациясе прокуратурасы турында»гы закон буенча (21—24 статьялар) прокурор законга каршы килә торган актларга ризасызлык белдерә яисә гражданның хокукларын яки закон тарафыннан яклана торган мәнфәгатьләрен яклау өчен судка мөрәҗәгать итә; закон бозуларны, шул исәптән хокукларны һәм ирекләрне бозуларны бетерү турында тәкъдим кертә; кирәк очракта җинаять эше кузгату яки административ хокук бозу буенча эш кузгату турында нигезле карар чыгара.

Закон буенча прокурорга нинди дә булса төгәл билгеләнгән мөрәҗәгать итү формасы юк. Гариза яисә шикаять ирекле

формада төзелә, анда закон бозуның асылы сурәтләнә (законның конкрет нормаларына таянмаска да мөмкин — анысын юрист үзе карый), закон бозучы кеше яки закон бозылган оешма турында мәгълүмат бирелә. Гариза бирүче үзенең фамилиясе, адресы, телефоны турындагы мәгълүматларны күрсәтергә тиеш, чөнки кирәк очракта прокурор әлеге гражданнан өстәмә мәгълүмат ала, мөрәҗәгатьне карау нәтиҗәләре турында хәбәр итә ала. Гариза предприятие, учреждение, оешма урнашкан яки закон бозучы кеше яшәгән район прокуроры исеменә языла. Ул прокурорга почта аша җибәрелергә, шулай ук шәхси кабул итү урынында тапшырылырга, турыдан-туры прокуратура канцеляриясенә бирелергә мөмкин һәм мәҗбүри тәртиптә теркәлергә тиеш.

Прокуратура органына телдән шикаять белән дә мөрәҗәгать итәргә мөмкин. Әйтик, Татарстан Республикасы прокуратурасында гражданнар көн саен 9 сәгатьтән 17 сәгатькә кадәр кабул ителә (якшәмбе һәм бәйрәм көннәреннән кала). Гражданнарны кабул итү мөрәҗәгатьнең характерын һәм әчтәлеген исәпкә алып оештырыла, кабул итү хезмәткәрләре гариза бирүчегә тиешле аңлатмаларны бирә, шикаятьләрне һәм гаризаларны кабул итә яки йомыш белән килүчене республика аппаратының тиешле урындагы кешесенә җибәрә. Республика прокуроры, аның урынбасарлары, идарә һәм бүлек начальниклары, кагыйдә буларак, гражданнарны район һәм шәһәр прокуратурасында чыгарылган карарларга карата язылган шикаятьләр белән кабул итәләр. ТР прокуратурасы җитәкчеләре, кагыйдә буларак, гражданнарны һәрберсе билгеле бер көндә (атнага бер көннән дә ким түгел) кабул итә.

Сораулар һәм биремнәр: 1. Эшлекле уен үткәрегез: законсыз эштән чыгарсалар, хезмәт хакын вакытында бирүдән баш тартсалар, нинди органга мөрәҗәгать итәргә кирәк? Укучыларның берсе — кабул итүләрен сорап килгән граждан, икенчесе — кабул итүче урындагы кеше. Килеп туган сорауларга җавап таба алмасагыз, нинди материаллардан файдаланыр идегез? **2.** «Документаль материал» бүлегендә китерелгән дәгъва гаризаларының үрнәкләреннән файдаланып, законсыз эштән алуларын әйтеп, намусны һәм кешелек дәрәҗәсен яклауны сорап, дәгъва гаризалары языгыз.

Йомгак

Шулай итеп, дәреслегебезнең соңгы битләрен ябарга әзерләнәбез. Табигый ки, биредә әлеге катлаулы фәннең барлык аспектларын да тулысынча аңлатып бетереп булмады. Максатыбыз да бүтән иде — сезне хокук белеме белән таныштыру, катлаулы тормыш хәлләреннән мөстәкыйль чыгу юлларын өйрәтү. Хәтерегездәдер, хокук культурасы турында

сөйләшкәндә, хокук культурасы югары булган кеше законнарның нечкәлекләрен аңлау белән генә чикләнеп калмый, закон аңа әшендә, тормышында ярдәм итә дигән идек.

Дәресләребезнең юкка гына үткәрелмәгәнлегенә ышанасы килә. Сезнең белемегез артты, хокук белән кызыксына башладыгыз. Киләчәктә дә Россия һәм Татарстан законнары белән танышуыгызны дәвам итәрсез дип уйлыйбыз.

Әмма шунысы ачык: бернинди китап та чынбарлык тормышның үзен алыштыра алмый. Шуңа күрә, безнең дәреслəрдән файдаланып, тормышка кыюрак керегез. Шул чак тормыш һәм хокук сезгә йөз белән борылыр.

Закон бозулар кешеләр аны ирекле рәвештә үтәргә өйрәнгәч кенә тукталачак. Изгелекнең явызлыкны җиңәчәгенә ышанабыз.

ДОКУМЕНТАЛЬ МАТЕРИАЛ

Кеше хокукларының гомуми декларациясе

(өземтә)

Преамбула

Кешелек гаиләсенең барлык әгъзаларына хас булган горурлык хисен, аларның тигез һәм аерылгысыз хокукларын тану азатлыкның, гаделлекнең һәм бөтен дөньяда тынычлыкның нигезендә ятуын игътибарга алып; һәм

кеше хокукларына кимсетеп һәм нәфрәтләнеп карауның кешелек намусына кагыла торган вәхшилек актларына китерүен, һәм кешеләр сүз һәм инану ирегенә ия, курку һәм мохтаҗлыктан азат булган җәмгыять төзү кешеләрнең иң югары омтылышы икәнлеген игътибарга алып; һәм

кеше, соңгы чара буларак, залимлеккә һәм изүгә каршы баш күтәрергә мәҗбүр булмасын өчен, кеше хокукларының закон хакимияте тарафыннан саклануы зарурлыгын игътибарга алып; һәм

халыклар арасында дуслык мөнәсәбәтләренең үсүенә ярдәм итәргә кирәклекне игътибарга алып; һәм

Берләшкән Милләтләр халыкларының Уставта кешенең төп хокукларына, кеше шәхесенең абруена һәм кыйммәтенә, ирләрнең һәм хатын-кызларның тигез хокуклылыгына ышанычларын раслаганлыкларын һәм күбрәк ирек алып, социаль прогресска һәм тормыш шартларын яхшыртуга ирешергә карар кылганлыкларын игътибарга алып; һәм

дәүләт-әгъзаларның, Берләшкән Милләтләр Оешмасы белән хезмәттәшлек итеп, кеше хокукларын һәм төп ирекләрне хөрмәт итү һәм саклауда ярдәм итәргә йөкләмә алуларын игътибарга алып; һәм

бу хокукларның һәм ирекләрнең характерын гомуми аңлауның бу йөкләмәнең тулысынча үтәлүе өчен гаять зур әһәмияткә ия булуын игътибарга алып,

Генераль Ассамблея

кеше хокукларының әлеге Гомуми декларациясен, һәр кеше һәм җәмгыятьнең һәр органы, бу Декларацияне даими күздә тоткан хәлдә, мәгариф һәм белем бирү, милли һәм халыкара алгарыш чаралары, аларның дәүләтләр — Оешма әгъзалары халыклары арасында да, алар юрисдикциясендәге территория халыклары арасында да гомуми һәм нәтиҗәле танылуы һәм тормышка ашырылуы юлы белән бу хокукларны һәм ирекләрне ихтирам итүдә һәм тәэмин итүдә булышырга омтылырлык итеп, барлык халыклар һәм барлык дәүләтләр үтәргә тиешле бурыч сыйфатында игълан итә.

1 статья

Барлык кешеләр дә үзләренең дәрәҗәләре һәм хокуклары ягыннан ирекле һәм тигез булып туалар. Аларга гакыл һәм вөҗдан бирелгән һәм бер-берсенә карата туганлык мөнәсәбәтендә булырга тиешләр.

2 статья

Һәр кеше, расасы, тәненең төсе, җенесе, дине, сәяси һәм башка инанулары, милли һәм социаль чыгышы, мөлкәти, сословие һәм башка хәле нинди булуга карамастан, әлеге Декларация игълан иткән барлык хокукларга һәм ирекләргә ия булырга тиеш.

Моннан тыш, кеше торган илнең яки территориянең сәяси, хокукый яки халыкара статусы нигезендә, бәйсез илме ул, опека астындамы, үзидарәле түгелме яисә суверенлыгында башка төрле чикләүләр бармы, бернинди дә аерып караулар булырга тиеш түгел.

3 статья

Һәр кеше яшәүгә, иреккә һәм шәхси кагылгысызлыкка хокуклы.

4 статья

Беркем дә коллыкта яки ирексезлек халәтендә тотылырга тиеш түгел; коллык яки коллыкка сатуның барлык төрләре дә тыела.

5 статья

Беркем дә газаплау яки рәхимсез, кешелексез һәм дәрәҗәне кимсетә торган мөнәсәбәткә яисә җәзалауга дучар ителергә тиеш түгел.

6 статья

Һәр кеше, кайда гына булса да, хокук субъекты булып танылырга хокуклы.

7 статья

Барлык кешеләр дә закон каршында бертигез, һәм бер төрле дә аерма ясамыйча, закон тарафыннан тигез якланырга хокуклы. Барлык кешеләр дә әлеге Декларацияне боза торган теләсә нинди дискриминациядән, мондый дискриминациягә теләсә нинди котыртулардан тигез якланырга хокуклы.

8 статья

Һәр кеше, конституция яки закон тарафыннан бирелгән төп хокуклары бозылган очракта, хокукларының вәкаләтле милли судлар тарафыннан нәтиҗәле торгызылуына хокуклы.

9 статья

Беркем дә нигезсез кулга алынырга, тоткарланырга яки куылырга тиеш түгел.

10 статья

Һәр кеше, үзенең хокукларын һәм бурычларын, җинаятьтә гаепләнүенең дәлиллелеген билгеләү өчен, тулы тигезлек нигезендә, үз эшенең хәбәрдарлык һәм гаделлекнең барлык таләпләрен саклап, бәйсез һәм гадел суд тарафыннан каралуына хокуклы.

11 статья

1. Җинаять кылуда гаепләнгән һәр кеше, гаебе закон тәртибендә яклауның барлык мөмкинлекләре тәэмин ителгән ачык суд тикшерүе юлы белән билгеләнгәнче, гаепсез дип исәпләнергә хокуклы.

Беркем дә, нинди дә булса хәрәкәт яки хәрәкәтсезлек нигезендә, әгәр бу гамәлләр аларны кылган вакытта милли законнар яки халыкара хокук буенча җинаять дип исәпләнмәгән булса, җинаять өчен хөкем ителергә тиеш түгел. Шулай ук кешегә шушы җинаятьне кылган вакытта кулланылырга мөмкин булган җәзадан авыррагы бирелергә тиеш түгел.

12 статья

Беркем дә шәхси һәм гаилә тормышына нигезсез тыкшынуларга, торагының, корреспонденция серләренең, намусының һәм абруеның кагылгысызлыгына кул сузуларга дучар ителергә тиеш түгел. Һәр кеше мондый тыкшынулардан һәм кул сузулардан закон тарафыннан якланырга хокуклы.

13 статья

1. Һәр кеше һәр дәүләт эчендә үзенә яшәү урыны сайларга һәм ирекле рәвештә күчеп йөрергә хокуклы.

2. Һәр кеше, үз илен дә кертеп, теләсә кайсы илне ташлап китәргә һәм үзенекенә кире әйләнеп кайтырга хокуклы.

14 статья

1. Һәр кеше үзен эзәрлекләүләрдән башка илләрдә сыену урыны эзләргә һәм бу урыннан файдаланырга хокуклы.

2. Бу хокук чынлыкта сәяси булмаган җинаять кылуга яки Берләшкән Милләтләр Оешмасының максатларына һәм принципларына каршы килүче гамәлләр кылуга нигезләнгән эзәрлекләүләр очрагында файдаланыла алмый.

15 статья

1. Һәр кеше гражданлыкка хокуклы.

2. Беркем дә гражданлыгыннан яки гражданлыгын үзгәртү хокукыннан нигезсез мәхрүм ителә алмый.

16 статья

1. Балигъ булу яшенә җиткән ир-атлар һәм хатын-кызлар раса, милли һәм дини билгеләр буенча һәртөрле чикләүләрсез никахка керергә һәм гаилә төзергә хокуклы. Алар никахка керү вакытында, никахта торганда һәм аны өзгәндә бер үк төрле хокуклардан файдаланалар.

2. Никах һәр ике якның ирекле һәм тулы ризалыгы белән генә теркәлә ала.

3. Гаилә җәмгыятьнең табигый һәм төп ячейкасы булып тора; ул җәмгыять һәм дәүләт тарафыннан якланырга хокуклы.

17 статья

1. Һәр кеше милеккә аерым да, башкалар белән бергә дә ия булырга хокуклы.

2. Беркем дә үзенең милкеннән нигезсез мәхрүм ителергә тиеш түгел.

18 статья

Һәр кеше фикер, вөждан һәм дин ирегенә хокуклы; бу хокук диненңне яки инануларыңны алыштыру ирегеи, аерым да, башкалар белән бергәләп тә, ачыктан-ачык яки хосусый тәртиптә дә укуда, дингә хезмәт итүдә, дини һәм ритуаль йолалар үтәүдә дин тоту һәм инану ирегеи үз эченә ала.

19 статья

Һәр кеше инану ирегенә һәм аны ирекле белдерүгә хокуклы; бу хокук тоткарлыксыз үз инануларында тору ирегеи, теләсә нинди чаралар ярдәмендә һәм дәүләт чикләренә бәйсез рәвештә мәгълүматлар һәм идеяләр эзләү, табу һәм тарату ирегеи үз эченә ала.

20 статья

1. Һәр кеше тыныч җыелышлар һәм ассоциацияләр ирегенә хокуклы.
2. Беркем дә нинди дә булса ассоциациягә мәҗбүри кертелә алмый.

21 статья

1. Һәр кеше турыдан-туры яки ирекле сайлап куелган вәкилләр аша иле белән идарә итүдә катнашырга хокуклы.
2. Һәр кеше үз илендәге дәүләт хезмәтендә тигез катнашырга хокуклы.
3. Халык ихтыяры хөкүмәт хакимиятенең нигезе булырга тиеш, бу ихтыяр яшерен тавыш бирү юлы белән үтә торган гомуми һәм тигез сайлау хокукында яки тигез тавыш бирү ирегеи тәэмин итә торган башка формаларда чагылыш табарга тиеш.

22 статья

Һәр кеше, җәмгыять әгъзасы буларак, милли тырышлыклар һәм халыкара хезмәттәшлек ярдәмендә һәм һәр дәүләтнең структурасына һәм ресурсларына туры китереп, социаль тәэминатка, кешелек дәрәҗәсен төшермәү һәм шәхесен икътисади, социаль һәм мәдәни өлкәләрдә ирекле үстерү өчен кирәкле хокукларга ия булырга тиеш.

23 статья

1. Һәр кеше хезмәткә, эшне ирекле сайлауга, гадел һәм уңай хезмәт шартларына һәм эшсезлектән яклануга хокуклы.
2. Һәр кеше, бернинди дискриминациясез, бертигез хезмәт өчен бертигез хезмәт хакы алырга хокуклы.
3. Һәр хезмәткәр үзе өчен дә, гаиләсе өчен дә тиешле яшәү шартларын тәэмин итәрлек һәм кирәк чакта социаль тәэминатның башка чаралары белән дә тулыландырыла торган гадел һәм канәгатьләнерлек түләүгә хокуклы.
4. Һәр кеше, үз мәнфәгатьләрен яклау өчен, профессиональ союзлар төзергә һәм профессиональ союзларга керергә хокуклы.

24 статья

Һәр кеше ялга һәм эштән буш вакытка, эш вакытының кирәгенчә чикләнүенә, даими рәвештә түләүле ялга хокуклы.

25 статья

1. Һәр кеше, азык-төлек, кием-салым, торак, медицина ярдәмен дә кертеп, сәламәтлеккә һәм үзенең һәм гаиләсенең уңайлы тормышы өчен кирәкле дәрәҗәгә ия булырга хокуклы; эшсезлек, авыру, гариплек, тол калу, картлык килү яки аның үзенә бәйсез рәвештә башка яшәү чыганакларын югалту очракларында тәэмин ителергә хокуклы.

2. Ана булу һәм балачак аерым бер карауга һәм ярдәмгә хокук бирә. Никахта яки никахсыз туган барлык балалар бер үк төрле социаль яклаудан файдаланырга тиеш.

26 статья

1. Һәр кеше белем алырга хокуклы. Белем алуның ким дигәндә башлангыч һәм гомуми белемгә кагылышлысы түләүсез булырга тиеш. Башлангыч белем мәҗбүри булырга тиеш. Техник һәм профессиональ белем һәркем ирешә алырлык, югары белем алу һәркемнең сәләте нигезендә барлык кеше өчен бертигез дәрәҗәдә мөмкин булырга тиеш.

2. Мәгариф кеше шәхесен тулы үстерүгә һәм кеше хокукларына һәм аның төп ирекләренә ихтирамны арттыруга юнәлдерелергә тиеш. Белем барлык халыклар, раса һәм дини төркемнәр арасында үзара аңлашуга, түземлелеккә һәм дуслыкка ярдәм итәргә һәм Берләшкән Милләтләр Оешмасының тынычлыкны саклау буенча эшчәнлегенә булышырга тиеш.

3. Ата-аналар үзләренең кече яшьтәге балалары өчен белем алу төрен сайлау өстенлегенә хокуклы.

27 статья

1. Һәр кеше җәмгыятьнең мәдәни тормышында ирекле катнашырга, сәнгать белән хозурланырга, фәнни алгарышта катнашырга һәм аның уңайлыкларыннан файдаланырга хокуклы.

2. Һәр кеше үз авторлыгындагы фәнни, әдәби һәм сәнгать әсәрләренең нәтиҗәләре булган мораль һәм матди мәнфәгатьләрен якларга хокуклы.

29 статья

1. Һәр кеше үз шәхесенә ирекле һәм тулы үсәргә мөмкинлек биргән җәмгыять алдында бурычлы.

2. Үз хокукларын һәм ирекләрен тормышка ашырганда һәр кеше башкаларның хокукларын һәм ирекләрен тиешле дәрәҗәдә тану һәм ихтирам итү, демократик җәмгыятьтә моральнең, җәмәгать тәртибенең һәм гомуми уңайлыкларның гадел таләпләрен канәгатьләндерү максатында бары тик закон тарафыннан билгеләнгән чикләүләргә генә дучар ителергә тиеш.

30 статья

Бу Декларациядәге бер нәрсә дә нинди дә булса дәүләткә, кешеләр төркеменә яки аерым кешеләргә әлеге Декларациядә бәян ителгән хокукларны һәм ирекләрне юкка чыгарырга юнәлтелгән нинди дә булса эшчәнлек белән шөгыльләнергә яки гамәлләр кылырга хокук бирә дигәнне аңлатмый.

Генераль Ассамблея тарафыннан 1948 елның 10 декабрендә кабул ителде.

БАЛА ХОКУКЛАРЫ ТУРЫНДА КОНВЕНЦИЯ

(өземтә)

1 статья

Әлеге Конвенция максатлары өчен 18 яшькә җитмәгән һәр кеше заты, әгәр ул үзенә карата кулланылган закон буенча балигъ булу яшенә иртәрәк җитмәсә, бала булып исәпләнә.

2 статья

1. Катнашучы дәүләтләр, һичнинди дискриминациясез, расасы, тән төсе, җенесе, теле, дине, сәяси һ. б. ышанулары, милләте, этник һәм социаль чыгышы, мөлкәти хәле, баланың тууы һәм сәламәтлеге, аның ата-аналары яки законлы опекуннары яисә нинди дә булса башка шартларга карамастан, әлеге Конвенциядә каралган хокуклар белән үзләренең юрисдикцияләре эчендәге һәр баланы тәэмин итәләр.

2. Катнашучы дәүләтләр баланы статус, эшчәнлек, бала һәм баланың ата-аналары, законлы опекуннар яки гаиләнең башка әгъзалары белдерә торган карашлар һәм ипанулар нигезендә дискриминациянең яки җәзалауларның барлык формаларыннан яклауны тәэмин итү өчен бөтен кирәкле чараларны күрәләр.

3 статья

1. Балаларга мөнәсәбәтле барлык гамәлләрдә, алар социаль тәэминат мәсьәләләре белән шөгыльләнүче дәүләт һәм хосусый учреждениеләр тарафыннанмы, судлар, административ яки закон чыгаручы органнар тарафыннанмы башкарылуына карамастан, бала мәнфәгатьләрен бик яхшы итеп тәэмин итүгә беренче чиратта игътибар бирелә.

2. Катнашучы дәүләтләр баланы, аның ата-аналарының, опекуннарының яки аның өчен закон буенча җаваплы башка кешеләрнең хокукларын һәм бурычларын да игътибарга алып, тиешле яклау һәм кайгырту белән тәэмин итәргә йөкләмә алалар һәм шушы максаттан барлык кирәкле закон һәм административ чараларны күрәләр.

5 статья

Катнашучы дәүләтләр ата-аналарның һәм, тиешле очракларда, җирле йолалар тарафыннан каралганча, опекуннарның һәм закон буенча бала өчен җавап бирүче башка кешеләрнең әлеге Конвенция раслаган хокукларны тормышка ашыруда бала белән тиешле дәрәҗәдә идарә итү һәм җитәкчелек итү һәм моны баланың үсеп килүче мөмкинлекләренә туры китереп эшләү хокукларын һәм бурычларын ихтирам итәләр.

6 статья

1. Катнашучы дәүләтләр һәр баланың яшәүгә аерылгысыз хокукын таныйлар.

7 статья

1. Бала туганнан соң ук теркәлә һәм, туу мизгеленнән башлап, исем һәм гражданлык алырга, шулай ук, мөмкин булганча, ата-аналарын белергә һәм аларның кайгыртуларына хокуклы була.

8 статья

1. Катнашучы дәүләтләр баланың үз шәхсиятен саклау хокукын, гражданлыкны, исемне, гаилә бәйләнешләрен дә кертеп, законсыз тыкшынуларга юл куймыйча ихтирам итәргә йөкләмә алалар.

9 статья

1. Вәкаләтле органнарның суд карары буенча баланы ата-анасыннан аеруның бала мәнфәгатьләре өчен эшләнгәнлеге тиешле закон һәм процедуралар кулланып билгеләнә торган очракларны исәпләмәгәндә, катнашучы дәүләтләр баланың ата-анасыннан аерылмавын тәэмин итәләр.

11 статья

1. Катнашучы дәүләтләр балаларның законсыз чит илгә җибәрелүе һәм кайтарылмавы белән көрәшү өчен чаралар күрәләр.

13 статья

1. Бала үз фикерен ирекле рәвештә белдерергә хокуклы; бу хокук, дәүләт чикләреннән бәйсез рәвештә, телдән, язмача һәм басмача формада, сәнгать әсәре формасында яки бала теләге буенча башка чаралар ярдәмендә мәгълүматны яки теләсә нинди төрдәге идеяне эзләү, табу һәм тапшыру ирегеи дә үз эченә ала.

14 статья

1. Катнашучы дәүләтләр баланың фикер, вөҗдан һәм дин ирегенә хокукын ихтирам итәләр.
2. Катнашучы дәүләтләр ата-аналарның һәм тиешле очракларда баланың законлы опекуннарының бала хокукларын тормышка ашырганда аның сәләтләренә туры килә торган ысуллар куллану хокукларын һәм бурычларын ихтирам итәләр.
3. Үз динен тоту ирегe закон билгеләгән һәм дәүләт куркынычсызлыгын, җәмәгать тәртибен, халыкның әхлаклылыгын һәм сәламәтлеген саклау яки башка кешеләрнең төп хокукларын һәм ирекләрен яклау максатында гына чикләүләргә дучар ителергә мөмкин.

16 статья

Бер генә бала да аның шәхси тормышына, гаилә тормышына, торак кагылгысызлыгына яки корреспонденция серенә хокукын тормышка ашыруда нигезсез һәм законсыз тыкшыну, яки аның намусына һәм абруена законсыз кул сузу объекты була алмый.

18 статья

1. Катнашучы дәүләтләр ата-аналарның икесенең дә баланы тәрбияләү һәм үстерүдә уртак һәм бертөрле җаваплылык принцибын тануны тәэмин итү өчен мөмкин булган барлык тырышлыкны куялар. Ата-аналар яки тиешле очракларда законлы опекуннар баланы тәрбияләү һәм үстерү өчен төп җаваплы кешеләр булып саналалар. Бала мәнфәгатьләре аларның төп кайгырту предметы булып тора.

19 статья

1. Катнашучы дәүләтләр баланы ата-аналар, законлы опекуннар яки бала турында кайгыртучы теләсә кайсы башка кешеләр ягыннан барлык физик һәм психологик көч кулланулардан, мыскыл итүләрдән яки явызларча файдаланулардан, илтифатсыз тупас мөнәсәбәттән яки, сексуаль дәгъваларны да кертеп, эксплуатацияләү формаларыннан саклау максатында барлык кирәкле законнарны, административ, социаль һәм агарту чараларын кулланалар.

20 статья

1. Гаилә җылысыннан вакытлыча яки бөтенләйгә мәхрүм булган яки үз мәнфәгатьләрендә гаиләдә кала алмый торган бала дәүләтнең махсус яклавына һәм ярдәменә хокуклы.

24 статья

1. Катнашучы дәүләтләр баланың сәламәтлек саклау системасының иң камил хезмәтләреннән, авыруларны дәвалау һәм сәламәтлекне торгызу чараларыннан файдалану хокукын таныйлар.

27 статья

1. Катнашучы дәүләтләр һәр баланың физик, акыл, рухи, әхлакый һәм социаль үсеше өчен кирәкле тормыш дәрәҗәсенә хокукын таныйлар.

2. Ата-ана һәм баланы тәрбияләүче башка кешеләр, сәләтләре һәм финанс мөмкинлекләреннән чыгып, баланың үсеше өчен кирәкле тормыш шартларын тәэмин итүдә җаваплы.

28 статья

1. Катнашучы дәүләтләр баланың белем алуга хокукын таныйлар һәм бу хокукны тигез мөмкинлекләр нигезендә тормышка ашыруга акрынлап ирешү максатында әлешчә:

a) түләүсез һәм мәҗбүри башлангыч белем бирүне кертәләр;

b) гомуми һәм профессиональ урта белем бирүнең төрле формаларын үстерәләр, анда һәр баланың укый алуын тәэмин итәләр һәм түләүсез белем бирү һәм кирәк очракта финанс ярдәме күрсәтү кебек зарури чаралар күрәләр;

c) барлык кирәкле чаралар ярдәмендә, һәркемнең сәләте нигезендә һәммә кешенең югары белем алу мөмкинлеген тәэмин итәләр;

d) барлык балаларның белем һәм профессиональ хәзерлек өлкәсендә мәгълүмат һәм материаллар таба алуын тәэмин итәләр;

e) мәктәпкә даими йөрү һәм мәктәпне ташлаган укучылар санын киметү буенча чаралар күрәләр.

2. Катнашучы дәүләтләр мәктәп дисциплинасы кешелек дәрәҗәсен ихтирам итүне чагылдырган һәм әлеге Конвенциягә туры килә

торган ысуллар ярдәмендә саклануын тәэмин итүче барлык кирәкле чараларны күрәләр.

29 статья

1. Катнашучы дәүләтләр баланың белем алуы:
a) бала шәхесенең, сәләтләренең, акыл һәм физик мөмкинлекләренең иң тулы күләмдә үсүенә;
b) кеше хокукларына һәм төп ирекләренә, шулай ук Берләшкән Милләтләр Оешмасы Уставында игълан ителгән принципларга хөрмәт тәрбияләүгә;
c) баланың ата-аналарына, аның мәдәни үзенчәлегенә, теленә һәм кыйммәтләренә, бала яши торган илнең милли кыйммәтләренә хөрмәт тәрбияләүгә;
d) ирекле җәмгыятьтә үзара аңлашу, иминлек, түземлелек, ирләр һәм хатын-кызларның тигез хокуклылыгы һәм барлык халыклар, этник, милли һәм дини төркемнәр, шулай ук җирле халыклар арасындагы дуслык рухында баланы аңлы тормышка әзерләүгә;
e) әйләнә-тирә мохиткә ихтирам тәрбияләүгә юнәлтелергә тиеш булуы белән килешәләр.

30 статья

Этник, дини, тел ягыннан азчылык милләтләр яшәгән яки җирле халык арасыннан чыккан кешеләр яшәгән дәүләтләрдә шушы азчылыкка яки җирле халыкка караган бала, үз төркемендәге башка әгъзалар белән беррәттән, үз культурасыннан файдалану, динен тоту һәм йолаларын үтәү, шулай ук туган теленнән файдалану хокукыннан мәхрүм ителергә тиеш түгел.

31 статья

1. Катнашучы дәүләтләр баланың ялга һәм эштән буш вакытка булган хокукын, яшенә туры килә торган уеннарда һәм күңел ачу чараларында катнашу хокукын һәм ирекле рәвештә мәдәни тормышта катнашу һәм сәнгать белән шөгыльләнү хокукын таныйлар.

32 статья

1. Катнашучы дәүләтләр баланың икътисади эксплуатациядән һәм сәламәтлегенә зыян китерергә яки белем алуда тоткарлык булып торырга яисә аның сәламәтлегенә, физик, акыл, рухи, мораль һәм социаль үсешенә зыян салырга мөмкин булган теләсә нинди эшне башкарудан яклану хокукын таныйлар.

33 статья

Катнашучы дәүләтләр, тиешле халыкара килешүләрдә билгеләнгәнчә, балаларны наркотиклар һәм психотроп матдәләрне законсыз куллланудан саклау һәм мондый матдәләрне законсыз җитештерү һәм сату эшендә файдалануга юл куймау өчен барлык кирәкле чараларны (закон, административ һәм социаль чараларны да кертеп) күрергә тиешләр.

34 статья

Катнашучы дәүләтләр баланы сексуаль эксплуатациянең һәм сексуаль аздыруның барлык формаларыннан яклауны үз өсләренә алалар. Катнашучы дәүләтләр бу максатларда, аерым алганда, милли,

ике яклы һәм күп яклы дәрәҗәдә барлык тиешле чараларны күрәләр;

а) баланы теләсә нинди законсыз сексуаль эшчәнлеккә тарту яки мәҗбүр итүне;

b) балаларны фахишәлектә яки башка законсыз сексуаль практикада эксплуатацияләү максатында файдалануны;

c) балаларны порнографик материалда эксплуатацияләү максатында файдалануны булдырмау.

35 статья

Катнашучы дәүләтләр милли, ике яклы һәм күп яклы дәрәҗәләрдә төрле максатларда һәм төрле формаларда балаларны урлауны, балалар белән сату итүне яки контрабанданы туктату өчен барлык кирәкле чараларны күрәләр.

36 статья

Катнашучы дәүләтләр баланы аның иминлегенә зыян китерә торган теләсә нинди башка төрле эксплуатациядән саклыйлар.

37 статья

Катнашучы дәүләтләр түбәндәгеләрне тәэмин итәләр:

а) бер бала да газаплауларга яки башка рәхимсез, кешелексез яки кешелек дәрәҗәсен кимсетә торган мөгамәлә яки җәза төрләренә дучар ителергә тиеш түгел. Азат итү мөмкинлеген карамый торган үлем җәзасы да, гомерлек төрмәгә ябылу да 18 яшьтән яшьрәк кешеләр кылган җинаятьләр өчен билгеләнми;

c) ирегеннән мәхрүм ителгән һәр балага, аның яшендәгеләрнең ихтыяҗларын исәпкә алып, кешелекле мөнәсәбәт һәм ихтирам белән карау тәэмин ителергә тиеш. Аерым алганда, ирегеннән мәхрүм ителгән һәр бала, әгәр аның мәнфәгатьләре буенча моны эшләргә кирәк түгел дип табылмаса, өлкәннәрдән аерым тотылырга, аерым шартларны исәпләмәгәндә, хат язышу һәм күрешү рәвешендә гаиләсе белән элемтәдә торырга тиеш.

38 статья

1. Катнашучы дәүләтләр кораллы бәрелешләр вакытында балаларга кагылышлы халыкара гуманитар хокук нормаларын хөрмәт итәргә һәм аларның үтәлешен тәэмин итәргә йөкләмә алалар.

2. Катнашучы дәүләтләр унбиш яше тулмаган затларның сугыш хәрәкәтләрендә турыдан-туры катнашмауларын тәэмин итү өчен барлык мөмкин булган чараларны күрәләр.

40 статья

1. Катнашучы дәүләтләр җинаять законын бозган дип саналган, аны бозуда гаепләнгән яки гаепле дип танылган һәр баланың үзенә карата кешелекле мөнәсәбәткә хокукын таныйлар, ул мөнәсәбәт балада кешелек дәрәҗәсе хисен, кеше хокукларына һәм башкаларның төп ирекләренә хөрмәт белән карау хисен үстерүдә булышырга, баланың җәмгыятькә файдалы кеше булып китүенә ярдәм итәргә тиеш.

2. Шушы максатларда һәм халыкара документларның тиешле положениеләрен игътибарга алып, катнашучы дәүләтләр, аерым алганда:

b) җинаять законын бозган яки аны бозуда гаепләнгән һәр баланың ким дигәндә түбәндәге гарантияләре булуын тәэмин итәләр:

i) закон буенча гаебе расланганчы, гаепсезлек презумпциясе;

ii) аңа гаепләү турында (кирәк очракта аның ата-аналары яки законлы опекуннары аша) кичекмәстән яки турыдан-туры хәбәр итү һәм үзен яклауны хәзерләү яки тормышка ашыру вакытында кирәкле башка ярдәмне күрсәтү;

iy) шаһитлык күрсәтмәләре бирергә яки гаебен танырга мәҗбүрилектән азат итү; мөстәкыйль рәвештә яки башка кешеләр ярдәмендә шаһитларның гаепләү күрсәтмәләрен өйрәнүне, шаһитларның тигез хокукта катнашуларын һәм аларның күрсәтмәләрен өйрәнүне тәэмин итү.

43 статья

1. Катнашучы дәүләтләрнең әлеге Конвенциягә ярашлы рәвештә кабул ителгән бурычларын үтәүдә ирешелгән алгарышны карау максатларында бала хокуклары буенча Комитет төзелә...

Конвенция БМО Генераль Ассамблеясы тарафыннан 1989 елның 20 ноябрендә хупланды.
СССР Югары Советы тарафыннан ратификацияләнде һәм 1990 елның 15 сентябрендә СССР өчен үз көченә керде.

* * *

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КОНСТИТУЦИЯСЕ
(өземтә)

Бу Конституция Татарстан Республикасының дәүләт статусы турында халыкның тавыш бирүе (референдум) йомгаклары нигезендә кабул ителә һәм игълан ителә.

I. Татарстан Республикасының дәүләт һәм иҗтимагый төзелеше нигезләре

1 бүлек. Иҗтимагый-сәяси система

1 статья. Татарстан Республикасы — республиканың күпмилләтле барлык халкы ихтыярын һәм мәнфәгатен чагылдыручы суверен демократик дәүләт.

Дәүләт суверенитетын һәм вәкаләтләрен халык билгели.

Дәүләт суверенитеты — Татарстан Республикасының төп билгесе.

2 статья. Татарстан Республикасында бөтен хакимият халык кулында. Халык дәүләт хакимиятен шушы Конституция нигезендә турыдан-туры, шул исәптән референдум юлы белән дә, дәүләт органнары системасы аша да гамәлгә ашыра. Татарстан Республикасы Конституциясе Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан яки референдум юлы белән кабул ителә.

Халык депутатлары Советлары, халыкның вәкиллекле органнары буларак, дәүләтнең сәяси нигезен тәшкил итә.

Аерым шәхес яки шәхесләр төркеме Татарстан Республикасында дәүләт хакимиятен тормышка ашыру хокукын үзләштерә алмый.

3 статья. Граждан белән дәүләт арасындагы мөнәсәбәтләр иң зур социаль хәзинә булган кеше хокуклары өстенлегенә, гражданнарның дәүләт эшләрен идарә итүдә катнашуына нигезләнә. Үзара мөнәсәбәтләрендә граждан һәм дәүләт бер-берсе алдында җаваплы.

Татарстан Республикасы сәяси, икътисади, социаль һәм мәдәни тормышның барлык өлкәләрендә гражданнарның тигез хокуклылыгын гарантияли.

Халыкның барлык катлауларының, барлык милләт гражданнарының бер-берсен хөрмәт итүе, ирекле һәм тигез хокуклы хезмәттәшлеге Татарстан Республикасының иҗтимагый нигезен тәшкил итә.

4 статья. Татарстан Республикасында дәүләт телләре — тигез хокуклы татар һәм рус телләре.

5 статья. Татарстан Республикасында дәүләт органнарының эшчәнлеге хокукый дәүләт принципларында: законнарның өстенлеге, аларның тайпылышсыз үтәлеше, закон чыгару, башкару һәм суд хакимиятләренең аерым-аерым булуы принципларында гамәлгә ашырыла.

6 статья. Сәяси партияләр, профессиональ союзлар, массакүләм хәрәкәтләр һәм башка җәмәгать берләшмәләре дәүләт эшләрен идарә итүдә дәүләт хакимиятенең сайлаулы органнарындагы үз вәкилләре аша катнашырга хокуклы. Үзләренең программа һәм уставларында каралган вазифаларны үтәгәндә алар Татарстан Республикасы Конституциясе һәм законнары чикләрендә эш итә.

Татарстан Республикасының конституцион төзелешен һәм бөтенлеген көчләп үзгәртүне, аның иминлеген какшатуны, социаль, раса, милли һәм дини ызгыш кабызуны максат итеп куйган партия, оешма һәм хәрәкәтләр төзүгә, аларның эшчәнлегенә юл куелмый, бу максатта массакүләм мәгълүмат чараларын, шулай ук башка чараларны файдалану тыела.

7 статья. Дәүләт үз эшчәнлеген социаль гаделлек принцибында оештыра, халыкның барлык катлауларына лаеклы тормыш дәрәҗәсен тәэмин итү өчен, җәмгыятьнең социаль-икътисади һәм мәдәни үсеше өчен кирәкле шартлар тудыра, экология хәвефсезлеген һәм табигатьтән акыллы файдалануны тәэмин итә.

8 статья. Дәүләтләр һәм халыклар арасындагы бәхәсләрне хәл итү чарасы буларак көч куллануны һәм сугышны Татарстан Республикасы кире кага.

Татарстан Республикасы территориясе — күпләп юк итү коралыннан азат зона.

Татарстан Республикасында сугышны пропагандалау тыела.

2 бүлек. **Икътисади система**

9 статья. Җир, җир асты, су, урман һәм башка табигый байлыклар, хайваннар һәм үсемлекләр дөньясы, дәүләт бюджеты акчалары, дәүләт банклары активлары, Татарстан халыкларының мәдәни һәм тарихи хәзинәләре, шулай ук республиканың хуҗалык мөстәкыйльлеген, матди һәм рухи мәдәниятен саклауны тәэмин итә торган башка мөлкәтләр — бөтенхалык байлыгы.

10 статья. Татарстан Республикасы икътисадының нигезен социаль базар хуҗалыгы тәшкил итә, анда закон нигезендә хуҗалык

эшчәнлеге ирекә һәм милекнең күп төрлелеге, аларны хокукый яклау өчен тигез шартлар тәэмин ителә.

Икътисади мөнәсәбәтләр граждан белән дәүләт, кулланучы белән җитештерүче, эш башкаручы белән эш бирүче арасындагы социаль партнерлык нигезендә төзелә.

Дәүләт хуҗалык эшчәнлеген, җәмгыять мәнфәгатьләренә туры китереп, закон билгеләгән чикләрдә җайга сала.

11 статья. Татарстан Республикасында хуҗалык эшчәнлеге хосусый, дәүләт, коммуналь милек һәм җәмәгать берләшмәләре милке нигезендә гамәлгә ашырыла.

Җир участоклары, закон тыймаган теләсә кайсы өлкәдә файдаланыла торган башка объектлар хосусый милек була ала.

Татарстан Республикасында башка дәүләтләр, халыкара оешмалар, чит илләрнең юридик затлары һәм гражданнары, гражданлыксыз шәхесләр милкенә юл куела, шулай ук гражданнар, юридик затлар һәм дәүләтләр милкен берләштерү рөхсәт ителә.

12 статья. Милек кагылгысыз. Законлы милек хуҗасының хокукын чикләүгә юл куелмый.

Милек дәүләт һәм җәмгыять мәнфәгатьләренә, кеше хокукларына, ирегенә һәм абруена зыян китерү максатында файдаланылмаска тиеш.

Милекне тартып алу закон нигезендә реквизиция һәм конфискация тәртибендә генә рөхсәт ителә.

13 статья. Татарстан Республикасының һәм аның гражданнарының Татарстан Республикасы территориясеннән читтәге милке дәүләт тарафыннан яклана.

15 статья. Татарстан Республикасы икътисады базар хуҗалыгы принципларын эшли. Дәүләт республика икътисадын үстерүне, предприятие һәм оешмаларның хуҗалык эшчәнлегенә катнашмыйча, икътисади һәм социаль үсеш программалары, салым, кредит, инвестиция һәм амортизация сәясәте белән, халыкның тормыш дәрәҗәсен билгели торган товарларга һәм хезмәтләргә, шулай ук монополист предприятиеләр продукциясенә бәяләр билгеләү сәясәте белән җайга сала. Татарстан Республикасының законнарын һәм халыкара йөкләмәләрен бозмаган очракта, икътисади мөстәкыйль предприятиеләр эшчәнлеген административ чикләүгә юл куелмый.

17 статья. Татарстан Республикасы кулланучы мәнфәгатьләрен яклый һәм аның хокукларын яклауга юнәлтелгән иҗтимагый эшчәнлекне хуплый. Кулланучылар товар җитештерүче һәм хезмәт күрсәтүче китергән зыянны закон билгеләгән тәртиптә түләттерергә хаклы.

18 статья. Татарстан Республикасы җир, җир асты байлыкларының, су, урман, үсемлекләр һәм хайваннар дөньясының саклануын тәэмин итә, табигатьтән түләүле файдалану нигезендә табигый байлыкларны торгызу һәм арттыру, мохитне яхшырту чаралары күрә.

Җир участогы хуҗалары, җир биләүче һәм җирдән файдаланучылар, табигатьтән файдаланучы башкалар җирнең уңдырышлылыгын сакларга бурычлы.

Хуҗалык эшчәнлеге нәтиҗәсендә әйләнә-тирә мохиткә, гражданнарның сәламәтлегенә һәм мөлкәтенә китерелгән зыян Татарстан Республикасы законнары нигезендә түләттерелергә тиеш. Татарстан Республикасы законнарын бозучы җир биләүче һәм җирдән файдаланучылар, табигатьтән файдаланучы башкалар эшчәнлеге республиканың дәүләт органнары тарафыннан туктатып торыла. Әйләнә-тирә мохитне саклау законнарын бозуда гаепле физик һәм юридик затлар закон нигезендә җавапка тартыла.

II. Шәхес һәм дәүләт

3 бүлек. **Татарстан Республикасы гражданлыгы. Гражданнарның тигез хокуклылыгы**

19 статья. Татарстан Республикасының үз гражданлыгы бар. Татарстан Республикасы гражданлыгын алу яки аннан ваз кичү нигезләре һәм тәртибе Татарстан Республикасының гражданлык турындагы законы белән билгеләнә.

Татарстан Республикасы гражданнары Россия Федерациясе — Россия — гражданлыгына ия.

Һәр кеше гражданлыкны сайларга һәм аны үзгәртергә хокуклы. Гражданлыктан яки гражданлыкны үзгәртү хокукыннан мәхрүм итү тыела.

20 статья. Татарстан Республикасының барлык гражданнары тигез хокуклы һәм тигез бурычлы. Чыгышына, социаль һәм мөлкәти хәленә, нинди расадан һәм милләттән булуына, җенесенә, белеменә, теленә, сәяси карашына, дини мәсләгенә, шөгыленең төренә һәм үзенчәлегенә, торган урынына һәм башкаларга карамастан, алар дәүләт тарафыннан яклануга тигез хокуклы.

Гражданнарга туган теленнән файдалану гарантияләнә.

Гражданнарның Конституциядә каралган хокуклары, ирекләре һәм бурычлары турыдан-туры Конституция нигезендә гамәлгә ашырыла.

21 статья. Татарстан Республикасының барлык гражданнарына гомумтанылган халыкара хокук нормалары, шулай ук Татарстан Республикасының халыкара килешүләре нигезендә Татарстан Республикасы Конституциясендә каралган хокуклар һәм ирекләр гарантияләнә.

Татарстан Республикасының читтә яшәүче һәр гражданына Татарстан Республикасының хокукый яклавы һәм ярдәме гарантияләнә.

Гражданнарның хокуклары һәм ирекләре закон һәм суд карары нигезендә генә чикләнә яки туктатып торыла ала.

22 статья. Гражданнарның хокукларын турыдан-туры яки башкача чикләгән яисә раса, милли һәм башка билгеләр буенча аларга өстенлекләр билгеләгән өчен закон нигезендә җәза бирелә.

23 статья. Чит ил гражданнары һәм гражданлыксыз шәхесләр, законда башкача каралмаган булса, Конституциядәге барлык хокуклардан һәм ирекләрдән Татарстан Республикасы гражданнары белән тигез файдаланалар.

Татарстан Республикасы территориясендә чит ил гражданнары һәм гражданлыксыз шәхесләр Татарстан Республикасы Конституциясен һәм законнарын ихтирам итәргә һәм үтәргә бурычлы.

4 бүлек. **Кеше һәм гражданның хокуклары, ирекләре һәм бурычлары**

24 статья. Татарстан Республикасы гражданнары шушы Конституциядә каралган шәхси, сәяси, социаль-икътисади һәм мәдәни хокукларга һәм ирекләргә тулысынча ия.

25 статья. Дәүләт кешенең тормышын, сәламәтлеген, шәхси ирекен һәм иминлеген яклый.

26 статья. Татарстан Республикасы гражданнарына шәхес кагылгысызлыгы гарантияләнә. Беркем дә законсыз кулга алына һәм ирегеннән мәхрүм ителә алмый. Кулга яки сак астына алынган очрак-

та граждан бу хакта кичекмәстән судка шикаять бирергә хаклы. Хокук бозган өчен җавапка тартылган граждан закон һәм хокукый процедура чикләрендә гаебе исбатланганга кадәр гаепсез дип санала.

Татарстан Республикасы гражданнарына яклану хокукы гарантияләнә.

27 статья. Татарстан Республикасы гражданнарына торак кагылгысызлыгы гарантияләнә. Законлы сәбәп булмаганда торакка керергә, анда яшәүчеләр ризалыгыннан башка тентү үткәрергә беркемнең дә хакы юк.

28 статья. Татарстан Республикасы гражданнарына хат алышу, телефоннан сөйләшү, телеграф һәм хәбәрләшүнең башка төрләрендә сер саклау тәэмин ителә.

29 статья. Татарстан Республикасы гражданнары, инануларына карап, теләсә кайсы динне тотарга ирекле яисә берсен дә тотмаска, дини яки атеистик эшчәнлек белән шөгыльләнергә хокуклы. Дини йолаларны үтәүдә һәркем ирекле.

Дини инануларга бәйле рәвештә дошманлык, нәфрәт һәм милли ызгыш уяту тыела.

Татарстан Республикасында диннәр һәм дини берләшмәләр дәүләттән аерылган.

30 статья. Гаилә, ана, ата һәм балалар дәүләт яклавында. Никах хатын-кыз белән ир-атның ирекле килешүенә нигезләнә; гаилә мөнәсәбәтләрендә хатын белән ир тигез хокуклы. Гражданнарның гаилә тормышы закон белән саклана.

Дәүләт гаилә турында кайгырта, ана белән баланың сәламәтлеген саклауга һәм балаларны тәрбияләүгә аерым игътибар бирә.

Татарстан Республикасы гражданнары үз балаларын тәрбияләү өчен җаваплы. Балигъ булган балалар ата-аналарын кайгыртырга һәм аларга ярдәм күрсәтергә бурычлы.

31 статья. Һәр граждан Татарстан Республикасы территориясендә ирекле күчеп йөрүгә, яшәү һәм тору урынын сайлауга хокуклы. Бу хокукны закон гына чикли ала.

32 статья. Һәр кеше Татарстан Республикасы территориясеннән ирекле рәвештә китәргә һәм республикага әйләнеп кайтырга хокуклы.

33 статья. Шәхесне ихтирам итү, гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен саклау — барлык дәүләт органнарының, җәмәгать берләшмәләре һәм урындагы кешеләрнең бурычы.

Татарстан Республикасы гражданнары намусына һәм абруена, тормышына һәм сәламәтлегенә, шәхси ирегенә һәм мөлкәтенә кул сузудан суд аша якланырга хокуклы.

34 статья. Һәр граждан урындагы кешеләрнең, дәүләт органнары һәм җәмәгать оешмаларының гамәленә карата судка шикаять бирергә, шулай ук әхлакый һәм матди зыянны түләтергә хокуклы.

35 статья. Татарстан Республикасында һәркемгә сүз, матбугат, фикер һәм инану иреге, аларны тоткарлыксыз белдерү һәм тарату иреге гарантияләнә.

36 статья. Татарстан Республикасы гражданнары закон билгеләгән тәртиптә тыныч һәм коралсыз митинг, урамда оешып йөрү, демонстрация һәм пикетлар оештыруга хокуклы.

37 статья. Халык мәнфәгатьләренә туры китереп һәм иҗтимагый активлыкны күтәрү максатында Татарстан Республикасы гражданнары сәяси партияләргә, профессиональ союзлар, массакүләм хәрәкәтләргә һәм башка җәмәгать берләшмәләренә берләшергә, гамәлдәге законнар чикләрендә гражданлык инициативасы тәртибендәге чараларда катнашырга хокуклы. Дәүләт аларга устав бурычларын үтәүдә булыша.

38 статья. Татарстан Республикасы гражданнары сәяси тормышта, дәүләт һәм җәмәгать эшләрен идарә итүдә, гомумреспублика һәм җирле әһәмияттәге законнарның һәм карарларның проектын тикшерүдә референдумнарда катнашырга хокуклы.

39 статья. Закон нигезендә һәр гражданга дәүләт хезмәтенә керү өчен тигез хокук гарантияләнә.

40 статья. Татарстан Республикасының һәр гражданы дәүләтнең эчке һәм халыкара тормышының барлык өлкәләре, шул исәптән шәхеснең хокукы статусы мәсьәләләре турында дөрес мәгълүматны тоткарлыксыз алырга һәм таратырга хокуклы.

Дәүләт органнары, җәмәгать берләшмәләре һәм урындагы кешеләр гражданга аның хокукларына һәм законлы мәнфәгатьләренә кагылышлы карарлар һәм башка материаллар белән танышу мөмкинлеген тәэмин итәргә тиеш.

41 статья. Татарстан Республикасы гражданнары милеккә һәм аны мирас итүгә хокуклы.

42 статья. Татарстан Республикасы гражданнары хезмәткә, ягъни һөнәрен һәм эш урынын сайлау, хезмәткә сәләтен файдалану ирегенә хокуклы. Хезмәт килешүе иреге гарантияләнә.

Һәркем хәвефсезлек һәм гигиена таләпләренә туры килә торган хезмәт шартларына, хезмәтенә закон билгеләгән иң аз күләмнән дә ким булмаган түләүгә хокуклы.

Милек формасы нинди булуга карамастан, барлык предприятие, учреждение һәм оешмаларда эшләүчеләргә дәүләт эшкә алуның, эштән бушатуның һәм хезмәтне саклауның гадел шартларын, хезмәт хокукларын һәм мәнфәгать вәкиллеге ирекен гарантияли.

Дәүләт балигъ булмаган, физик һәм психик кимчелекле кешеләрнең хезмәткә хокукларын гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыра, гарипләрне, мохтаҗ һәм даими эше булмаган гражданнарны социаль яклауны гарантияли, кирәк очракта аларны өйрәтүне һәм квалификацияләрен үзгәртүне оештыра.

Мәҗбүри хезмәткә суд карары белән, шулай ук Татарстан Республикасының халыкара килешүләрендә каралган очракларда гына юл куела.

43 статья. Татарстан Республикасы гражданнарына ялга һәм эштән буш вакытка хокук гарантияләнә. Бу хокук 40 сәгатьтән артык булмаган эш атнасы билгеләү, хезмәт имләренә ел саен түләүле ял, атна саен ял көннәре бирү, буш вакытны файдалы үткәрү өчен шартлар тудыру белән тәэмин ителә.

44 статья. Татарстан Республикасының һәр гражданы сәламәтлеген саклауга, шул исәптән сәламәтлек саклауның дәүләт һәм башка учреждениеләре закон тәртибендә күрсәтә торган медицина ярдәменә хокуклы.

Дәүләт гражданнарның сәламәтлеген ныгытуга, физик культура һәм спортны үстерүгә ярдәм итүче эшчәнлекне хуплый.

45 статья. Татарстан Республикасы гражданнары чиста табигать мохитенә хокуклы.

46 статья. Татарстан Республикасы гражданнары картлыкта, авырганда, хезмәткә сәләтен тулысынча яки өлешчә югалтканда, бала табып, аны закон билгеләгән яшькә җиткергәндә, туендыручысын югалтканда, шулай ук законда күздә тотылган башка нигезләрдә һәм күләмдә матди тәэмин ителүгә хокуклы.

47 статья. Татарстан Республикасы гражданнары торакка хокуклы. Бу хокук дәүләт һәм җәмәгать торак фондын үстерү, кооператив һәм шәхси торак төзелешенә булышу белән тәэмин ителә. Законда билгеләнгән очраклардан тыш, беркем дә торагыннан мәхрүм ителә алмый.

48 статья. Татарстан Республикасы гражданнары дәүләт уку йортларында түләүсез гомуми урта һәм махсус урта белем алырга, шулай ук мәктәптә туган телендә укырга хокуклы.

Татарстан Республикасы гражданнары дәүләт уку йортларында конкурс нигезендә түләүсез югары белем алырга хокуклы.

49 статья. Татарстан Республикасы гражданнары мәдәният казанышларыннан файдаланырга хокуклы. Һәр кешегә фәндә, техникада һәм сәнгатьтә иҗат иреге гарантияләнә.

Автор, уйлап табучы һәм рационализатор хокуклары дәүләт тарафыннан саклана.

50 статья. Татарстан Республикасы гражданнары икътисади һәм социаль мәнфәгатьләрен яклау өчен, күмәк хезмәт бәхәсен хәл итүнең соңгы чарасы буларак, законда каралган эш ташлауга хокуклы.

Беркем дә эш ташлауда катнашырга мәҗбүр ителә алмый.

Кешеләрнең гомеренә һәм сәламәтлегенә куркыныч тудырырлык эш ташлауга юл куелмый.

51 статья. Гражданнарның Конституция игълан иткән хокукларын һәм ирекләрен файдалануы дәүләт һәм җәмәгать иминлегенә, җәмәгать тәртибенә, халыкның сәламәтлегенә һәм әхлагына, башка кешеләрнең хокукларына һәм ирекләренә зыян китермәскә тиеш.

52 статья. Татарстан Республикасы гражданнары Татарстан Республикасы Конституциясен һәм законнарын үтәргә бурычлы.

53 статья. Татарстан Республикасы гражданнары башка кешеләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен ихтирам итәргә бурычлы.

Башка гражданнарның намусын һәм милли горурлыгын ихтирам итү — Татарстан Республикасының һәр гражданы бурычы.

54 статья. Татарстан Республикасы гражданнары, закон тәртибендә салымнар түләп, дәүләт чыгымнарында катнашырга бурычлы.

55 статья. Табигатькә сакчыл мөнәсәбәт — Татарстан Республикасының һәр гражданы бурычы.

56 статья. Мәдәни хәзинәләрне, тарихи истәлекләрне саклау — Татарстан Республикасы гражданнарының бурычы.

Мәдәни истәлекләрне бозган яки юкка чыгарган өчен Закон нигезендә җәза бирелә.

57 статья. Башка илләрнең халыклары белән дуслык һәм хезмәттәшлекне үстерүгә булышу, гомумтанылган халыкара хокук нормалары нигезендә бөтен дөньяда тынычлыкны саклау һәм ныгыту — Татарстан Республикасы гражданнарының бурычы.

58 статья. Татарстан Республикасы гражданнары закон нигезендә хәрби хезмәт үтәргә бурычлы. Хәрби хезмәт Татарстан Республикасы территориясендә яки Татарстан Республикасының килешү йөкләмәләре нигезендә аннан читтә үтелә.

Хәрби хезмәтне альтернатив вазифалар белән алыштыру, шулай ук хәрби хезмәттән азат итү закон белән билгеләнә.

III. Татарстан Республикасының дәүләт төзелеше

5 бүлек. **Татарстан Республикасы — суверен дәүләт**

59 статья. Татарстан Республикасы үзенең дәүләти-хокукый статусын, сәяси, икътисади, социаль-мәдәни төзелеше мәсьәләләрен мөстәкыйль билгели һәм хәл итә. Татарстан Республикасы законна-

ры, әгәр алар Татарстан Республикасының халыкара йөкләмәләренә каршы килмәсә, аның бөтен территориясендә өстенлеккә ия.

60 статья. Татарстан Республикасы территориясе — кагылгысыз. Татарстан Республикасы белән башка дәүләтләр арасындагы чикләр үзара килешү нигезендә билгеләнә һәм үзгәртелә.

61 статья. Татарстан Республикасы — Россия Федерациясе (Россия) белән вәкаләтләрне һәм ике якка да караган эшләрне тапшырышу турындагы Килешү нигезендә ассоциацияләшкән суверен дәүләт, халыкара хокук субъекты.

62 статья. Татарстан Республикасы башка дәүләтләр белән мөнәсәбәткә керә, халыкара килешүләр төзи, дипломатия, консуллык, сәүдә һәм башка вәкиллекләр алмаша, халыкара хокук принципларына нигезләнеп, халыкара оешмалар эшчәнлегендә катнаша.

Гомумтанылган халыкара хокук принциплары һәм нормалары Татарстан Республикасы законнарыннан өстенрәк санала.

* * *

«Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында хакимият вәкаләтләре чикләрен билгеләү һәм үзара вәкаләтләр бүлешү турында»

Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы

ШАРТНАМӘСЕ

Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнарының һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының тулы вәкаләтле вәкилләре:

Россия Федерациясе Конституциясенә һәм Татарстан Республикасы Конституциясенә таянып;

халыкларның гомумтанылган үзбилгеләнү хокукыннан, тигез хокуклылык, ирекле рәвештә ихтыяр белдерә алу принципларыннан чыгып;

территория бөтенлеген һәм уртак икътисади мәйдан саклауны гарантияләп;

тарихи һәм милли традицияләрнең, мәдәниятләрнең, телләрнең саклануына һәм үсүенә ярдәм итеп;

гражданнар арасында тынычлыкны, милләтара татулыкны һәм халыкларның иминлеген тәэмин итү турында кайгыртып;

кайсы милләттән булуына, нинди дин тотуына, кайда яшәвенә һәм башка төрле аерымлыкларына бәйсез рәвештә, кешенең һәм гражданның төп хокуклары һәм ирекләре өстенлеген гамәлгә ашырып;

Татарстан Республикасының дәүләт буларак Россия Федерациясе белән Россия Федерациясе Конституциясе, Татарстан Республикасы Конституциясе һәм Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында хакимият вәкаләтләре чикләрен билгеләү һәм үзара

вәкаләтләр бүлешү турында шартнамә нигезендә берләшүен, халыкара һәм тышкы икътисади мөнәсәбәтләрдә катнашуын исәпкә алып, түбәндәгеләр хакында килештеләр:

I статья

Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында хакимият вәкаләтләре чикләрен билгеләү һәм үзара вәкаләтләр бүлешү Россия Федерациясе Конституциясе, Татарстан Республикасы Конституциясе һәм шушы Шартнамә нигезендә гамәлгә ашырыла.

II статья

Татарстан Республикасының үз Конституциясе һәм законнары бар.

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары дәүләт хакимияте вәкаләтләрен гамәлгә ашыралар, шул исәптән:

1) кеше һәм гражданның хокукларын һәм ирекләрен яклауны тәэмин итәләр;

2) республика бюджетын формалаштыралар, республика салымнарын билгелиләр һәм җыялар;

3) адвокатура һәм нотариат мәсьәләләрен хәл итәләр;

4) административ, гаилә, торак мөнәсәбәтләрен, әйләнә-тирә мохитне саклау һәм табигатьтән файдалану өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне хокукый яктан тәртипкә салуны гамәлгә ашыралар;

5) Татарстан Республикасы судлары тарафыннан хөкем ителгән затларның гаебен кичерүне гамәлгә ашыралар;

6) фәкать Татарстан халкы байлыгы һәм милке булып торучы җиргә, җир асты байлыкларына, су, урман һәм башка табигый ресурсларга, шулай ук, федераль милек объектларыннан кала, Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан дәүләт предприятиеләренә, оешмаларына, башка күчемле һәм күчемсез дәүләт милкенә хуҗа булу, алардан файдалану һәм аларны идарә итү мәсьәләләрен хәл итәләр;

7) Татарстан Республикасының дәүләт органнары системасын, аларны оештыру һәм эшчәнлек тәртибен билгелиләр;

8) республика гражданлыгы мәсьәләләрен хәл итәләр;

9) федераль закон нигезендә хәрби хезмәтне башка хезмәт белән алыштырырга хокукы булган гражданнарга Татарстан Республикасы территориясендә альтернатив гражданлык хезмәте узу тәртибен билгелиләр;

10) Россия Федерациясе республикалары, крайлары, өлкәләре, автономияле өлкәсе һәм автономияле округлары, Мәскәү һәм Санкт-Петербург шәһәрләре белән Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы Конституцияләренә, шушы Шартнамәгә, Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында төзелгән башка килешүләргә каршы булмаган мөнәсәбәтләр урнаштыралар һәм багланышлар тоталар, шартнамәләр һәм килешүләр төзиләр;

11) халыкара багланышларда катнашалар, чит дәүләтләр белән мөнәсәбәтләр урнаштыралар һәм алар белән Россия Федерациясе Конституциясенә һәм аның халыкара йөкләмәләренә, Татарстан Республикасы Конституциясенә һәм шушы Шартнамәгә каршы килмәгән килешүләр төзиләр, тиешле халыкара оешмаларның эшчәнлегендә катнашалар;

12) аерым килешү нигезендә Милли банк төзиләр;

13) мөстәкыйль рәвештә тышкы икътисади эшчәнлекне гамәлгә

ашыралар. Тышкы икътисади эшчәнлек өлкәсендә вәкаләтләрне чикләү аерым килешү нигезендә тормышка ашырыла;

14) Татарстан Республикасының дәүләт милке булган предприятиеләрдә аерым Килешүдә билгеләнгән тәртиптә конверсия мәсьәләләрен хәл итәләр;

15) Татарстан Республикасының дәүләт бүләкләрен һәм мактаулы исемнәрен булдыралар.

III статья

Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары тарафыннан түбәндәге вәкаләтләр бергәләп гамәлгә ашырыла:

1) кеше һәм гражданның хокукларын һәм ирекләрен, милли азчылыкның хокукларын тәэмин итү;

2) суверенитетны һәм территория бөтенлеген саклау;

3) Татарстан Республикасы территориясендә халык хуҗалыгын мобилизациягә әзерләүне оештыру, кораллар һәм хәрби техника эшләүгә җитәкчелек итү; корал, сугыш кирәк-яраклары, хәрби техника һәм башка төрле хәрби мөлкәтне сату, шулай ук оборона промышленностена конверсия ясау мәсьәләләре. Якларның тиешле вәкаләтләрен гамәлгә ашыруда ни рәвешле һәм күпме дәрәҗәдә катнашулары аерым Килешүләр белән билгеләнә;

4) гражданлыкның гомуми һәм бәхәсле мәсьәләләре;

5) халыкара һәм тышкы икътисади элемтәләрне килештерү;

6) бәяләр сәясәтен килештерү;

7) региональ үсеш фондларын оештыру;

8) акча сәясәтен үткәрү;

9) якларның мәнфәгатен исәпкә алып, ирекле рәвештә үзара килешү буенча бергәләп идарә ителүгә тапшырылырга мөмкин булган Россия Федерациясе яки Татарстан Республикасы милкендәге объектлар белән идарә итү; конкрет объектлар белән бергәләп идарә итү рәвеше һәм тәртибе аерым Килешүләр нигезендә билгеләнә;

10) геодезия, метеорология хезмәте, вакытны исәпләү мәсьәләләренә караган эшчәнлекне килештерү;

11) бергәләп эшләгән программаларны финанслау өчен уртак фондлар төзү, үзара Килешүләр нигезендә табигать бәла-казалары һәм афәтләр китергән аяныч нәтиҗәләрне бетерү;

12) уртак энергетика системасы, магистраль, тимер юл, торбаүткәргеч, һава һәм су транспорты, элемтә, мәгълүмат системалары белән идарә итүне килештерү;

13) һава, диңгез, елга, тимер юл һәм автомобиль юллары, шулай ук торбаүткәргеч транспорт буенча йөкләрне һәм продукцияне, транспортны тоткарлыксыз һәм салым түләмичә йөртү режимын тәэмин итү;

14) халыкара стандарт нигезендә табигый мохитнең торышына бәя бирү, аны тотрыклы итү һәм торгызу чараларын гамәлгә ашыру, экологик иминлекне тәэмин итү, җир, су һәм башка табигый ресурслардан файдалану өлкәсендә эшләрне килештерү; экологик бәла-казаларны булдырмау; табигатьнең махсус рәвештә саклана торган территорияләре мәсьәләләре;

15) социаль өлкәдә уртак сәясәт үткәрү: халыкны эш белән тәэмин итү, миграция процесслары, социаль тәэминатны да кертеп, социаль яклау;

16) сәламәтлек саклау, гаиләне, аналарны, аталарны һәм балаларны яклау, мәгариф, фән, мәдәният, физик культура һәм спорт мәсьәләләре буенча эшчәнлекне килештерү; мәктәпләр, уку йортла-

ры, мәдәният учреждениеләре, массакүләм мәгълүмат чаралары, башка учреждениеләр һәм оешмалар өчен милли кадрлар әзерләү; мәктәпкәчә яшьтәге балалар учреждениеләрен һәм уку йортларын туган телдә әдәбият белән тәэмин итү; халыкларның тарихы, мәдәнияте һәм аларның телләре өлкәсенә караган фәнни тикшеренүләрне килештерү;

17) суд һәм хокук саклау органнары кадрлары;

18) адвокатура, арбитраж һәм нотариат;

19) хокук саклау органнары эшчәнлеген килештерү, иминлек саклау органнарының үзара килешеп эшләве, җинаятьчелек белән көрәшү буенча максатчан программалар эшләү һәм гамәлгә ашыру;

20) дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә системасын оештыруның уртак принципларын билгеләү;

21) административ, административ-процессуаль, хезмәт, гаилә, торак, җир, су, урман турындагы законнар, җир асты байлыклары, әйләнә-тирә мохитне саклау турындагы законнар;

22) җирдән, җир асты байлыкларыннан, судан һәм башка табигать ресурсларыннан бергәләп файдалану мәсьәләләре;

23) үзара килешү буенча каралган башка вәкаләтләр.

IV статья

Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары карамагында тора:

1) Россия Федерациясе Конституциясен һәм федераль законнарны кабул итү һәм аларга үзгәрешләр кертү, аларның үтәлешен контрольдә тоту; Россия Федерациясенең федератив төзелеше һәм территориясе;

2) кеше һәм гражданның хокукларын һәм ирекләрен яклауны җайга салу; Россия Федерациясендә гражданлык; милли азчылыкның хокукларын җайга салу һәм яклау;

3) законнар чыгару, башкарма һәм суд хакимиятенең федераль органнары системасын, аларны оештыру тәртибен һәм эшчәнлекләрен билгеләү; дәүләт хакимиятенең федераль органнарын формалаштыру;

4) федераль дәүләт милке һәм аның белән идарә итү;

5) Россия Федерациясенең дәүләти, икътисади, экологик, социаль, мәдәни һәм милли үсеше өлкәсендә федераль сәясәт нигезләрен һәм федераль программаларны билгеләү;

6) бердәм базарның хокукый нигезләрен гамәлгә кую; финанс, валюта, кредит, таможня мәсьәләләрен җайга салу, акча эмиссиясе, бәяләр сәясәте нигезләре; федераль банкларны да кертеп, федераль икътисади хезмәтләр;

7) федераль бюджет; федераль салымнар һәм җыемнар; регионнарны үстерүнең федераль фондлары;

8) федераль энергетика системалары, атом-төш энергетикасы, таркалучан материаллар; федераль транспорт, аралашу юллары, мәгълүмат һәм элемтә; космостагы эшчәнлек;

9) Россия Федерациясенең тышкы сәясәте һәм халыкара мөнәсәбәтләре, Россия Федерациясенең халыкара килешүләре; сугыш һәм солых мәсьәләләре;

10) Россия Федерациясенең тышкы икътисади мөнәсәбәтләре;

11) оборона һәм иминлек; оборона производствосы; корал, сугыш кирәк-яраклары, хәрби техника һәм башка хәрби милкәтне сату һәм сатып алу тәртибе; агулы матдәләр, наркотиклар җитештерү һәм алардан файдалану тәртибе;

12) Россия Федерациясе дәүләт чикләренең, территориясендәге диңгезләрнең, һава киңлекләренең, аерым икътисади зонаның һәм континенталь шельфның статусын билгеләү һәм саклау;

13) суд төзелеше; прокуратура; җинаять, җинаять-процессуаль һәм җинаять-башкарма законнар; амнистия һәм хөкем ителгәннәрнең гаебен кичерү; гражданлык, гражданлык-процессуаль һәм арбитраж-процессуаль законнар;

14) федераль коллизион хокук;

15) метеорология хезмәте, стандартлар, эталоннар, үлчәү системасы һәм вакытны исәпләү; геодезия һәм картография; географик объектларның атамалары; рәсми статистика һәм бухгалтерлык исәбе;

16) Россия Федерациясенең дәүләт бүләкләре һәм мактаулы исемнәре;

17) федераль дәүләт хезмәте.

V статья

Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының хакимият органнары, учреждениеләре һәм урындагы кешеләре тарафыннан шушы органнарның, учреждениеләрнең һәм урындагы кешеләрнең вәкаләтләре чикләрендә бирелгән юридик документлар гамәлдә.

VI статья

Россия Федерациясенең дәүләт хакимияте органнары, Татарстан Республикасының хакимият органнары кебек үк, үзләренә карамаган мәсьәләләр буенча хокукый актлар чыгара алмыйлар.

Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте органнары, дәүләт хакимиятенең федераль органнары кебек үк, шушы Шартнамәне бозган Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарына карата протест белдерергә хокуклы.

Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнарының һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының бергәләп идарә итү даирәсендә вәкаләтләрне гамәлгә ашыру буенча килеп чыккан бәхәсләр үзара килешү тәртибендә хәл ителә.

VII статья

Шушы Шартнамәне тормышка ашыру максатларында Россия Федерациясенең дәүләт хакимияте органнары һәм Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте органнары өстәмә Килешүләр төзи, тигез шартларда уртак структуралар, комиссияләр оештыра алалар.

VIII статья

Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнарының һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының Казан шәһәрендә һәм Мәскәү шәһәрендә вәкаләтле вәкиллекләре бар.

IX статья

Шартнамә яки аның аерым положениеләре берьяклы тәртиптә гамәлдән чыгарыла, үзгәртелә яки аларга өстәмәләр кертелә алмый.

Шартнамә кул куйганнан соң 7 көн узгач көченә керә һәм матбугатта чыгарылырга тиеш.

1994 елның 15 февралендә Мәскәү шәһәрендә ике нөсхәдә, һәркайсы рус һәм татар телләрендә башкарылды, текстларның икесе дә бер үк көчкә ия.

Гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен бозучы эшләргә һәм карарларга карата судка шикаять бирү турында Россия Федерациясе законы

1 статья. Судка шикаять белән мөрәҗәгать итү хокукы.

Һәр граждан, әгәр дәүләт органнарының, җирле үзидарә органнарының, учреждениеләр, предприятиеләр һәм аларның берләшмәләренең, иҗтимагый берләшмәләрнең яки урындагы кешеләрнең, дәүләт хезмәткәрләренең законсыз эшләре (карарлары) белән аның хокуклары һәм ирекләре бозылган дип исәпли икән, судка шикаять белән мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Дәүләт хезмәткәренең җаваплылыгы «Россия Федерациясендә дәүләт хезмәте нигезләре турында»гы федераль законның 5 статьясы буенча аның кеше һәм гражданның хокукларын һәм ирекләрен тану, үтәү һәм яклау бурычы белән бәйле рәвештә барлыкка килә.

Муниципаль хезмәткәрләрне федераль закон ярдәмендә дәүләт хезмәткәрләренә тиңләштергән очракта, әлеге законның дәүләт хезмәткәрләре турындагы статьялары аларга да кагыла.

2 статья. Судка шикаять бирергә мөмкин булган эшләр (карарлар).

Дәүләт органнарының, җирле үзидарә органнарының, учреждениеләр, предприятиеләр һәм аларның берләшмәләренең, иҗтимагый берләшмәләрнең һәм урындагы кешеләрнең судка шикаять бирергә мөмкин булган эшләренә (карарларына) коллегиаль һәм аерым эшләнгән эшләре (карарлары), шул исәптән, нәтиҗәдә гражданның хокукларын һәм ирекләрен бозган; гражданның үзенең ирекләрен һәм хокукларын тормышка ашыруда топкарлыклар китереп чыгарган; гражданга законсыз нинди дә булса бурыч йөкләгән яки аны законсыз нинди дә булса җаваплылыкка тарткан эшләр кылу (карарлар кабул итү) өчен нигез булып торган рәсми мәгълүмат бирү керә.

Гражданнар, әлеге статьяның беренче кисәгендә күрсәтелгән органнарның, предприятиеләрнең, берләшмәләрнең, урындагы кешеләрнең хәрәкәтсезлегенә карата да, әгәр ул статьяның шул ук кисәгендә күрсәтелгән нәтиҗәләргә китерсә, шикаять бирергә хокуклы.

Һәр граждан турыдан-туры үзенең хокукларына һәм ирекләренә кагылган документларны һәм материалларны, әгәр алардагы мәгълүматка федераль закон билгеләгән чикләүләр булмаса, алырга хокуклы, ә урындагы кешеләр, дәүләт хезмәткәрләре аңа бу документлар белән танышу мөмкинлеге бирергә тиеш.

Граждан алда саналган эшләргә (карарларга) карата да, эшләр кылу (карарлар кабул итү) өчен нигез булып хезмәт итүче мәгълүматларга карата да яки икесенә карата берьюлы да шикаять бирергә хокуклы.

Рәсми мәгълүматка гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен тормышка ашыруда йогынты ясаган һәм эшләр кылган (карарлар кабул иткән) һәм дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, учреждениеләр, предприятиеләр һәм аларның берләшмәләре, иҗтимагый берләшмәләр һәм урындагы кешеләр, дәүләт хезмәткәрләре адресына җибәрелгән язма һәм телдән формадагы мәгълүматлар (әгәр аларның авторлары билгеле булса һәм суд тарафыннан карарлар кабул итү өчен нигез буларак танылса) керә.

3 статья. Әлеге Законның гамәлдә булу чикләре.

Әлеге Закон буенча судлар гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен боза торган теләсә кайсы эшләргә (карарларга) карата булган шикаятьләрне карыйлар (түбәндәгеләрдән тыш):

Россия Федерациясенең Конституцион Суды карамагында гына тикшерелергә тиешле эшләр (карарлар);

судка шикаять бирүнең закон буенча башка тәртибе каралган эшләр.

4 статья. Шикаять бирү.

Гражданин үзенең хокукларын һәм ирекләрен бозучы эшләргә (карарларга) карата шикаять белән турыдан-туры судка яки буйсыну тәртибендә югары дәүләт органына, җирле үзидарә органына, учреждение, предприятие яки иҗтимагый берләшмәгә, урындагы кешегә, дәүләт хезмәткәренә мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Буйсыну тәртибендәге югары орган, берләшмә, урындагы кеше шикаятьне бер ай срок эчендә карарга тиеш. Әгәр гражданнның шикаятен канәгатьләндерү кире кагылган, яки ул аңа бер ай дәвамында җавап алмаган икән, аның судка шикаять бирергә хокукы бар.

Шикаятьне хокуклары бозылган граждан яки аның вәкиле, шулай ук гражданның үтенече буенча иҗтимагый оешманың, хезмәт коллективының вәкаләтле вәкиле бирергә мөмкин.

Шикаять гражданның ихтыяры буенча яшәү урынындагы судка яки орган, берләшмә, урындагы кеше, дәүләт хезмәткәре урыны буенча судка бирелә.

Хәрби хезмәткәр әлеге статьяда каралган тәртиптә хәрби судка үзенең хокукларын һәм ирекләрен бозган хәрби идарә органнарының һәм урындагы хәрби кешеләрнең эшләренә (карарларына) карата шикаять бирергә хокуклы.

Шикаятьне кабул иткәч, судның граждан үтенече буенча яки үз инициативасы белән шикаять бирелгән эшләрне (карарларны) туктатып торырга хокукы бар.

Шикаять биргән өчен билгеләнгән күләмдә пошлина (дәүләт җыемы) түләнә. Суд гражданны җыем түләүдән азат итә яки аның күләмен кечерәйтә ала.

5 статья. Судка шикаять бирү сроклары.

Судка шикаять бирү өчен түбәндәге сроклар билгеләнә:

гражданга аның хокуклары бозылу билгеле булган көннән алып өч айга кадәр;

гражданның югары органнан, берләшмәдән, урындагы кешедән аның шикаятен канәгатьләндерү кире кагылганлык турында белдерү кәгазе алу көненнән яисә шикаять бирелгән көннән соң бер ай үткәч (әгәр граждан язма җавап алмаган булса). Нигезле сәбәп буенча узып киткән шикаять бирү срогы суд тарафыннан торгызылырга мөмкин. Әлеге Законның 2 статьясында каралган, шикаять бирелгән эшләр (карарлар) һәм аларның нәтиҗәләре турында мәгълүмат алуны кыенлаштырган теләсә кайсы шартлар нигезле сәбәп дип атала.

6 статья. Шикаятьне карау тәртибе.

Гражданның дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, учреждениеләр, предприятиеләр һәм аларның берләшмәләре, иҗтимагый берләшмәләр, урындагы кешеләр, дәүләт хезмәткәрләре эшләренә (карарларына) карата шикаяте суд тарафыннан гражданлык суды кагыйдәләре буенча әлеге Закон билгеләгән үзенчәлекләрне исәпкә алып карала.

Граждан тарафыннан эшләренә (карарларына) карата шикаять бирелгән дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына, учреждениеләргә, предприятиеләргә һәм аларның берләшмәләренә, иҗтимагый берләшмәләргә, урындагы кешеләргә, дәүләт хезмәткәрлә-

ренә шикаять бирелгән эшләрнең (карарларның) законлылыгын документаль төстә раслау буенча процессуаль бурыч йөкләнә; граждан шикаять бирелгән эшләрнең (карарларның) законсызлыгын раслау бурычыннан азат ителә, ләкин ул үзенең хокукларының һәм ирекләренең бозылу фактын расларга тиеш.

7 статья. Шикаять буенча суд карары.

Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча суд карар чыгара.

Шикаятьнең нигезлелеген билгеләп, суд шикаять бирелгән эшнең (карарның) законсыз икәнлеген таный, гражданның таләбен канәгатьләндерү бурычын йөкли, аңа карата кулланылган җавапка тарту чараларын юкка чыгара яисә башка юл белән аның бозылган хокукларын һәм ирекләрен торгыза.

Шикаять бирелгән эш (карар), әгәр ул законның 2 статьясында күрсәтелгән нәтиҗәләргә китерә икән, законсыз дип таныла.

Шикаятьнең нигезле икәнлеген раслап, суд дәүләт органының, җирле үзидарә органының, учреждениенең, предприятие яки берләшмәнең, иҗтимагый берләшмәнең яки урындагы кешенең, дәүләт хезмәткәренең гражданның хокукларын һәм ирекләрен бозуга китергән эшләре (карарлары) өчен җаваплылыгын билгели.

Законсыз дип табылган эшләр кылган (карарлар кабул иткән) дәүләт хезмәткәрләренә карата суд «Россия Федерациясенең дәүләт хезмәте нигезләре турында»гы Федераль закон һәм башка федераль законнар нигезендә дәүләт хезмәткәренең җаваплылык дәрәҗәсен билгели, ул эштән азат итүгә кадәр барып җитәргә мөмкин. Җаваплылык эшләре (карарлары) законсыз дип табылганнарга да, әлеге Законның 2 статьясында күрсәтелгәнчә, законсыз эшләр (карарлар) өчен нигез булган мәгълүмат бирүчегә дә бер төрле йөкләнә.

Гражданга законсыз дип табылган эшләр (карарлар), шулай ук ялган мәгълүмат китергән зарар, мораль зыян Россия Федерациясенең Гражданлык Кодексы билгеләгән тәртиптә каплатыла.

Әгәр шикаять бирелгән эшне (карарны) суд законлы дип, гражданның хокукларын һәм ирекләрен бозмый дип таба икән, ул шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тарта.

8 статья. Суд карарын үтәү.

Закон көченә кергән суд карары барлык дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, учреждениеләр, предприятиеләр һәм аларның берләшмәләре, иҗтимагый берләшмәләр, урындагы кешеләр, дәүләт хезмәткәрләре һәм гражданнар өчен мәҗбүри һәм Россия Федерациясенең барлык территориясендә үтәлергә тиеш.

Суд карары тиешле органга, берләшмәгә яки урындагы кешегә, дәүләт хезмәткәренә, шулай ук гражданга карар закон көченә кергәннән алып ун көннән дә соңга калмыйча җибәрелә.

Карарның үтәлеше турында судка һәм гражданга суд карарын алган көннән алып бер айдан да соңга калмыйча хәбәр ителергә тиеш. Карар үтәлмәгән очракта суд Россия Федерациясе законнары тарафыннан каралган чараларны күрә.

9 статья. Шикаятьне карау белән бәйле суд чыгымнарын бүлү.

Шикаятьне карау белән бәйле суд чыгымнары, әгәр суд шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тарту турында карар кабул итә икән, гражданның үзенә йөкләнә, әгәр өсләреннән шикаять бирелгән эшләр законсыз дип табылса, дәүләт органына, җирле үзидарә органына, учреждение, предприятие яки берләшмәгә, иҗтимагый берләшмәгә, урындагы кешегә, дәүләт хезмәткәренә йөкләнә.

Әгәр гражданның буйсыну тәртибендә югары торучы органга, берләшмәгә, урындагы кешегә бирелгән шикаяте җавапсыз калса яки җавап әлеге Законның 4 статьясында билгеләнгән срокны бозып бирелсә, суд аларның эшләрен (карарларын) законлы дип тапкан

очракта да суд чыгымнары дәүләт органына, җирле үзидарә органына, учреждениегә, предприятиегә яки берләшмәгә, иҗтимагый берләшмәгә яки урындагы кешегә, дәүләт хезмәткәренә йөкләтелә.

Россия Федерациясе Президенты
Б. Ельцин.

Мәскәү, 1993 елның 27 апреле.

* * *

СУДКА ШИКАЯТЬ БЕЛДЕРЕП ГАРИЗА ЯЗУНЫҢ КАЙБЕР ҮРНӘКЛӘРЕ

Намусны һәм кешелек дәрәҗәсен яклау турындагы дәгъва гаризасы үрнәге

Татарстан Республикасының ... район судына

Дәгъвачы: Казан шәһәре, Клубничная урамы, 5 нче йорт, 11 нче фатирда яшәүче Сабир Сабир улы Сабиров

Җавап тотучы: (оешма исеме яки фамилиясе, исеме, атасының исеме, адрес)

Намусны һәм кешелек дәрәҗәсен яклау турында дәгъва гаризасы

(дәгъвачы фикеренчә, аның намусын һәм кешелек дәрәҗәсен хурлаучы мәгълүматларның кайчан, кем тарафыннан, кайда таратылганын, бу мәгълүматларның нидән гыйбарәт булганлыгын һәм аларның ни өчен дөреслеккә туры килмәгәнлеген күрсәтергә, әйтелгәннәрне раслаучы дәлилләр китерергә мөмкин)

Гражданлык кодексының 15 статьясы нигезендә түбәндәгеләрне үтенәм:

минем намусымны һәм кешелек дәрәҗәмне хурлаучы мәгълүматларны кире кагуыгызны (мәгълүматларның характерын һәм аларны кире кагу тәртибен күрсәтергә). Дәгъваны раслау өчен судка шаһитлар чакыруыгызны (фамилияләре, исемнәре, аталарының исемнәре, адреслары).

Өстәмә:

1. Дәгъвачыдагы аны хурлаучы мәгълүматлар таралуын раслаучы дәлилләр
2. Дәүләт пошлинасы маркасы (квитанциясе).
3. Дәгъва гаризасының күчермәсе.

Имза.

Дата.

Искәрмә: мәсәлән, газета яки журнал кисемтәсе, утырыш беркетмәсе, хат һ. б. лар дәлил булырга мөмкин. Мәгълүматларны таратучы аларның дөреслеккә туры килүен дәлилләргә тиеш.

* * *

Эшкә кире кайтару турында дәгъва гаризасы үрнәге

Татарстан Республикасы ... район судына

Дәгъвачы: Сабир Сабир улы Сабиров (адресы — Казан шәһәре, Клубничная урамы, 5 нче йорт, 11 нче фатир)

Җавап тотучы: (оешма исеме, адрес)

Эшкә кире кайтару һәм мәҗбүри прогул вакыты өчен түләү турында дәгъва гаризасы

Мин (число, ай, елны күрсәтергә) дән башлап (предприятие, оешма, учреждение исемен күрсәтергә) дә (вазифаңны, башкарыла торган эшне күрсәтергә) булып эшләдем. ...нче номерлы боерык белән (число, ай, елны күрсәтергә) нән эштән азат ителдем (азат ителүнең нигезен күрсәтергә).

Азат ителүемне законсыз дип исәплим (дәгъвачы фикеренчә законсыз дип исәпләнгән шартларны күрсәтергә, мөмкин булса, алда әйтелгәннәрне раслау өчен дәлилләр китерергә).

(число, ай, ел) дан башлап эшләмим.

РСФСР КЗоТының 213, 214 статьялары нигезендә үтенәм:

1. Мине (вазифа, башкарыла торган эш) эшемә (предприятие, учреждение, оешма исеме) кире кайтаруыгызны.

2. (число, ай, ел) дән алып эшкә кире кайтарылганга кадәрге мәҗбүри прогул вакытына минем файдага уртача хезмәт хакымны (предприятие, учреждение, оешма исеме) дән мәҗбүри түләтүегезне.

Дәгъваны раслау өчен судка шаһитлар чакыруыгызны (фамилияләре, исемнәре, аталарының исемнәре, адреслары).

Өстәмә:

1. Эшкә алу турындагы боерыкның күчермәсе.

2. Эштән азат итү турындагы боерыкның күчермәсе.

3. Азат итүгә ризалык бирү турында профсоюз комитеты утырышы беркетмәсе.

4. Соңгы ике календарь аенда эшләгән өчен хезмәт хакының күләме турында белешмә.

5. Дәгъва гаризасының күчермәсе.

Имза.

Дата.

Хокукый төшенчәләр һәм атамаларның кыскача сүзлеге

Мәктәпләрдә, бигрәк тә авыл җирләрендә, хәзерге заман юридик сүзлекләрен табу кыен булганга, без махсус хокукый төшенчәләр һәм атамалар сүзлеген бирергә булдык (берничә ел элек кенә чыккан сүзлекләр дә инде искерде — кайбер дәүләт һәм хокук төшенчәләре турындагы күзаллаулар да бик тиз үзгәрә). Сүзлек юридик тематикага беренче мәртәбә мөрәҗәгать итүче укучылар өчен ярдәмче материал булыр һәм, һичшиксез, уку материалын үзләштерүне, законнар турындагы язмалардан һәм юридик әдәбияттан файдалануны җиңеләйтер.

Әлеге сүзлектә китерелгән юридик терминнар һәм атамаларны да, аларга бирелгән аңлатмаларны да тулысынча дип әйтеп булмый. Анда хокук фәнендә һәм практикада иң еш кулланыла торган төп төшенчәләр һәм атамалар гына бирелгән. Шуңа күрә дә ул кыскача дип атала. Шулай да әлеге сүзләрне без юридик текстларны аңлар өчен җитәрлек дип исәплибез. Аңлатмаларны мөмкин кадәр кыска һәм мәктәп укучылары өчен аңлаешлы итеп бирергә тырыштык.

Автономия (грекча autonomia сүзеннән — үзидарә, бәйсезлек) — бердәм, кагыйдә буларак, федератив дәүләт кысаларындагы сәяси-милли оешмаларның үзидарәсе формасы. Автономияле территориаль берәмлек үзәк хакимият тарафыннан куелган чикләрдә җирле мәсьәләләрне мөстәкыйль хәл итә.

Адвокат (латинча advoco сүзеннән — чакырам, өндим) — адвокатлар коллегиясе әгъзасы. Россиядә һәм Татарстанда адвокатура — законда каралганча җинаять эшләре буенча суд яклавын һәм гражданлык эшләре буенча якларның вәкиллеген тормышка ашыручы, гражданнарга һәм оешмаларга (предприятиеләргә, учреждениеләргә) башка юридик ярдәм күрсәтүче затларның ирекле оешмасы.

Административ җаваплылык — административ гаеп эш өчен җаваплылык.

Административ хокук бозу (гаеп эш) — дәүләт идарәсе өлкәсендәге хокук нормаларын бозучы иҗтимагый зарарлы, хокукка каршы юнәлтелгән гаеп эш.

Административ акт — дәүләт идарәсе органының конкрет мәсьәлә буенча, әйтик, район администрациясе башлыгының фатирга ордер бирүе турында карары.

Акт — 1) гамәл, эш; 2) документ, закон.

Алиби (латинча alibi сүзеннән — кайдадыр башка урында) — гаепләнүченең (шикле кешенең) җинаять эшләнгән вакытта бүтән урында булганлыгы һәм шуңа күрә әлеге җинаятьтә катнаша алмавы сәбәпле, аның гаепсез икәнлегенә дәлил.

Алимент (латинча alimentum сүзеннән — туклану, асрау) — яшәү өчен средство бирү.

Амнистия (грекча amnestia сүзеннән — оныту, гафу итү) — югары хакимиятнең җинаять кылучыларга карата булган һәм аларны җәзадан азат итүче (тулысынча яки өлешчә), җәзаны йомшартучы, җинаять эзәрлекләвен юкка чыгаручы, җәза срогын тутырган яки аннан азат ителгән затларның хөкем ителергә тиеш түгеллеген раслаучы акты; билгеле бер җинаять төрләренә карата кулланыла. Россия Федерациясендә Дәүләт Думасы, Татарстан Республикасында Дәүләт Советы тарафыннан тормышка ашырыла.

Арбитраж (французча arbitrage сүзеннән) — эшкуарлар, учреждениеләр арасындагы хуҗалык (гражданлык-хокукый) бәхәсләрен хәл итә торган махсус дәүләт органы.

Бергә катнашу (җинаятьтә) — ике яки аннан күбрәк затның бергә торып бергәләп җинаять кылуы.

Бурычлы кеше — хокукый мөнәсәбәттә катнашырга йөкләмә алган кеше, ул бу мөнәсәбәттә катнашучы икенче бер кеше — кредитор — файдасына билгеле бер гамәл кылырга тиеш.

Бурыч (гражданлык хокукында) — әчтәлеге бер затның (бурычлы) аннан үзенең бурычларын үтәүне таләп итәргә хокуклы булган икенче зат (кредитор) файдасына билгеле бер гамәл кылу бурычы булган гражданлык-хокукый мөнәсәбәт.

Бәлагә таручы — хокуксызлык гамәлләреннән зыян күргән зат.

Бүләк итү — гражданлык хокукында милекне бер кешедән икенчесенә бушлай күчерү турындагы бер яклы килешү; закон тарафыннан каралган очракларда нотариаль расланырга тиеш.

Васыятьнамә — мирас калдыручының үзе үлгән очракта милке турында тиешле формада эшләнгән күрсәтмәсе, юридик мәгънәгә ия.

Гаеп — кешенең үзенең хокук бозуына, кылган гамәлләренә, аларның иҗтимагый-куркыныч яки зарарлы нәтиҗәләренә психик мөнәсәбәте. Начар ният яки саксызлык формасында чагыла.

Гаепләү — компетентлы органнарның һәм затларның суд каршында кемнең дә булса җинаять кылуда гаепле икәнлегенә һәм аның нигезләрен, шулай ук җинаять җаваплылыгын һәм җәзаны билгеләүгә юнәлтелгән процессуаль эшчәнлеге. «Гаепләү» термины шулай ук гаепләүче тәгъбирләгән карашлар эчтәлегенең үзен дә белдерә — бу мәгънәдә гаепләү-

не, гаепләүнең расланганлыгын яки гаепләүнең үзгәргәнлеген белдерү турында әйтәләр.

Гаепләнүче — җинаять җаваплылыгына тартылган һәм җинаять кылуда гаепләнгән физик зат.

Гадәт — кагыйдә, озакка сузылган иҗтимагый практика нәтиҗәсендә барлыкка килгән нәрсәләр ныгытылган тәртип формасы. Гадәт ыруглык строе шартларында иҗтимагый мөнәсәбәтләрне төп көйләү чарасы булган.

Гипотеза — хокукый норманы куллану шарты.

Гражданнарның төп бурычлары — гражданнарның Конституциядә беркетелгән гомуми һәм иң мөһим бурычлары. Төп бурычлар исәбенә Конституцияне һәм законнарны үтәү, намуслы хезмәт итү, башка кешеләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен саклау һ. б. бурычлар керә.

Гражданнарның төп хокуклары — гражданнарның конституцион законнарда беркетелгән гомуми һәм иң мөһим хокуклары; Россиядә һәм Татарстанда гражданнарның төп хокуклары һәм ирекләре РФ Конституциясендә һәм ТР Конституциясендә беркетелгән. Гражданнарның төп хокуклары исәбенә түбәндәгеләр керә: хезмәткә хокук, ял итүгә хокук, сәламәтлекне саклауга хокук, картлыкта, авырган очракта, хезмәткә сәләтлелекне тулысынча яки өлешчә югалтканда, шулай ук туендыручыны югалтканда матди тәэмин ителүгә хокук, торакка хокук, белем алуга хокук һ. б. хокуклар һәм ирекләр, шул исәптән сәяси һәм шәхси хокуклар. Конституция игълан ителгән хокукларның һәм ирекләрнең гарантияләрен билгели һәм хокукларны һәм ирекләрне тормышка ашыруның гражданның үз бурычларын үтәүдән аерылгысыз икәнлеген күрсәтә.

Гражданнарның хокукый статусы — гражданнарның дәүләттәге фактик хәлен юридик чагылдыру һәм беркетү; үз эченә хокуклылыкны, төп хокукларны һәм бурычларны ала; сүз оешмаларның, учреждениеләр, дәүләт органнары, урындагы кешеләрнең, аларның хокуклары һәм бурычларының җыелмасы буларак, хокукый статусы турында да барырга мөмкин.

Гражданлык хокуклары — гражданның илнең сәяси, социаль һәм мәдәни тормышында катнашу мөмкинлеген билгеләүче хокукый статусы.

Гражданлык кодексы (ГК) — гражданлык хокукы нормаларының билгеле бер системасын эченә алган бердәм закон акты.

Гражданлык җәмгыяте — шундый җәмгыять ки, анда гражданнарның төрле берләшмәләре (партияләр, профсоюзлар, кооперативлар, төркемнәр) кеше һәм дәүләт арасындагы элемтәне тормышка ашыра һәм дәүләткә шәхесне узурпацияләргә ирек бирми.

Гражданлык-хокукый җаваплылык — гражданлык-хокукый гаеп өчен җаваплылык.

Гражданлык — физик затның билгеле бер дәүләтнеке булуы, моннан әлеге затның юридик хокуклары һәм бурычлары җыелмасы (хокукый статус) килеп чыга; гражданлыкның нигезе, аны алу һәм югалту тәртибе закон белән билгеләнә.

Гаепсезлек презумпциясе — суд эшчәнлегенең шәхеснең гаепсезлеген фараз итүгә нигезләнгән төп принципларының берсе, икенче төрле әйткәндә, теләсә кайсы гражданны, әгәр закон белән билгеләнгән тәртиптә башкасы расланмаса, гаепсез дип тану; киң мәгънәдә — җинаять җаваплылыгына тартылган затның суд хөкеме буенча гына гаепле дип исәпләнүеннән гыйбарәт булган законлылыкны таләп итү. Гаепсезлек презумпциясе — гаепсез затның гаепләү расланмаганда хөкем ителмәячәген гарантияләүнең берсе; гаепләнүченең гаебен дәлилләү җитәрлек булмаганда, җинаять эше туктатылырга яисә аклау карары чыгарылырга тиеш.

Гаилә хокукы — никахка керү, никахны өзү һәм аны гамәлдән чыгару шартларын һәм тәртибен билгеләүче, гаилә әгъзалары, башка туганнар һәм затлар арасындагы мөлкәткә бәйләнмәгән шәхси мөнәсәбәтләрне һәм мөлкәткә бәйле мөнәсәбәтләрне көйләүче, шулай ук ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларны гаиләгә урнаштыру формаларын һәм тәртибен билгеләүче хокук нормалары җыелмасы.

Дактилоскопия — шәхесне кул бармаклары очындагы соңгы фаланганың уч төбе өслегендәге папилляр челтәре буенча ачыклау; криминалистик тикшеренү эшендә кулланыла.

Дәүләт — буйсындыру һәм идарә итү аппаратына ия булган, үз боерыкларына илнең бөтен халкы өчен мәҗбүрилек көче бирә торган һәм суверенитетка ия булган үзенә бер төрле сәяси оешма. Җәмгыятьнең сәяси системасының төп институты. Аның белән идарә итүне, саклауны һәм аның икътисади-социаль төзелешен тәэмин итүне тормышка ашыра.

Дәлил — 1) дәлилләү фактлары, ягъни эш буенча җентекле тикшерелергә тиешле шартларны билгеләүче яисә кире кагучы фактлар; 2) дәлилләү чаралары, ягъни тикшерү органнарының һәм судның дәлилләү фактларын, мәсәлән, шаһитлар биргән мәгълүматларны ала торган чыганаклар.

Дәгъва — дәгъвачының судта яки арбитражда җавап тотучыга куелган таләбе — гражданнарның һәм оешмаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен суд яклавы чарасы.

Дәгъва гаризасы — бозылган яки бәхәсле хокукны яклауны сорап, язма формада судка мөрәҗәгать итү; билгеле бер кагыйдәләр буенча төзелә һәм анда билгеле бер реквизитлар булырга тиеш.

Дәгъвачы — судка яки арбитражга, үзенең хокукын яклауны сорап, гариза белән мөрәҗәгать итүче физик яки юридик зат.

Дәүләт механизмы (дәүләт аппараты) — дәүләт функцияләрен башкаруны, җәмгыятьнең максатларын тормышка ашыруны тәэмин итә торган органнар һәм учреждениеләр системасы.

Декларация (латинча declaratio сүзеннән — белдерү игълан итү) — 1) төп принципларны, программ положениеләрне игълан итүче хокукый документ; мәҗбүр итү көченә ия түгел, рекомендация булып исәпләнә (мәсәлән, Кеше хокукларының гомуми декларациясе); 2) чик аша кыйммәтле әйберләрне алып чыкканда таможняга бирелә торган гариза (таможня декларациясе); 3) салым түләргә тиешле кешенең үзенең кереме, милкәте турындагы гаризасы (салым декларациясе).

Демократия (грекча demos — халык һәм kratos — хакимият сүзләреннән) — халык хакимияте дигән сүз. Халык тарафыннан кабул ителүгә нигезләнгән дәүләт формасы, халыкның, гражданлык хокукларына һәм ирекләренә ярашлы рәвештә, дәүләт эшләрен хәл итүдә катнашу хокукы.

Дискриминация (латинча discriminatio — аеру дигән сүз) — билгеле бер категориядәге гражданнарның хокукларын раса һәм милли сыйфатлары буенча чикләү яисә алардан мәхрүм итү.

Диспозиция — хокук нормасында тәгъбир ителгән тәртип кагыйдәсе.

Дисциплина (латинча disci plina сүзеннән — тәрбия, укыту) — кешеләрнең үз-үзләрен тотышларының җәмгыятьтәге хокук (һәм әхлак) нормаларына, шулай ук теге яки бу оешма таләпләренә туры килә торган билгеле бер тәртибе.

Дисциплинар җаваплылык — хезмәткәрнең хезмәт вазифасын бозган өчен җаваплылыгы, хезмәт дисциплинасын бозучыга йөгынты ясауның хокукый нормаларының берсе.

Дәүләт формасы — идарә итү, дәүләт төзелеше һәм сәяси режим формасы буенча дәүләт хакимиятен оештыру.

Дәүләт функцияләре — дәүләтнең җәмгыятьне идарә итүенең асылын һәм социаль максатын чагылдыручы эчке һәм тышкы эшчәнлек юнәлешләре.

Дәүләт теле (рәсми тел) — законнарда һәм рәсми эш башкарганда, суд эшчәнлегендә, укытуда һ. б. да кулланыла торган төп тел. Конституциядә билгеләнә. Россия Федерациясенең дәүләт теле булып — рус теле, Татарстан Республикасында татар һәм рус телләре исәпләнә.

Дәүләт идарәсе — юридик әдәбиятта һәм законнарда еш кына тиешле дәүләт органнарының башкару-оештыру эшчәнлеге кебек тар, махсус мәгънәдә кулланыла; Россия Федерациясе Конституциясе буенча Россия дәүләт хакимиятенең югары башкаручы һәм оештыручы органы булып — Россия Министрлар Кабинеты, ә Татарстан Республикасы Конституциясе буенча Татарстан Министрлар Кабинеты исәпләнә;

киң мәгънәдә бу — дәүләтнең һәм аның теләсә кайсы органының эшчәнлеге, социаль идарәнең аерым бер төре.

Дәүләт төзелеше — бөтенлеге дәрәҗәсе ягыннан караганда, дәүләтнең территориаль төзелеше, аның состав өлешләре арасындагы, шулай ук аларның һәркайсының дәүләт белән ике арадагы үзара мөнәсәбәтләренең характеры. Унитар һәм федератив (берничә дәүләттән тора торган союздаш) дәүләтләр була.

Дәүләт суверенитеты — дәүләт хакимиятенең илнең эчендә һәм тышында һәртөрле башка хакимияттән (сәяси һәм идеологик) бәйсезлеге. Бәйсезлек хакимиятнең үзенең барлык эшләрен мөстәкыйль һәм ирекле, монополияле хәл итүгә хокуклы булуында чагыла. Шул ук вакытта суверенитет башбаштаклык, хаксыз гамәлләр өчен нигез була алмый.

Закон — дәүләт хакимиятенең югары вәкиллекле органының хокук нормалары булган норматив-хокукый акты (Россия Федерациясендә — Федераль Җыелышның, Татарстан Республикасында — Дәүләт Советының). Закон югары юридик көчкә ия һәм гражданның, җәмгыятьнең, дәүләтнең иң әһәмиятле мәнфәгатьләрен көйләүгә юнәлтелгән.

Законлылык — 1) законнарның төгәл һәм тайпылышсыз үтәлүе; Россия һәм Татарстан Конституцияләре буенча дәүләт эшчәнлеге принцибы һәм гражданнарның төп бурычларының берсе булып тора; 2) теләсә кайсы иҗтимагый мәгънәгә ия эшчәнлектә закон өстенлек итә торган режим; законлылык — демократиянең зарури элементы. Россиядә һәм Татарстанда законнарны барлык гражданнар, урындагы кешеләр, дәүләт һәм иҗтимагый оешмалар үтәргә тиеш. Законлылыкны Россия Федерациясенең Генераль прокуроры һәм федерация субъектларының аңа буйсынган прокурорлары, шул исәптән Татарстан Республикасы прокуроры, шулай ук шәһәр һәм район прокурорлары үзләренең югары дәрәҗәдәге күзәтүләре астында тоталар.

Законнар җыелмасы — тар мәгънәдә — илдәге гамәлдә булган барлык законнарның җыелмасы; киң мәгънәдә — дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнарының барлык норматив-хокукый актлары. Россиядәге законнар җыелмасы — хокук чагылышының төп формасы, аның төп чыганагы, илдәге законлылыкның зарури алшарты.

Закон проекты — кабул итәргә тәкъдим ителә торган законның тексты.

Законнарны системалаштыру — законнарны тәртипкә салу буенча дәүләт органнары тарафыннан үткәрелә торган эшчәнлек.

Зат — гражданлык хокукында хокукый мөнәсәбәтләрдә катнашучы, хокук субъекты; физик һәм юридик затлар була.

Зарури саклану — җинаятьчел кул сузудан законлы саклану; һөҗүм итүчегә зыян салырга мөмкин, ләкин зарури

саклану чикләрен узарга ярамый. Җинаять җаваплылыгына юл калдырмый.

Законлы тәртип — бу хокук субъектларының хокук нормаларына туры килә торган тәртибе (гамәле).

Идарә итү формасы — югары дәүләт хакимиятен оештыру (югары хакимият һәм идарә органнары төзелеше, аларның оешу, эшчәнлек һәм халык белән үзара мөнәсәбәте тәртибе). Монархияләр һәм республикалар була.

Иҗтимагый куркынычлылык — гамәлнең куркынычлылыгы, җинаятькә хас, формаль булмаган төп сыйфат.

Казус — катлаулы, буталчык очрак.

Кассация — түбәндә торучы судның закон көченә кермәгән хөкем карарларын һәм билгеләмәләрен югары инстанциядәге судның яңадан каравы, алардан ризасызлык белдерүе.

Кодекс — хокукның нинди дә булса тармагына карый торган нормасын системалы тәгъбирләүне үз эченә алган бердәм законнар акты (Хезмәт турындагы законнар кодексы — КЗоТ. Гражданлык кодексы — ГК, Гаилә кодексы — ГК, Җинаять кодексы — ҖК, Җинаять процессуаль кодекс — ҖПК һ. б.). Законнарны кодификацияләү нәтиҗәсе. Бердәм закон актыннан файдалану җиңелрәк һәм гадирәк, шуңа күрә хокукның кабат барлыкка килгән тармаклары кодификацияләүне таләп итә (мәсәлән, салым законнары).

Кодификация — законнарны системалаштыру ысулының берсе, инкорпорациядән аермалы буларак, хокукый көйләүнең эчтәлеге үзгәрү белән бәйләнгән: хокук системасы тармаклары буенча кодификация иң камил дип исәпләнә.

Коллектив килешү — предприятие дәрәҗәсендә социаль партнерлар — хезмәт коллективы (хезмәткәрләр), профсоюз органы һәм эш бирүче (администрация) тарафыннан эшләнә һәм кабул ителә торган килешү. Анда хезмәт хакы мәсьәләләре, эш вакыты, ял вакыты, хезмәткә түләү һ. б. буенча төп положениеләр, килешүче якларның үзара бурычлары билгеләнә.

Компетенция (латинча competo сүзеннән — ирешәм, туры киләм) — теге яки бу органның яисә урындагы кешенең барлык хокуклары һәм бурычлары җыелмасы. Компетенция закон, положение яки устав белән билгеләнә.

Конвенция (латинча conventio сүзеннән — килешү, шартнамә) — кагыйдә буларак нинди дә булса аерым бер мәсьәлә буенча төзелгән халыкара шартнамә; аңа кушылган (кул куйган, раслаган) дәүләтләр өчен мәҗбүр итү көченә ия. Эчтәлеге бер төрле булмаган конвенция тагын пакт дип атала.

Конституция (латинча constitutio сүзеннән — урнаштыру, төзелеш) — дәүләтнең, аның иҗтимагый һәм икътисади строе нигезләрен, идарә итү һәм дәүләт төзелеше формасын, шәхеснең хокукый хәлен, үзәктә һәм урыннарда хакимият органнарын һәм идарә итүне оештыру тәртибен, суд эшчәнле-

ген, сайлау системасын оештыруны һәм аларның мөһим принципларын беркетүче төп законы. Агымдагы закон чыгару эшенең юридик базасы. Юридик кына түгел, сәяси әһәмияткә дә ия. Россия Федерациясе Конституциясе референдум нәтиҗәсендә 1993 елның 12 декабрендә, ә Татарстан Республикасы Конституциясе 1992 елның 6 ноябрендә кабул ителде.

Кредитор — йөкләмәле хокукый мөнәсәбәтләрдә катнашучы, икенче бер катнашучыдан (бурычлы) тиешле бурычын түләүне (акча түләү, әйбер бирү, эш башкару һ. б.) таләп итәргә хокуклы.

Кеше хокуклары — шәхеснең тумыштан ия була торган аерылгысыз ирекләре һәм хокуклары.

Кулга алу — закон буенча чик куюның бер чарасы, дисциплинар җәза яки административ җаваплылык сыйфатында сак астына алу; аны тоткарлау һәм иректән мәхрүм итүдән аера белергә кирәк.

Күптәнлек — закон билгеләгән срок, аның узуы юридик нәтиҗәләргә китерә (мәсәлән, дәгъвага, карар яки хөкем карарын үтәүгә, җинаять эзәрлекләвенә хокукны югалту).

Милек — мөлкәткә ия булу, файдалану һәм эш итүнең оештыру һәм социаль формаларын характерлаучы икътисади һәм юридик мөнәсәбәтләр системасын билгеләү өчен файдаланыла торган категория.

Милиция — Россиядә һәм Татарстанда дәүләтнең иҗтимагый тәртипне, милекне, гражданнарның, предприятиеләрнең, оешмаларның һәм учреждениеләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен җинаятьчел кул сузулардан сакларга тиешле административ-башкарма органы. Милиция — Россия эчке эшләр органнары системасының состав өлеше.

Мирас итеп алу — үлгән кеше мөлкәтенең аның варисларына күчүе, закон яки васыять буенча булырга мөмкин.

Мөлкәт хокукы — 1) милек мөнәсәбәтләрен көйләүче юридик нормалар җыелмасы, бу гражданлык хокукы нормаларының әһәмиятле өлеше, законнарның башка тармакларының кайбер нормалары (мәсәлән, гаилә тармагының); 2) гражданнар һәм оешмаларның әйбергә хокуклары, йөкләмә хокуклары, хезмәт, авторлык, гаилә, уйлап табу хокуклары керә торган хокукларның бер төре.

Мөлкәт мөнәсәбәтләре — милек, ягъни акчалата бәяләмәгә ия булган уңайлыклар өлкәсендәге мөнәсәбәтләр.

Мәҗбүри китертү — гаепләнүче яки башка затны, тикшерү органы яки суд чакыруы буенча сәбәпсез килмәгән очракта, мәҗбүри алып килү.

Ният — гаеп формасы; турыдан-туры ният һәм читләтеп уйланган ният була. Турыдан-туры ният: кеше, җинаять кылганда, эшенең иҗтимагый-куркыныч нәтиҗәгә китерәчәген алдан күрә һәм аларны үзе тели; читләтеп уйланган ният:

кеше үзенең хәрәкәтләренең (хәрәкәтсезлегенең) иҗтимагый куркыныч нәтиҗәләргә китерәчәген алдан күрә, аларны теләми, әмма аңлы рәвештә юл куя. Ниятне саксызлыктан аерып карый белергә кирәк.

Нигилизм — гомумкабул ителгән кыйммәтләрне инкарь итү.

Норма (латинчадан) — үрнәк, тәртип кагыйдәсе. Бу тәртип үрнәге чикләнмәгән дәрәҗәдәге очракларда файдаланыла. Иҗтимагый мөнәсәбәтләргә карата нормалар социаль характер ала, ә процесс үзе норматив-социаль көйләү дип атала. Аның әһәмияте шунда, ул кешеләр тормышында бердәм, һәммәсе өчен дә уртак, даими яшәп килүче тәртип кертергә ярдәм итә.

Норматив акт (кайвакыт норматив-хокукый акт дип атыйлар) — вәкаләтле органның хокук нормаларын билгеләү, үзгәртү яки юкка чыгару турындагы акты; икенче төрле әйткәндә, юридик нормалары булган дәүләт-хакимият күрсәтмәсе. Хокук чыганагы булып тора.

Нотариат — юридик әһәмияткә ия булган килешүләрне, актларны һәм фактларны рәсмиләштерүче һәм раслаучы орган.

Никах — хатын-кызның һәм ир кешенең гаилә кору өчен төзелә һәм ир белән хатынның үзара хокукларын һәм бурычларын барлыкка китерә торган ирекле, тигез хокуклы берлеге.

Никах килешүе — никахка керүче затларның никахта торганда яки ул өзелгән очракта ир белән хатынның мөлкәт хокукларын һәм бурычларын билгеләүче килешү. Никах килешүе никахның дәүләт тарафыннан теркәлүенә кадәр дә, никахта торган чорның теләсә кайсы вакытында да төзелергә мөмкин. Никах килешүе язма формада була һәм нотариаль раслана.

Парламент (французча parler сүзеннән — сөйләргә) — халыкның төп сәяси актив төркемнәре вәкиллеген тормышка ашыручы, сайлап куела торган, закон чыгаручы югары орган. Россия Федерациясендә — Федераль Җыелыш, Татарстан Республикасында — Дәүләт Советы.

Пүнәтәй — тикшерү органнарының закон тарафыннан каралган гамәлләрен башкарганда шунда булу өчен чакырылган зат (мәсәлән, тентү яки мәҗбүри алу вакытында).

Попечительлек — хокукый сәләтлелекләре чикләнгән затларның хокукларын һәм мәнфәгатьләрен саклау формасы, аларның хокукларын һәм бурычларын тормышка ашыруда ярдәм итү. Ул 15 яшьтән 18 яшькәчә балигъ булмаганнар өчен химая (опека) кебек үк тәртиптә урнаштырыла. Попечительлек хокукый сәләтлелекләре суд тәртибендә чикләнгән затлар өчен дә урнаштырыла.

Преамбула — законның, башка норматив-хокукый актның (мәсәлән, Конституциянең) кереш өлеше.

Президент (латинча praesident сүзеннән — алда утыручы) — 1) хәзерге заманның республикачыл идарә итү формасы булган дәүләтләрендә сайланып куела торган дәүләт башлыгы; 2) кайбер иҗтимагый учреждениеләрдә һәм оешмаларда — башкаручы органның сайлап куела торган рәисе.

Прецедент (латинча praecedens сүзеннән — моннан алдагы) — охшаш ситуациядә дәлил итеп китерелә торган положение, хәл, карар; күп кенә илләрдә (ләкин Россиядә түгел) хокук чыганагы була ала.

Прогул — бөтен эш көне дәвамында сәбәпсез эшкә килмәү яки эштә исерек, наркотик яки токсинлы матдә кулланган хәлдә күренү.

Прокурор (латинча prokuro сүзеннән — кайгыртам, тәэмин итәм, кисәтәм) — законнарның төгәл үтәлүен күзәтүне тормышка ашыручы урындагы кеше. РФ Прокуратурасының югары урындагы кешесе — РФнең Генераль Прокуроры, Татарстанда — Татарстан Республикасы Прокуроры.

Протест (латинча protestor сүзеннән — белдерәм, раслыйм) — закон бозуларны бетерүдә төп чараларның берсе: 1) гомуми күзәтчелек тәртибендә — прокурорның нинди дә булса законсыз карарны юкка чыгаруны таләп итә торган акты; 2) суд күзәтчелеге тәртибендә бу — закон көченә кергән хөкем карарларын, карарларны, суд билгеләмәләрен кабат карау турындагы тәкъдим.

Республика (латинчада дәүләт эшләре, сәясәт дигән сүз) — дәүләттә хакимият бөтен гражданныкы яисә күпчелекнеке булган идарә итү формасы. Югары дәүләт хакимияте билгеле бер срокка сайлап куелган хакимият органнары тарафыннан тормышка ашырыла.

Референдум (латинчада хәбәр ителергә тиешле нәрсә дигәнне аңлата) — мөһим дәүләти яки иҗтимагый проблема буенча бөтен халыкның үз ихтыярын белдерүе (тавыш бирү яки сорау алу), гомуми тавыш бирү юлы белән нинди дә булса әһәмиятле закон кабул итү.

Сорау алу — җинаятьне тикшерүнең бер формасы.

Суд карары — гражданлык эше нәтиҗәсендә судның дәгъваны канәгатьләндерү (тулысынча яки өлешчә) яисә дәгъваны кире кагу турындагы мәсьәләне хәл итә торган карары.

Санкция (латинча sanctio сүзеннән — бик катгый карар) — 1) хокукый норманың аны бозган өчен җаваплылык билгеләүче элементы, 2) хокук бозучыга карата кулланылучы чара; 3) компетентлы орган тарафыннан нинди дә булса гамәлне, кагыйдәне, карарны раслау (санкцияләү). Мәсәлән, прокурорның кулга алуга санкциясе.

Сату-алу — гражданлык хокукы буенча — килешү, аның буенча бер як (сатучы) милекне икенче якка (сатып алучыга) бирергә, ә соңгысы бу милекне кабул итеп алырга һәм килешенгән сумманы түләргә йөкләмә ала.

Социаль тәэминат һәм социаль страхование — пенсия яшенә җиткән, шулай ук хезмәткә яраксыз (шул исәптән вакытлыча хезмәткә яраксыз) гражданнарны матди яктан тәэмин итү формасы.

Суверенитет — нинди дә булса көчләргә, шартларга һәм затларга бәйсез рәвештә мөстәкыйльлеккә хокук; барлык эчке тормыш мәсьәләләрен хәл итүдә һәм башка дәүләтләр белән үзара мөнәсәбәттә хакимиятнең өстенлек итүе, дәүләтнең бәйсезлеге һәм мөстәкыйльлеге.

Суд — гадел хөкемне тормышка ашыручы дәүләт органы. Судның гражданлык һәм җинаять эшләрен карау буенча эшчәнлеген гражданлык процессы һәм җинаять эшләре процессы тәшкил итә; беренчесе — гражданлык-процессуаль кодекс, икенчесе җинаять-процессуаль кодекс белән регламентлана.

Суд төзелеше — 1) суд системасын оештыру; 2) аны көйләүче юридик нормалар.

Салым — дәүләт бюджетына юридик яки физик зат тарафыннан тормышка ашырыла, закон тарафыннан регламентлаштырыла торган мәҗбүри түләү. Турыдан-туры һәм читләтеп, гомуми һәм үзенчәлекле, федераль, республика һәм җирле салымнар була.

Суд экспертизасы — тикшерү органнары яки җинаять эшләре өлкәсендә суд карары буенча эксперт тарафыннан тормышка ашырыла торган тикшерену; эксперт чыгарган нәтиҗә суд дәлилләренең бер төре. Экспертизалар гражданлык эшләре буенча да үткәрелергә мөмкин.

Сәяси система — бу дәүләт, сәясәт һәм җәмәгать органнарының, оешмаларның һәм учреждениеләрнең катлаулы җыелмасы, алар ярдәмендә сәясәт субъекты җәмгыятьтә үзенең хакимиятен тормышка ашыра.

Суд эшчәнлеге — гражданлык һәм җинаять эшләрен караудан гыйбарәт булган суд эшчәнлеге. Россиядә һәм Татарстанда суд эшчәнлегенең иң әһәмиятлеләре аларның Конституцияләрендә ныгытылган демократик принциплар нигезендә суд тарафыннан гына тормышка ашырыла.

Тоткарлау — җинаять кылуда шикләнелгән затны, җинаятьне туктату чарасы буларак, аның шәхесен ачыклаганчы яки төрмәгә япканчы, алдан вакытлыча сак астына алу. Тоткарлау вакыты 72 сәгатьтән артмаска тиеш.

Тулы хокуклылык — билгеле бер затның конкрет хокукый мөнәсәбәтләрдә катнашучы буларак конкрет хокукы.

Указ — хакимияткә ия булган дәүләт башлыгының, мәсәлән, президентның, хокукый акты.

Унитар дәүләт — үзләренең конституциясе, законнары, хөкүмәте булмаган территориаль дәүләт берәмлекләреннән торган дәүләт; аларда җирле идарә органнарын төзү өчен идарәчеләр билгеләнә.

Уллыкка алу (кызлыкка алу) — юридик акт, аның буенча уллыкка алынган бала һәм уллыкка алучы арасында, ата-ана һәм балалар арасындагы кебек, хокукый (шәхси һәм мөлкәт) мөнәсәбәтләр урнаштырыла.

Федерация субъектлары — Россия Федерациясе составындагы дәүләтләр (республикалар) һәм сәяси-территориаль берлекләр (крайлар, өлкәләр). Россиядә барлыгы 89 субъект бар: 21 республика, 6 край, 49 өлкә, федераль әһәмияткә ия булган 2 шәһәр, 1 автономияле өлкә һәм 10 автономияле округ.

Файдалануга алучы — мөлкәтне файдалануга алу килешүендә катнашучы, бу килешү буенча ул түләү нигезендә килешүнең икенче катнашучысы — файдалануга бирүченеке булган милектән файдаланырга хокуклы.

Федерация (латинчадан — берлек, союз дигән сүз) — дәүләт төзелеше формасы, яңа дәүләт төзү максатында оешкан дәүләтләр берлеге, анда федерациягә кергән берәмлекләр (республикалар, җирләр, штатлар, өлкәләр, губерналар) үзләренең хокукларының бер өлешен субъект буларак саклыйлар (үзләренең конституцияләренә яки уставларына, закон чыгаручы, башкаручы һәм суд органнарына ия булалар); шул ук вакытта барлык берәмлекләр өчен дәүләт хакимиятенең федераль органнары төзелә, бердәм гражданлык, акча берәмлеге һ. б. урнаштырыла.

Физик зат — юридик заттан хокук субъекты булуы белән аерылып торучы граждан. Билгеле бер дәүләт гражданнары белән беррәттән, физик затлар булып әлеге дәүләттә яшәүче чит ил гражданнары, шулай ук билгеле бер гражданлыгы булмаган затлар да исәпләнә. Физик затлар хокукка ия һәм хокукый сәләтле булалар.

Хакимият — кешеләрнең, социаль төркемнәрнең эшчәнлеге һәм үз-үзләрен тотышы сыйфатына һәм юнәлешенә йогынты ясарга сәләтле булуы белән характерлана торган социаль мөнәсәбәтләр формасы. Үз ихтыярыңны тормышка ашыру сәләте.

Хәбәрдарлык — суд эшләрен ачык суд процессында карау. Россия Федерациясе Конституциясендә беркетелгән суд эшчәнлеге принципларының берсе.

Хокук институты — хокук тармагы эчендә аерымланган һәм тиңдәш иҗтимагый мөнәсәбәтләрнең бер төрен көйләп торучы юридик нормалар җыелмасы (мәсәлән, милек институты, гражданлык институты һ. б.).

Хокук чыганагы — юридик практикада юридик нормаларны чагылдыру формасы (мәсәлән, закон, указ һ. б.).

Хокук системасы — илдә гамәлдә булган хокук, ул аның эчке бердәмлеге һәм аерым тармакларга бүленеше күзлегеннән чыгып карала; хокукның эчке төзелеше, аны үзара тәэсир итешүче элементларга бүлү.

Хокук субъекты — юридик нормалар нигезендә хокук мөнәсәбәтләрендә катнаша ала торган физик яки юридик затлар.

Хокукка аңлатма бирү — законның мәгънәсен ачыклау һәм аңлату.

Хөкем ителгәнлек (суд тарафыннан) — җинаять кылган өчен җинаять җәзасына хөкем ителгән зат өчен тудырылган хокукый халәт.

Хезмәт шартнамәсе (контракт) — хезмәт законнары буенча хезмәткәр һәм предприятие, учреждение, оешма арасындагы килешү; аның буенча эшче яки хезмәткәр билгеле бер эшне башкарырга, ә предприятие, учреждение, оешма аның күләме һәм сыйфаты буенча түләргә, шулай ук тиешле хезмәт шартлары белән тәэмин итәргә йөкләмә ала. Хезмәт шартнамәсе телдән булырга мөмкин, ләкин эшкә алу һичшиксез документаль формада — администрациянең боерыгы һәм хезмәт кенәгәсенә язу белән рәсмиләштерелергә тиеш.

Хезмәт бәхәсләре — хезмәт шартнамәсе яклары арасында хезмәт хокукларын һәм бурычларын урнаштыру һәм тормышка ашыру буенча килеп чыга торган бәхәсләр.

Хокук нормасы — хокук субъектының дәүләт тарафыннан кертелгән яки хупланган (санкцияләнгән) тәртип кагыйдәсе, ягъни дәүләт мәҗбүр итүе мөмкинлеге белән саклана торган һәм иҗтимагый мөнәсәбәтләрне көйләүгә юнәлтелгән күрсәтмә яки рөхсәт.

Химая (опека; гражданлык һәм гаилә хокукында) — дәүләт тарафыннан хокукый сәләтсез затның мәнфәгатьләрен һәм хокукларын яклауны оештыру һәм тормышка ашыру. Ул атаана кайгыртуыннан мәхрүм булган 15 яшькә кадәрге балигъ булмаганнар, зәгыйфь акыллылар һәм психик авырулар өчен оештырыла.

Хокук тармагы — билгеле бер төрдәге иҗтимагый мөнәсәбәтләрне көйләүче нормалар җыелмасы (мәсәлән, гражданлык хокукы, җинаятькә каршы көрәш хокукы); үзенең махсус хокукый ысулы ярдәмендә аерымланган һәм чагыштырмача тиңдәш хокук мөнәсәбәтләре өлкәсен көйләүче нормалар системасы. Законнарны хокук тармаклары буенча кодификацияләү шактый нык камилләшкән.

Хөкүмәт — дәүләтнең яисә аның субъектларының тулы хакимиятне тормышка ашыра торган башкарма хакимият органы. Вәкаләтләре гамәлдәге законнар белән билгеләнә.

Хокук — дәүләт тарафыннан урнаштырылган һәм үтәлүе дәүләт көче белән тәэмин ителә торган, һәркем өчен мәҗбүри булган тәртип нормалары системасы.

Хокук культурасы — хокукны тирәнтен белү һәм аңлау, аның күрсәтмәләренең кирәклеген тоеп, шәхеснең эчке ихтыяҗы буларак үтәү. Гомуми рухи культураның мөһим элементы.

Хокукый норма — дәүләтнең мәҗбүр итүе белән тәэмин ителгән гомуми мәҗбүри тәртип кагыйдәсе. Хокукның төрле чыганакларында була (законнарда, указларда һ. б.). Өч элементтан тора: гипотезалар, диспозицияләр, санкцияләр.

Хокукый дәүләт — демократик дәүләт, анда хокук хакимлеге, иҗтимагый мөнәсәбәтләрне көйләүнең төп принцибы буларак законның өстенлеге, барысының да (хакимиятнең, гражданның, җәмгыятьнең) закон һәм бәйсез суд алдында тигезлеге тәэмин ителә, кеше хокуклары һәм ирекләре икърар ителә һәм гарантияләнә, ә хакимиятне оештыру нигезенә хакимиятләрнең бүленү принцибы салына. Анда конституцион идарә режимы урнаша, нык үскән хокукый система һәм нәтиҗәле суд хакимияте яши. Хокукый дәүләт төшенчәсе безгә демократия шартларында дәүләт хакимияте тәртибенең бик әйбәт үрнәген бирә.

Хокук бозу — хокук тарафыннан саклана торган иҗтимагый мөнәсәбәтләргә зыян салучы, юридик җаваплылык китереп чыгаручы, хокукка каршы юнәлтелгән гаепле эш (хәрәкәт яки хәрәкәтсезлек).

Хокук мөнәсәбәте — иҗтимагый мөнәсәбәт, ул хокук нормалары, анда катнашучыларның хокукларын һәм бурычларын урнаштыру юлы белән көйләнә. Бу юридик нормаларны тормышка ашыру формасы, икенче төрле әйткәндә, гамәлдәге хокук.

Хокук тәртибе — җәмгыятьтә хокук нормалары белән көйләнә торган мөнәсәбәтләрнең аларны төгәл үтәүгә, законлылык принципларына нигезләнгән тәртибе. Хокук тәртибе дәүләт тарафыннан саклана.

Хокукый аң — аерым бер затның, социаль төркемнәрнең, сыйныфларның, милләтнең, халыкның күзаллаулары, карашлары, инанулары, идеяләре һәм хисләре җыелмасы, аларда юридик чынбарлыкка (гамәлдәге хокукка) билгеле бер мөнәсәбәт чагыла. Хокукый аңны хокукый психологиягә һәм хокукый идеологиягә, индивидуаль һәм иҗтимагый-хокукый аңга бүләләр; соңгы чиктә хокукый аң, иҗтимагый аңның барлык өлкәсе кебек үк, иҗтимагый чынбарлык — кешеләр тормышының матди шартлары, сәяси һәм бигрәк тә әхлакый аң, рухи культура белән тыгыз бәйләнгән. Хокук нормаларын билгеләүдә һәм тормышка ашыруда, суд эшчәнлеген башкаруда, законлылык һәм хокук тәртибе, юридик фән тормышында зур роль уйный. Хокукый аңда позитив (гамәлдәге) хокук турында гына түгел, билгеләнгән, билгеләнергә уйланган, тиеш яки мөмкин булган хокук турында да күзаллаулар бар.

Хокуклылык — затның хокук нормалары караган хокукларга һәм бурычларга ия булу сәләте. Гражданлык туган көннән яисә оешма төзелгән көннән башлана.

Хокукый көйләү предметы — иҗтимагый мөнәсәбәтләрнең хокукый көйләү юнәлтелгән билгеле бер өлкәсе.

Хокукый сәләтлелек — кешенең үзенең гамәлләре ярдәмендә хокукка ия булу һәм аны тормышка ашыру, юридик вазифаларны үз өстенә алу, шулай ук хокуксыз эшләре өчен юридик җаваплылыкны үз өстенә алу сәләте; психик авыруы булмаган очракта, хокукый сәләтлелеккә кеше билгеле бер яшьтә ия була; Закон буенча өлешчә хокукый сәләтлелек — 14—16 яшьтә, тулысынча 18 яшьтә башлана.

Хөкем карары — җинаять эше буенча хөкем ителүченең гаеплелеге һәм җазага тартылуы яисә аклануы турында суд карары.

Чиктән тыш зарурлык — куркынычлылыкны булдырмас өчен башка чаралар мөмкин булмаганда кулланыла торган гамәл.

Чик кую чарасы — гаепләнүченең тикшерүдән һәм судтан тайпылуын, җинаять эзләрен яшереп калуын һәм җинаять эшен дәвам итүен тоткарлау өчен мәҗбүр итү чарасы (мәсәлән, читкә китмәү турында кул кую яки сак астына алу).

Шартнамә — ике яки берничә затның нинди дә булса хокуклар һәм бурычлар кабул итү, үзгәртү һәм туктату турындагы килешүе.

Шикаять — учреждение яки урындагы кешенең, шикаять бирүче күзлегеннән караганда, законсыз һәм ялгыш эш итүләрен күрсәтеп, язмача яки телдән бирелгән гариза. Гражданнарның, урындагы кешеләрнең һәм оешмаларның эшеннән риза булмыйча, югары органнарга шикаять бирү хокукы Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы Конституцияләрендә беркетелгән. Шикаятьләрне карау тәртибе һәм сроклары закон белән көйләнә.

Шәхси хокуклар — мөлкәткә, шулай ук шәхестән аерылгысыз булган, мөлкәткә бәйсез социаль кыйммәтләргә (мәсәлән, исемгә, намуска һәм кешелек дәрәҗәсенә һ. б.) хокуклар; мөлкәткә бәйләнмәгән шәхси хокуклар аерылгысыз (кемгә дә булса күчерелә алмый).

Шәхеснең кагылгысызлыгы — Россия хокукы һәм Татарстан Республикасы хокукы буенча суд карары яки прокурор санкциясеннән башка беркемнең дә сак астына алына алмавын белдерә. Бу аларның Конституцияләрендә беркетелгән. Шулай ук торакның кагылгысызлыгы гарантияләнә һәм гражданнарның шәхси тормышының, хат язышу, телефоннан сөйләшү һәм телеграф белән хәбәр итешү серенең закон тарафыннан саклануы; шәхесне ихтирам итү, гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен саклау барлык дәүләт органнарының, җәмәгать оешмаларының, урындагы кешеләрнең бурычы икәнлеге; гражданнарның намусларына һәм кешелек дәрәҗәләренә, тормышларына һәм сәламәтлекләренә кул сузулардан суд яклавына, шәхси ирекә һәм милеккә хокуклары барлыгы билгеләнә.

Ышанычнамә — бер затның (ышанучы) икенчесенә (вәкил) өченче затларга күрсәтү өчен ышанучы исеменнән бирелә һәм билгеле бер юридик гамәлләр кылырга хокук бирә торган (мәсәлән, хезмәт хакын, посылканы алырга) документ. Ышанычнамә йорт идарәсендә (торак конторасында), эш яки уку урынында, район, шәһәр хакимиятендә, нотариуста раслана.

Эзләү — яшеренгән җинаятьчене, хәбәрсез югалган затны яки җавапка тартылучыны табу өчен оештырылган чаралар (закон тарафыннан каралган очракларда).

Югары куркынычлылык чыганагы — юридик затларның һәм гражданнарның файдаланган вакытта әйләнә-тирәдәгеләр өчен югары куркынычлылык тудыра торган машиналары, механизмнары һәм башка объектлар.

Юридик зат — закон белән расланган устав (положение) нигезендә үз исемнәреннән чыгыш ясау, үз бурычлары буенча мөстәкыйль җаваплылык алу хокукы булган төрле предприятиеләр, берләшмәләр, учреждениеләр, җәмәгать оешмалары. Юридик затлар сәүдә һәм сәүдәнеке булмаган оешмалар булырга мөмкин.

Юридик бурыч — бурычлы затның билгеле бер тәртибенең юридик зарурлыгы, аның белән ул, дәүләт мәҗбүр итүеннән куркып, тулы хокуклы зат мәнфәгатьләрендә эш итәргә тиеш.

Юридик җаваплылык — хокук бозганда гаепле затка карата кулланыла торган һәм аның өчен уңайсыз булган билгеле бер социаль нәтиҗәләр белән бәйле җәза бирү чарасы.

Юридик фактлар — хокук мөнәсәбәтләренең барлыкка килү, үзгәрү һәм тукталу шартлары булып исәпләнгән тормыш хәлләре. Юридик фактлар халәткә, вакыйгага (кеше ихтыярына бәйсез рәвештә барлыкка килә, мәсәлән, кар ишелмәсе астында үлү) һәм гамәлгә (бусы кешеләрнең аңына бәйле, аларның үз ихтыярларын белдерүе булып тора, мәсәлән, сату-алу килешүе төзү; гамәлләр законлы һәм законсыз булырга мөмкин) бүленә.

Юрисдикция (латинча jus — хокук, dicj — әйтәм сүзләреннән) — 1) гражданлык һәм җинаять эшләрен карау, хокукый мәсьәләләрне хәл итү вәкаләте; 2) тиешле органның күрсәтелгән юрисдикция вәкаләтләрен җәелдерү өлкәсен билгеләү.

Юрисконсульт (латинча jurisconsultus сүзеннән — хокук белгече) — безнең илдә предприятиеләрнең, учреждениеләрнең (нигездә дәүләтнеке), оешмаларның хокук эшләре хезмәткәре.

Юстиция (латинча justitia сүзеннән — гаделлек, гадел) — 1) юрисдикцияне тормышка ашыручы яки алар белән идарә итүче органнарның барлык җыелмасын белдерүче термин; 2) юрисдикцияне тормышка ашыручы органнар (судлар, арбитражлар) эшчәнлеген белдерүче термин.

Яклаучы — суд эшендә гаепләүне тулысынча яки өлешчә кире кагуга юнәлдерелгән гамәлләрне тормышка ашыру процессында катнашучы. Кагыйдә буларак, адвокат тарафыннан тормышка ашырыла.

Яла — җинаятьнең башка кеше тарафыннан яисә башка кеше катнашында кылынган икәнлеген раслаучы ялган күрсәтмә.

Ярлыкау — җинаять кылган билгеле бер затны җинаять җәзасыннан тулысынча яки өлешчә азат итү; дәүләт хакимиятенең югары органы тарафыннан җәзаны җиңеләйтүне яисә хөкем ителгәнлекне бетерүне тормышка ашыру (Россия Федерациясендә — РФ Президенты, Татарстан Республикасында — ТР Президенты тарафыннан).

Үзен-үзе белештермәү хәле — кешенең авыруы аркасында психик халәте, мондый очракта ул үзенең хәрәкәтләренә хисап бирә яки алар белән идарә итә алмый. Экспертиза ярдәмендә тикшереп беленә, юридик җаваплылыкка юл калдырмый. Закон буенча җаваплылыктан азат итми торган исерткеч (һәм наркотик) матдәләр кулланып исерү халәтеннән аерып карый белергә кирәк.

Җир хокукы — хокукның җирләрдән рациональ файдалану һәм аларны саклау максатында аңа ия булу, аннан файдалану һәм эш итү белән бәйле мөнәсәбәтләрне көйләүче тармагы.

Җинаять — иҗтимагый куркыныч, җәмгыять һәм дәүләт строена, гражданнарның милкенә, шәхесенә һәм хокукларына, хокук тәртибенә яный торган гаепле хәрәкәт яки хәрәкәтсезлек.

Җинаять кылудан ирекле баш тарту — кешенең, җинаятьне ахыргача җиткерү мөмкинлеге булып та, башланган җинаятьчел гамәлне үз ихтыяры белән туктатуы.

Җинаять составы — җинаятьне характерлау буенча закон билгеләгән сыйфатлар җыелмасы. Җинаять составының дүрт ягы була — җинаять объекты, җинаять субъекты, җинаятьнең субъектив ягы, җинаятьнең объектив ягы.

Җинаять объекты — җинаять законы тарафыннан саклана торган җинаятьчел кул сузу юнәлтелгән иҗтимагый мөнәсәбәт. Җинаять составы билгеләренең берсе.

Җинаять субъекты — җинаять кылган һәм закон буенча җинаять җәзасына тартылырга тиешле зат. Җинаятькә каршы көрәш хокукы буенча, үз акылындагы, закон билгеләгән яшькә җиткән физик зат кына җинаять субъекты була ала. Җинаять субъекты Россия һәм Татарстан гражданы да, чит илдән килгән кеше дә булырга мөмкин.

Җинаятьнең субъектив ягы — гаепкә һәм җинаятьнең сәбәбенә характеристика; җинаятькә каршы көрәш хокукы буенча, затның гаебеннән тыш җинаять составы юк, җинаять җаваплылыгы һәм җәзасы да була алмый.

Җинаятьнең объектив ягы — җинаять законы тарафыннан каралган һәм хокук тәртибенә кул сузучы иҗтимагый куркыныч гамәл (хәрәкәт яки хәрәкәтсезлек).

Җинаять сәбәбе — җинаять кылуга этәргән сәбәп, гаепне авырайта яки җиңеләйтә торган хәл булырга мөмкин (комсызлык, кызгану).

Җәза — законда күрсәтелгән җинаять кылган өчен бары тик суд тарафыннан һәм дәүләт исеменнән физик затка карата кулланыла торган махсус мәҗбүр итү чарасы.

Җинаять җаваплылыгы — җинаять кылган өчен җаваплылык.

Җинаять кодексы (кыскача ҖК) — җинаятькә каршы көрәш хокукы нормаларының билгеле бер системага салынган бердәм закон акты.

Җавапка тартылучы — судта (арбитражда) дәгъвачы тарафыннан гражданлык дәгъвасы җиткерелгән зат.

Укырга тәкъдим ителә торган китаплар исемлеге

Айтматов Ч. Плаха: Роман.— М.: Мол. гвардия, 1987.

Алексеев А. И. Дөреслекне эзләү.— М.: Юрид. лит., 1980.

Аракчеев Ю. Пирамида.— М.: Мол. гвардия, 1988.

Арбузов В., Шахновский А. Үз хокукларыңны бел һәм файдалан.— Л.: Лениздат, 1989.

Безуглов А. Җинаятьчеләр: Роман.— М.: Мол. гвардия, 1987.

Безуглов А. Ерткычлар.— М.: Мол. гвардия.

Брагинский М. Закон турында син нәрсә беләсең?: Укучылар өчен гражданлык хокукы буенча кулланма.— М.: Знание, 1988.

Вайнер А., Вайнер Г. Шәфкатьлелек эрасы: Роман; Шәһәр кабул итте: Повесть.— М.: Моск. рабочий, 1988.

Вайнер А., Вайнер Г. Минотаврга бару.— М.: Мол. гвардия.

Вайнер Г., Словин Л. Айның караңгы ягында: Повесть.— М.: Мол. гвардия, 1990.

Ваксберг А. Соңгы сүз.— М.: Мол. гвардия, 1986.

Винокуров В., Шурделин Б. Текә тыкрыктагы эзләр: Повесть.— М.: Мол. гвардия, 1989.

Габышев Л. Одлян, яки Азатлык һавасы.— М.: Мол. гвардия, 1990.

Грахов П., Головко Н. Өчле эш.— Л.: Лениздат, 1989.

Гусев В. Исән калырга гына түгел: Повестьлар.— М.: Мол. гвардия, 1990.

Домбровский Ю. Кирәксез әйберләр факультеты.— М.: Худож. лит., 1989.

Достоевский Ф. Җинаять һәм җәза: 6 кисәктән торган роман, эпилог белән.— М.: Сов. Россия, 1988.

Кларов Ю. Хитров базарының бетүе; Читләшү полосасында; Һөҗүм.— М.: Моск. рабочий, 1988.

Кларов Ю. Җинаятьчеләрне эзләү бүлеге музееннан биш экспонат.— М.: Мол. гвардия, 1985.

Корецкий Д. Каратэ принцибы: Повестьлар.— М.: Мол. гвардия, 1988.

Леонов Н. Профессионаллар: Повестьлар.— М.: Моск. рабочий, 1988.

Лиханов А. Хуш, Сирокко!: Повестьлар һәм очерклар.— М.: Моск. рабочий, 1990.

Яшьләргә хокук турында.— М.: Мол. гвардия, 1988.

Мостафин Р., Хәсәнов Ә. Татарстанның беренче Президенты Минтимер Шәймиев (Сәяси портретка штрихлар).— Казан: Татар. кит. нәшр., 1995.

Никитин А. Нәрсә ул хокукый культура?: Өлкән сыйныф укучылары өчен.— М.: Просвещение, 1988.
Никитин А. Кеше хокуклары: Урта мәктәп өчен уку әсбабы.— М.: 1993.
Оганесов Н. «Спринт» уйныйбыз: Повестьлар.— М.: Мол. гвардия, 1986.
Павлов К. Бу хәл дүшәмбедә булды.— Л.: Лениздат, 1989.
Плотников В. Суынган эзләр буенча: Тикшерүче Плетнев язмалары.— Л.: Лениздат, 1989.
Россиядә кеше хокуклары — халыкара үлчәнеш.— М.: Кеше хокуклары, 1995.
Татарстан Республикасының хокукый статусы.— Казан: Татар. кит. нәшр., 1996.
Привалихин В. Ату бәясе — тормыш.— М.: Юрид. лит. 1990.
Приставкин А. Алтын болыт куна калды.— М.: Сов. писатель, 1989.
Пронин В. Мәхәббәтсез төн.— М.: Мол. гвардия, 1990.
Пронин В. Объекттагы хата; Ромов А. Ачыкланмаган шартларда; Скорин И. УГРО егетләре.— М.: Моск. рабочий, 1990.
Псурцев Н. Перегон: Повестьлар.— М.: Мол. гвардия, 1989.
Саркисян И. Электричкадагы вакыйга.— М.: Моск. рабочий, 1990.
Кеше һәм халыклар хокуклары сүзлеге /Җаваплы ред. Тузмухамедов Р., Кузнецов В.— М.: Междунар. отнош., 1993.
Словин Л. Өстәмә поезд икенче юлга керә: Повестьлар.— М.: СП «Вся Москва» при участии МКО «Альянс», 1989.
Словин Л. Професионаллар өчен теннис туплары.— М.: Мол. гвардия, 1989.
Сорагыз — җавап бирәбез: Юристлар консультация бирә.— М.: Мол. гвардия, 1990.
Степанов А. Соңгы чиратта.— М.: Мол. гвардия, 1990.
Степанов А. Мосафирлар туктаган урын: Повестьлар.— М.: Мол. гвардия, 1990.
Толстой Л. Яңадан туу: Роман.— М.: Худож. лит., 1984.
Устинов Г. Ачыкланмаган шәхес.— М.: Мол. гвардия, 1990.
Чванов В. Катнашу: Повесть.— М.: Мол. гвардия, 1985.
Шевцов И. Талау: Роман.— М.: Мол. гвардия, 1988.
Феофанов Ю. Юрамалар һәм язмышлар.— М.: Мол. гвардия, 1988.
Феофанов Ю. Хакимият һәм хокук турында: Публицистик этюдлар. М.: Юрид. лит., 1989.

Учебное издание

Амиров Кафиль Фахразеевич
Амирова Рукия Гарабшиновна

ОСНОВЫ ПРАВОВЕДЕНИЯ

Учебное пособие
для татарской
средней общеобразовательной школы

(перевод с русского на татарский язык)

Редакция мөдире ***Р. И. Раскулова***
Редакторы ***С. С. Гайфуллина***
Бизәлеш редакторы ***Р. А. Сәйфуллина***
Техник редакторы ***Р. М. Галимова***
Корректорлары ***М. К. Нотфуллина, Р. В. Галләмова***

Нәшриятка 183 нче номерлы лицензия 1997 елның 7 апрелендә бирелгән.
Җыярга тапшырылды 12.05.98. Басарга кул куелды 30.09.98.
Форматы 60×90¹/₁₆. Китап-журнал кәгазе. «Школьная» гарнитурасы.
Офсет басма. Басма табагы 13,5. Нәшер-хисап табагы 13,9.
Тиражы 20 800. Заказ Я-237.

«Мәгариф» нәшрияты. 420503. Казан, Бауман урамы, 19.
Издательство «Магариф». 420503. Казань, ул. Баумана, 19.
Тел./факс (8432) 32-57-48.

Татарстан газета-журналлар нәшрияты типографиясе. 420066. Казан,
Декабристлар урамы, 2.